САНАГАННЫ ЯРАТА
Татарстан икътисады күрсәткечләре сөендерерлекме?
> 2

САКЧЫЛ КАРАШ
«Татнефть» балаларны табигатьне яратырга өйрәтә
> 4

ЯШЬЛЕК УЗМАГАН
Норлат әбиләре куплэргә үрнәк булырлык итеп яши
> 4

КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ
2021 елдагы эшчәнлек турында Вәкаләтле вәкил доклады
> 5–10

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 25 (28798) | Шимбә | 19 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Борчыган мәсьәлә

Җәмәгатьчелек фикере кабат икегә бүленде. Билгеле булганча, кинорежиссер Жора Крыжовников Роберт Гәрәевнең «Слово пацана» китабы буенча сериал төшерергә җыена. Сюжет үзәгендә – узган гасырда Казанда оешкан җинаятьчел төркемнәр тарихы. Берәүләр баштан кичкәннәрне кабат яңартудан зыян күрмәсә, икенчеләр режиссер эшенең шул чорларның кабатлануына этәргеч ясамагае дип шикләнә. Ул елларның җиле кызык эзләгән хәзерге яшьләргә кагылмасмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«ПАЦАН» НИ ӘЙТЕР?

Каршы торыргамы, дөресен күрсәтергәме?

Ыгы-зыгы нәрсәдән башланды соң? Февраль башында Жора Крыжовниковның «Слово пацана» сериалында катнашу өчен Татарстан шәһәрләрендә кастинг игълан ителде. Казанда әлеге кастингта 4 меңләп кеше катнашты. Яшүсмерләр һәм яшьләр, билгеле. Башкаларның күңеленә шом керде: экран аша җинаятьчел төркемнәр идеологиясен күрсәтү аларны каһарманлаштыру булмасмы?

Яшь буынны мондый эчтәлектәге чаралардан якларга кирәклеге турында беренчеләрдән булып Татарстанның бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Ирина Волынец әйтте. Ул республика прокуроры Илдус Нәфыйковтан яшүсмерләрне «Слово пацана» сериалына җәлеп итүнең законлымы-юкмы икәнен тикшерүне сорады. Сериал балигъ булмаганнарның психик һәм әхлакый сәламәтлегенә зыян китермәсен дип борчыла омбудсмен. «Җинаятьчел төркемнәрнең активлыгы чорында бик күп яшьләр вафат булды, «Слово пацана»ның дөньяга чыгуы аңы җитлекмәгән яшь буынга тискәре йогынты ясаячак», – дип саный ул.

Сүз уңаеннан, моңа кадәр Роберт Гәрәевнең китабын прокуратура тикшергән иде инде. Алар аны чыгаруны тыярлык нигез юк дигән фикергә килгән.

Фикер төрлелеге

Тарихны, бигрәк тә аның бик үк горурланып булмый торган өлешен яңарту кирәкме? Ул чорны күрмәгән, аңы җитлекмәгән яшь буын өчен мондый иҗат эшләре нәрсәсе белән куркыныч? 90 нчы еллар җинаятьләрен һәм җинаятьчеләрен каһарманлаштыру дөресме?

Татарстанның Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары Рафил Ногманов сүзләренчә, Казан тарихының мондый караңгы ягын күрсәтү кирәк түгел.

– Билгеле, Казанда боларның барысы да булган, барыбыз да белә инде. Әмма без моңа каршы торырга тиеш. Күп кешене харап иткән күренеш ул. Яшьләргә бер сөрән салу җитә хәзер, бу шул чорның кабатлануына китермәсен иде, – дип саный ул. – Әгәр сериал тәрбияви максатта төшерелсә, әйтик, менә шулай эшләргә, шундый булырга ярамый, дип өйрәтсә, нинди афәткә китерүен күрсәтсә, яхшы булыр иде. Киресенчә булса, кызганыч.

Казан Кремле дә шул фикердә.

– Меңьеллык тарихы булган республика башкаласында кино төшерерлек кызыклырак тарихлар да бар. Мәдәниятебез бай, яшь буынга күрсәтерлек тирән һәм лаеклы күренешләр күп, – дип белдерде Татарстан Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова. Шул ук вакытта төшерү эшләренә кысылу Президент дәрәҗәсендәге эш түгеллеген дә ассызыкладылар.

Россия кинематографчыларының Татарстан бүлеге рәисе, режиссер Илдар Ягъфәров сериалның явызлыкның яхшылыкны җиңүе турында булмасына өметләнә.

– Жора Крыжовников – сәләтле режиссер, көчле продюсерлар белән эшли. Алар сериалда явызлыкның өстен чыгуын күрсәтмәс дип уйлыйм. Драматургия, конфликт кирәк. Мондый темага күпме фильм, сериал чыкты инде. Бездә генә түгел ул. Минемчә, бернинди куркыныч юк, бары тик сериал әйбәт килеп чыксын. Минем уйлавымча, алар аз гына соңга калды, чөнки хәзер кеше бу хакта уйламый, һуш китәрлек проект булмас та. Төшерерләр, күрсәтерләр һәм онытырлар да, – ди ул. – Бу тема миңа да якын, чөнки ул мин үскән чорга да туры килде. Бассейннан кайтышлый, бер төркем кыйнады, аркага пычак кадады. Без бу чорны уздык. Ул төркемнәрдәге күпләр туры юлга басты. Аларның берсе дә үз балаларының шушындый төркемнәр оештыруын теләмәс.

Илдар Ягъфәров үзе, мондый проектка алынмас идем, ди. «Төшерәләр икән, каршы түгел. Әмма үзем алынмас идем. Бу минем өчен түгел. Урам пропагандасы белән шөгыльләнәсе килми. Минем максатым – милли кинематографны үстерү. Бездә башка матур, якты темалар, сәләтле актерлар күп. Бездә гел шикле проектларга теләктәшлек күрсәтәләр. Әмма аларның берсе дә аһ итәрлек нәтиҗә бирми», – дип саный режиссер.

Психолог Миләүшә Исмәгыйлева үсмерләрнең һәм яшьләрнең начар үрнәк саналган шәхесләргә охшарга тырышу омтылышларын, җәмгыять тарафыннан яманланган күренешләргә кызыксыну сәбәпләрен аңлатты.

– Әти-әни идеал булудан туктагач, балада тәнкыйди караш барлыкка килгәч, ул үрнәк булырдай, иярү өчен башка бер объект эзли башлый. Гадәттә, бу яшьрәк, аның чорына якынрак, карашлары заманча булган кешеләр. Шартлыча остаз диик. Бу остазны алар кайдан таба? Күбесенчә интернеттан, фильм, блогерлардан, – диде белгеч. – Мантыйк ягыннан караганда, криминаль образларда да бала өчен кирәкле сыйфатларны табарга була. Әйтик, батырлык, курыкмау. Тәнкыйди караш җитлекмәгән, баш мие формалашмаган (ул 25 яшькә кадәр бара. – **Ред**.) очракта, образларның начар сыйфатларын эләктереп, кабатларга мөмкин. Безнең бәла – үзебезнең образлар булмауда. Әйтик, Туганбатыр милли проектын тормышка ашырырга җыеналар. Шундый образлар тудырып, аларны популярлаштыра алсак, бик яхшы булыр иде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТУГАН ТЕЛ – ХАЛЫКНЫҢ ҖАНЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары Ассамблеясы Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Халыкара туган тел көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне Халыкара туган тел көне белән котлыйм. Җәмгыятьнең игътибарын телләрнең күптөрлелеген саклау мәсьәләсенә юнәлтү максатларында ЮНЕСКО тарафыннан гамәлгә куелган һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасы хуплаган бу истәлекле көн 1999 елдан башлап Җир шарының барлык тарафларында да билгеләп үтелә.

Һичшиксез, туган тел – ул халыкның «җаны», милләтнең яшәү нигезе һәм аның үзенә генә хас үзенчәлеген саклауның иң көчле коралы, чөнки һәр халык үзенең тарихы, дине, мәдәнияте һәм теленнән рухи көч алып яши. Дөньядагы милли мәдәниятләрнең күптөрлелеген һәм меңнәрчә телләрнең кабатланмас матурлыгын билгеләгәндә, без нәкъ менә туган телдә әйтелгән сүзнең зур көчкә ия булуын яхшы беләбез. Кеше туганнан бирле ул аның күңелендә үз урынын таба һәм, киләчәктә нинди генә башка телләрне өйрәнсә дә, ана теле белән «сеңгән» әйләнә-тирә дөньяны танып белү үзенчәлеге беркайчан да югалмый.

Кадерле дуслар! Халыкара туган тел көнендә без туган телләрне саклау һәм укыту өчен тырышкан, милли мәдәниятне алга сөрү эшенә фидакарь хезмәт иткән, туган тел ярдәмендә дөньяны, матурлыкны һәм игелекне аңлаткан һәркемгә дә олы рәхмәт сүзләрен җиткерәбез.

Ышанам ки, үз туган телен ихлас күңелдән яраткан кеше башка телдә сөйләшкән күршесенә дә ихтирам белән карый. Йөз җитмештән артык милләт вәкиленә Татарстаныбыз туган җир, туган йортка әйләнде, без моның белән горурланабыз. Республика җитәкчелеге аларның мәдәни үзенчәлеген саклау, күптеллелек гармониясенә ирешү өчен барысын да эшли, бары тик шулар аркылы гына җәмгыятьтә тынычлык һәм татулыкка нигез салына. Әйдәгез, бер-беребезгә игътибарлырак һәм мәрхәмәтлерәк булыйк. Нинди генә телдә аралашсак та, безнең максатыбыз уртак: бәхетле һәм озын гомер, якыннарыбызның сәламәтлеге һәм иминлеге. Барыбызга да шушы юлда уңышлар телим, бүгенге истәлекле көн республикабызда, илебездә һәм дөньяда булган барлык телләр һәм мәдәниятләргә карата тирән хөрмәт билгесе булсын.

Бушлай кертәләр

Татарстанда теркәлгән йортларны газлаштырып бетерү буенча төбәк штабы оештырылган. Президент Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән тиешле боерыкка кул куйган. Штаб дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарының «Газпром трансгаз Казан» (проект операторы) компаниясе белән газлаштыру буенча эшен җайга салу өчен оештырылган. Аңа Рөстәм Миңнеханов җитәкчелек итә.

2021–2023 елларга социаль газлаштыру программасына 9,3 мең йорт кертелгән. Моның өчен 3,9 миллиард сум күләмендә акча чыгымы күздә тотыла. Газны җир кишәрлегенә кадәр сузу – бушлай. Быел шул рәвешле 8,5 мең йортны газлы итү планлаштырыла.

COVID-19

Иммунитет бар. Тик аз

Бер тәүлектә – 3,6 мең очрак! Соңгы бер көндә Татарстанда әнә шулкадәр кеше коронавирус йоктырган. Бу алдагы атна белән чагыштырганда 2,3 тапкыр күбрәк, ди белгечләр. Гыйнвар ае белән чагыштырганда исә февральдә бу мәкерле чирне йоктыручылар саны 19 тапкыр (!) арткан.

Хәзерге вакытта республикада «омикрон» штаммының 334 очрагы ачыкланган. Авыручылар саны арту белән «больничный»ны электрон рәвештә генә ачуга да сорау арткан. Аны «122» хезмәтенә шалтыратып эшләп була. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина сүзләренә караганда, бүген республикада дистанцион рәвештә 3 меңгә якын «больничный» ачылган. «Бу уңайдан безгә барлыгы 4,4 мең гариза килеп ирешкән иде. 2,3 мең кеше хастаханәгә бармыйча гына «больничный» ачтырды», – диде Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков журналистлар белән очрашуда. Әмма бу телефоннан шалтыраттың да сиңа автомат рәвештә «больничный» бирелде дигән сүз түгел. Аны дистанцион рәвештә бирергәме, әллә инде хастаханәгә барып ачаргамы икәнлеген сезнең белән телефон аша сөйләшкән белгеч хәл итә.

Хәзерге вакытта Татарстанда коллектив иммунитет 80,31 процент тәшкил итә. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, коронавируска каршы вакцинаның беренче компонентын 2466602 кеше ясаткан. Министр урынбасары вакцинаның ике компонентын да ясатканнан соң алты айдан ревакцинация ясатырга кирәклеген дә искәртте. Әлегә ул тиешле дәрәҗәдә түгел дип саный белгеч. «1 августка Татарстанда 620445 кеше прививка кадаткан булган. Хәзер аларның ревакцинация үтәр чагы җитте. Бүген нибары 229500 кеше генә кабат вакцина ясаткан. Бу бик аз», – диде Жаворонков журналистлар белән очрашуда. Билгеле булганча, ел башыннан 12–17 яшьлек үсмерләргә дә коронавируска каршы вакцина ясала башлады. Хәзерге вакытта Татарстанда 1750 яшүсмер ковидка каршы прививканың беренче компонентын ясаткан.

Сүзгә-сүз

Анна КУЗНЕЦОВА, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары:

Без ятим балаларны торак белән тәэмин итү өлкәсендәге вазгыятькә нинди сәбәпләр китергәнен күрдек. Беренчедән, бу өлкәдә нәтиҗәле эшли торган дәүләт идарәсе булмау. Әлегәчә ятимнәргә торак бирү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләнмәгән. Бу вазыйфаны Төзелеш министрлыгына йөкләргә тәкъдим итәбез. Тагын бер сәбәп – кеше факторы, караклык һәм ришвәтчелек.

(«Парламентская газета» басмасыннан)

РОССИЯДӘ – ОНЛАЙН СӘҮДӘ

«Digital Horizon» компаниясе оештырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россия халкының өчтән бере генә электроника, азык-төлек һәм кием-салымны кибетләрдән сатып ала. Күпләр онлайн шопингка күчкән. Сораштыруда катнашучыларның 51,1 проценты киләчәктә барысын да интернет аша гына сатып алырга җыенуларын белдергән.

ОНЛАЙН РӘВЕШТӘ НӘРСӘ САТЫП АЛАСЫЗ?

45,7%	кием-салым
38%	электроника
21,5%	азык-төлек

Җәза кырыслана

Легаль булмаган мигрантларга һәм Россия законнарын бозучыларга карата катгый чаралар күреләчәк. Аларны хәтта илдән куарга мөмкиннәр. Бу хакта Россия Президенты Владимир Путин белдергән. «Легаль булмаган миграция эшчәнлеге, шул нигездә җинаятьчел бизнес коручыларга җитди чаралар күрелергә тиеш. Теләсә нинди экстремизм чагылышы, законсыз хезмәт эшчәнлеге буенча Россиядән куу һәм киләчәктә илгә кертүне тыю турында кичекмәстән карар кабул итәргә кирәк», – дигән Президент. Аның әйтүенчә, Россия законнарны үтәүче чит ил кешеләренә шат. Андыйларга кирәкле документларны рәсмиләштерү өчен барлык мөмкинлекләр дә булдырыла.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Алтын гасыр» кайтырмы?

Иртәгә Бөтендөнья социаль гаделлек көне. «Гаделлек ул әхлакый категория, билгеләмә генә түгел, дөньядагы тотрыклылык һәм иминлек тә. Тигез мөмкинлекләр, ярдәмчеллек, кеше хокукларын хөрмәт итү. Ул – милләт һәм халыкларның көч-егәренә дөрес юнәлеш бирү, күркәм яшәеш булдыру». 2009 елда әлеге датаны гамәлгә кертер алдыннан БМО Генераль секретаре югары мөнбәрдән бөтен дөньяга шулай дип белдергән. Дөрес сүзләр. Гаделсезлек – һәр очракта да низаг, гауга чыганагы. Бары социаль гаделлек кенә тынычлык, нәтиҗәле хезмәт һәм дә күтәренке рух тәэмин итә ала.

Нәкъ шуңа күрә дә гади кеше элек-электән гадел мөнәсәбәтләр һәм гадел дәүләт дип хыялланган. Акыл ияләре, фикерле затлар да читтә калмаган. Гаделдән дә гадел, тигездән дә тигез җәмгыятьләр, илләр уйлап чыгарып, китаплар язганнар, тәгълиматлар корганнар. Платон, Томас Мор, Кампанелладан башлап, Маркска кадәр шулай барган. Ленин исә, практик буларак, марксизм тәгълиматы белән коралланып, кешелек хыялын тормышка ашырырга Россиядә, булдыра алганда бөтен дөньяда иң гадел, иң күркәм тормыш төзергә алынып караган. Ләкин беләбез, «Кояш шәһәре» бөтенләй дә барып чыкмады. Киресенчә, каш төзәтәбез, дип, күзсез кала яздык – кан түгелде, җан кыелды, гаделлек эзләгәндә олы гаделсезлекләргә юл ачылды. Тик андый глобаль тәҗрибә уңышсызлыкка юлыкканга карап кына кеше заты гаделлек теләү, эзләү, аны таләп итүдән туктамады. Чөнки гаделлек беркайчан да йөз процент тормышка ашмас категория булса да, кеше заты омтылган иң асыл кыйммәтләрнең берсе.

Бер акыл иясе: «Бу дөнья без килгәндә ничек гаделсез булса, без аны ташлап киткәндә дә нәкъ шундый калачак», – дигән. Алай әйтү дөрес тә, дөрес түгел дә. Дөрес түгел, дию шуннан, гаделлеккә юл ифрат та озын, аңа ирешү озак процесс. Ә кеше гомере кыска. Бер гомер эчендә ул сыйфат адәм баласы сизәр дәрәҗәдә үзгәрмәскә дә мөмкин. Тик теләгәндә, вакыйгалар агышын барлаганда, аны тоемлап була кебек. Мәсәлән, әле бер гасыр элек кенә социаль дәүләт дип аталган дәүләтне көндез чыра яндырып эзләсәң дә, табып булмаган. Бүген исә алар бар һәм күп. Нәкъ менә социаль дәүләтләрдә социаль гаделлек дип аталган тезис гамәлгә кертелгән һәм дәүләтенә карап, кайда азрак, кайда күбрәк үтәлеп килә. Андый илдә матди байлыклар кеше дигәнең кешегә лаек тормыш кора алсын, гаделлек принциплары үтәлсен дип бүленә. Тигезсезлек, булган җәһәттә дә, күзгә төртелеп тормый, бай белән ярлы арасында киң упкын ятмый.

Ятимнәр, гарипләр акчалата да, мораль яклап та яклана, күпбалалы аналар кайгыртыла, өлкәннәргә пенсия түләүне инде әйткән дә юк. Пенсия дигәннән. Бит Иң яңа тарих дип аталган дәвернең башлангыч чорында андый түләүнең ни-нәрсә икәнен бик аз кеше генә белгән. Патша Россиясендә чиновникларның бер өлешенә һәм хәрбиләргә генә олыгайгач матди ярдәм күрсәтелгән. Анысы да монархиянең соңгы елларында. СССРда исә бар халыкка да пенсияне «кеше чырайлы» социализмга аяк баскач, ягъни Хрущев заманында түли башлыйлар. Мәрхүм әбиемнең, почтальон кулына 12 сум тотырып киткәч, сөенгәннәре, беркатлыланып: «И-и, бушка килгән акча бит. Шөкер, мондый заманны да күрдек», – диюләре бүгенгедәй күз алдымда. Бүген исә өлкән буын пенсиясез тормышны күз алдына да китерми. Артык сөендерерлек күләмдә булмаса да.

Хәзерге көндә күп илләрнең Төп Законына: «Фәлән ил – социаль дәүләт», – дип язылган. Шул исәптән Россия Конституциясенә дә. Тик, әйткәнебезчә, социаль яклау һәм социаль гаделлек, иленә карап, шактый аерылырга да мөмкин. Скандинавия илләрендәге социаль яклауның максималь дәрәҗәдә булуы күпләргә мәгълүм. Бары аларда гына байларга прогрессив салым аерым очракларда 70–80 процентка җитеп, эшсезлек буенча пособиенең шул ук Норвегия белән Швециядә – 1500, Даниядә хәтта 1800 евро булуын әйтәләр. Бу бит безнең акчага күчергәндә 120–140 мең сум! Бөтен дөньяда социализм һәм дә коммунизм төзергә хыялланган Ленин, бүгенге швед социализмын күрсә, ихтимал, утырып елар иде. Инкыйлаб оештырып юкка җәфаланганмын, дип. Тик биредә бер нечкәлек тә бар. «Швед социализмы» дип аталучы социаль гаделлек, феномен ул, ахыр чиктә, Европа капиталистының шөлләвеннән, Ленин ясаган революция аларга да килеп җитәр, барыннан да колак кактырыр, диюдән туган җәмгыять.

Ленин, ул теләгән гаделлек дигәндә, тагын да хыялый Кампанелла искә төшә. Вузда фәнни коммунизм өйрәнеп йөргән елларда диагональ буенча гына аның «Кояш шәһәре»н укып чыгарга туры килгән иде. Иң истә калганы – ирләрнең дә, хатын-кызларның да бер үк төрле кием – униформа киюе, бөтен халыкның бер вакытта һәм бергә ашавы. Аннан соң, гафу итегез, кайсы ирнең нинди хатын белән мөнәсәбәткә керүен дәүләт чиновнигының хәл итүе. Болар барысы да – ирексезлек. Ирексезлек яшәгәндә гадел дәүләт турында гомумән сүз куертып була микән? Җыеп әйткәндә, пролетариат юлбашчысы теләгәннәр белән итальян фикер иясе күз алдында тоткан дәүләттәге тәртипләрдә уртаклык хәтсез. Аларда ирекле дәүләттә ирекле кешеләр төзегән «швед социализмы» түгел, казарма социализмы шәйләнә. Ә бит гадел җәмгыять дигәндә, барысы да гади кебек: яхшы гадәтләргә, традицион саналган кыйммәтләргә өстенлек бир дә мораль, әхлакый нормаларга тугры кал. Гади кешеме син, хакимият дилбегәсе тотучымы, нәрсәгәдер алынгансың икән, закон буенча эшлә, яшә.Законнарны күпчелек мәнфәгатеннән чыгып кабул ит…

Борынгы грекларның бик күп аллалары арасында Астрея дигәне – гаделлек алиһәсе дә булган. Үзенең бертуган сеңлесе Айдос – тыйнаклык һәм оялчанлык алиһәсе белән ул башта кешеләр арасында яшәгән. Греклар «алтын гасыр» дип аталган чорда алар адәми затларны гаделлеккә һәм тыйнаклыкка, сабырлыкка өйрәткән. Имеш, ул заманнарда кешеләр гадел дә, тыйнак та, оялчан да булганнар: бай байлыгы сәбәпле ярлыдан оялып йөргән. Әмма бераздан, «тимер гасыр» җиткәч, кеше токымы бозылган. Сугышып, ызгышып, бер-берен талап яши башлаган. Ике алиһә исә, аларга кул селтәп, имеш, күккә ашкан.

Без үзебезне кешеләр дип атыйбыз. Кешелеккә: «Астрея белән Айдос киредән җиргә кайткан икән», – дип әйтерлек гадел һәм мәгънәле җәмгыять төзисе, мифик түгел, ә чын «алтын гасыр»га ирешәсе иде. Булырмы, кайчан да булса килерме андый заман?

АЛАРГА ДА, АЛАРДАН ДА ЗАРЛАНАЛАР

Нәтиҗә

Татарстан судьяларының XV еллык конференциясендә хөкем чыгаручыларның эшчәнлеге турында хисап тоттылар. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Коронавирус судларның да эшен арттырды. Әйтик, 2021 елда республика судлары административ хокук бозуга бәйле 185 мең эш тикшергән. Матди штраф күләме 220 млн сумны тәшкил иткән.

Гомумән, «таҗлы эшләр» барлык тикшерелгән эшләрнең зур өлешен алып торган. Икенче урында исә – хулиганлык, өченче баскычта – көч структураларының таләпләренә буйсынмау. Хокук бозу турында эшләр 16 процентка арткан. Административ җәзага 314 мең кеше тартылган. Шуларның яртысыннан артыгыннан штраф түләткәннәр, чиреге кисәтү белән котылган.

Былтыр халык судка түгел, судлардан да ешрак зарланган. Моңа бәйле 11 мең мөрәҗәгать кабул ителгән. Татарстанда яшәүчеләр Югары, Вахитов һәм Совет районнары судлары эшчәнлегеннән канәгать түгел.

Татарстан Югары суды рәисе Илгиз Гыйләҗев хисабыннан аңлашылганча, узган ел ришвәтчелеккә бәйле эшләр, 2020 ел белән чагыштырганда, 62 процентка арткан.

Өй арестына җәлеп ителгән кешеләр саны исә дүрт мәртәбә сирәгәйгән. Хөкем ителгәннәрне вакытыннан алда иреккә чыгару турында 1300 мөрәҗәгать кабул итеп, шуның чирегеен тормышка ашырганнар.

Күп кенә тармакларның баш бәласе булган кадрлар кытлыгы белән суд та очрашкан. Илгиз Гыйләҗев әйтүенчә, республикага 44 хөкемдар җитми. Җәмәгать судьялары аппаратыннан 308 кеше эштән киткән.

– Бик азлар гына үз өстенә шундый йөк алырга, башкаларның тормышы өчен җаваплылык тотарга, үзләрен тулысы белән һөнәргә багышларга әзер, – ди Югары суд рәисе.

Хезмәтләренең авыр булуын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та билгеләп үтте. Цифрлаштыру елы җиңеллек китермәсме? Ник дигәндә, суд системасы да электронлаша. Бу исә халыкка да уңайлы.

– Судьяларга эш елдан-ел арта. Икенче ел инде сез административ хокук бозулар турындагы эшләрне тикшерәсез. Аларның күп булуы халыкның вазгыятьнең ни дәрәҗәдә җитди булуын аңламавын күрсәтә. Бу мәсьәләдә эшләргә кирәк, – диде республика җитәкчесе.

Моннан тыш коррупцион җинаятьләрнең артуына, алкоголь әйләнеше кебек мәсьәләләргә, эш урынында чыккан бәхәсләргә аерым игътибар бирергә кирәк дип искәртте ул.

Яшел Үзәнгә табиблар җитми

tatarstan.ru

Яшел Үзән шәһәре һәм районы советларының уртак утырышы узды. Аның эшендә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Утырышка кадәр Дәүләт Советы Рәисе район башлыгы Михаил Афанасьев белән Яшел Үзәннең кайбер социаль объектларында булып, республика программаларын тормышка ашыруның барышы белән танышты.

Парламент башлыгы узган елда төзелә башлаган Мәдәни үсеш үзәгендә булып, аның концепциясе белән таныштырылды. Биредә районның милли-мәдәни автономияләрен һәм үзешчән иҗат коллективларын урнаштыру күздә тотыла. 600 урынга исәпләнгән тамашачы залы булдырылачак. Төзелешкә акча федераль программа буенча бирелә.

Шәһәр һәм район советларының берләштерелгән утырышы Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәгендә узды. Район хакимияте башлыгы Михаил Афанасьев чыгышыннан күренгәнчә, узган елда районның тулай территориаль продукты күләме 50 миллиард сум тәшкил иткән (үсеш – 101 процент). Тулай продуктның өчтән бер өлеше – 14,6 миллиард сумы кече бизнеска туры килә. Сәнәгатьтә җитештерү күләме акчага салып исәпләгәндә 52 миллиард сум чамасы булган.

Шәһәрнең ике төп предприятиесе – Серго исемендәге һәм Горький исемендәге заводлар җитештергән продукция гомуми күләмнең 61 процентын тәшкил иткән.

Михаил Афанасьев кайбер проблемаларны да телгә алып үтте. Шуларның берсе –медицина хезмәткәрләре җитмәү. Аның әйтүенчә, район табиблар белән нибары 57 процентка гына тәэмин ителгән.

Әлбәттә инде, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бу хәлне игътибарсыз калдырмады. Район башлыгыннан ул: «Пандемияле шушы авыр елда бу мәсьәләне ничегрәк хәл итәргә уйлыйсыз?» – дип сорады.

Михаил Афанасьев, чыннан да, проблеманың кискен торуын таныды. «Без барлык программаларда, шул исәптән «Земский доктор» программасында катнашабыз, социаль ипотека программасы буенча торак төзибез. Әмма бу гына аз. Яңа балалар сырхауханәсе ачылгач, уңайлы шартларда эшләргә теләк белдерүче табиблар пәйда булыр дип уйлыйбыз», – дип билгеләп үтте ул.

Афанасьев сүзләренә караганда, район җитәкчелеге Казан дәүләт медицина университеты белән эшли. Аерым алганда, максатчан укыту буенча килешүләр төзелә, студент-медикларны укыту өчен түләнелә. «Бу эшне миңа да, район үзәк хастаханәсе баш табибына да көчәйтергә кирәк. Аны Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә башкарсак, әйбәтрәк булыр иде», – дип басым ясап әйтте район башлыгы. Фәрит Мөхәммәтшин әлеге проблема буенча җитдирәк эшләүне сорады.

Дәүләт Советы Рәисе район җитәкчелеге эшчәнлеген бәяләп, социаль-икътисади үсеш күрсәткечләрен яхшырту өчен барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәргә кушты. «Район ел йомгаклары буенча гомуми рейтингта, алты урынга түбәнгә тәгәрәп, 24 нче урынны алган, – дип тәнкыйтьләп алды ул. Кече һәм урта бизнесның эшен көчәйтергә, файдаланылмаган авыл хуҗалыгы максатындагы җирләргә игътибар итәргә кирәк. Сездә алар – 8,5 мең га. Мондый җирләрнең барысын да әйләнешкә кертү – үсеш ноктасларының берсе булып тора, дип саныйбыз. Шул ук вакытта сез авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеге буенча – алдынгы районнар өчлегендә».

Уңышлы ел

Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының еллык коллегиясендә министр Альберт Кәримов сәнәгать җитештерү индексының 108,5 процентка җитүен хәбәр итте. Товар һәм хезмәт күләме 4 трлн сум булган. Чагыштыру өчен, 2020 ел күрсәткечләре буенча, Татарстанда җитештерү 3,6 процентка кимегән, ә продукция күләме 2,7 трлн сум иде.

– Бу – барлык оешмаларның да уртак эш нәтиҗәсе. 1992 елдан бирле Татарстанда мондый күрсәткечләргә ирешкән юк иде. Сәнәгать күрсәткечләре пандемиягә кадәрге чорга караганда да югарырак, – диде министр.

Нәтиҗәләрнең зур өлеше нефть продуктлары, химия, нефть химиясе, файдалы казылмалар чыгару һәм машина төзелешенә туры килә. Аерым алганда, республиканың сәнәгатьтәге уңышларының 63 проценты нефть-газ-химия комплексына туры килә. Алар тарафыннан 2,5 трлн сум продукция эшләнгән. Сәнәгать предприятиеләренең 78,7 проценты 611,18 млрд сум табыш алган. Ә 21,3 проценты 20,45 млрд сумлык зыянга эшләгән.

Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Иң элек ул хезмәт коллективларын саклап калган оешма җитәкчеләренә рәхмәтен белдерде, республиканың нефть-газ-химия комплексы һәм машина төзелеше белән көчле булуына басым ясады. Сүз уңаеннан, республиканың сәнәгать тармагында барлыгы 323 мең кеше эшли.

– Машина төзелешендә илебезнең лидеры булган КамАЗ турында да әйтми булдыра алмыйм, – диде ул. – Соңгы елларда заводны модернизацияләү буенча бик зур эш башкарылган. Бүген бездә дөньякүләм дәрәҗәдәге автомобильләр линейкасы бар. Бу – системалы эш нәтиҗәсе. КамАЗ – безнең горурлык. Алга таба да зур планнар бар.

Президент үсеш темпларын ел саен ким дигәндә 4 процентка арттыру бурычын куярга кирәклеген әйтте.

– Без тулай төбәк продукты һәм сәнәгать җитештерү индексын 5 триллионга җиткерү турында хыяллана идек. 4 триллионга ирештек. Темпларны ким дигәндә 4 процентка арттыру бурычын куярга кирәк. Моның өчен безнең бөтен мөмкинлекләр дә бар, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов 2026 елда чик буе (пограничный) транспорт-углерод салымы кертеләчәген искә төшерде:

– Ил Президенты предприятиеләрдән чыккан газларны киметү бурычын куйды. Шуңа күрә оешмаларга технологияләрне карарга, җиһазларны яңартырга туры киләчәк. Бу салымга электр энергетикасы да эләгә.

Президент шулай ук Татарстанның цифрлаштыру буенча 27 нче генә позициядә торуына басым ясады.

– Без үзебезне цифрлашкан төбәк дип әйтәбез. «КамАЗ», «Татнефть» оешмаларында цифрлаштыру югары дәрәҗәдә башкарыла. Ләкин кайбер компанияләр 100 күрсәткечнең 30ына гына ирешкән. Алар әллә аңламыйлар, әллә белмиләр. Кадрлар мәсьәләсе буенча да эшлисе эшләр күп. Һәр сәнәгать предприятиесендә кадрларга кытлык бар. Бу сорау буенча максатчан эш алып барырга кирәк булачак, – диде ул.

Президент сәнәгать оешмаларында килеп чыккан бәхетсезлек очракларына да игътибар итәргә кирәклеген әйтте. Узган ел республикада шундый 73 очрак теркәлгән.

САН

2021 елда 34,5 млн тонна нефть табылган, 69,3 мең йөк һәм 747 җиңел машина, 13,5 млн автомобиль тәгәрмәче, шулай ук 27 млрд кВт/сәг электр энергиясе эшләп чыгарылган. 2022 елда нефть чыгаруны 10 процентка арттыру, ә нефть эшкәртүне ким дигәндә 22 млн тоннага җиткерү планы бар.

МИДХӘТ ШӘҺИӘХМӘТОВ:

«ИКЪТИСАД ЭЛЕККЕГЕ ХАЛӘТЕНӘ КАЙТТЫ»

Икътисад министрлыгының еллык коллегиясендә узган ел Татарстан икътисады нинди күрсәткечләргә ирешкәнлеге билгеле булды.

Коллегиядә төп доклад белән чыгыш ясаган икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренчә, Татарстанның тулай төбәк продукты 3,259 трлн сумны тәшкил иткән. Бу 2020 ел белән чагыштырганда 3,8 процентка арткан дигән сүз. Икътисади үсешкә сәнәгать җитештерүендә яңа көчләр кертеп җибәрү, нефть, химия һәм машина төзелеше продуктларын чыгару арту кебек факторлар йогынты ясаган.

– Республика икътисады короновирус чикләүләренә кадәрге вакытка җитте. Күп кенә тармаклар үз халәтенә кайтты. Бары тик җәмәгать туклануы гына үз көченә эшләп китә алмый. Узган елгы корылык авыл хуҗалыгына тискәре йогынты ясады. Шулай булуга карамастан, ваклап сату әйләнеше 1 млрд сумнан артып китте, ә уртача хезмәт хакы 105,8 процентка артып, 44930 сумга җитте, – диде Мидхәт Шаһиәхмәтов.

Аның сүзләренчә, республика казнасын баетуга төп өлешне Казан, Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләре керткән. Министр киләсе елларга да зур максатлар билгеләде. Хезмәт җитештерүчәнлеген һәм үсеш тотрыклылыгын, кеше капиталын үстерү, районнар үсешен тигезләү, моңа исә илкүләм һәм республика программаларын тормышка ашыру аша килү – куелган зур бурычларның берничәсе генә.

Узган ел нәтиҗәләре буенча, бары тик ТОСЭР Яшел Үзән генә куелган барлык нәтиҗәләргә ирешкән. Чаллы резидентлар

tatarstan.ru

санын тутырмаса, Түбән Кама эш урыннары һәм акча кертү буенча артта кала. Ә менә Менделеевск бөтенләй бернинди дә уңышка ирешмәгән. Узган ел бу районга бары тик ике резидент кына җәлеп ителгән булган.

Мидхәт Шәһиәхмәтов әйтүенчә, инвесторларга керемгә, милеккә һәм җиргә салым буенча ташламалар каралган. Бу да яңа компанияләрне җәлеп итәр өчен уңышлы чара булып торырга мөмкин, дип саный министр. Шуңа күрә быелга өметләре зурдан. Ул Татарстанга 34 яңа резидент, 12,2 млрд сум инвестиция һәм 2,8 мең хезмәт урыны җәлеп итү бурычын куйды.

Инвестицияләр өчен көрәштә ил төбәкләре арасында көндәшлек арта баруына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та басым ясады. Аның фикеренчә, Татарстан сәнәгать мәйданчыклары инвесторларның кабул ителә торган карарлары тизлеге, административ процедураларны киметү, инфраструктура сыйфаты һәм ресурслар белән тәэмин итү таләпләренә туры килергә тиеш. Рөстәм Миңнеханов республика махсус зоналары һәм ТОСЭР эшен активлаштырырга өндәде.

– Бу елга максат – кече һәм урта эшкуарлыкта эшләүчеләр санын 800 мең кешегә җиткерү. Кече һәм урта эшкуарлыкны системалы рәвештә үстерү белән шөгыльләнүче районнар социаль-икътисади үсеш рейтингында алдынгы урыннарны били. Болар – Тукай, Югары Ослан районнары, Казан һәм Чаллы. Шул ук вакытта бизнесны үстерүгә җитәрлек игътибар бирмәүче районнар да бар. Бу – Кайбыч, Әгерҗе, Аксубай һәм тагын берничә район. Мин алардан артта калуның сәбәпләрен җентекләп анализлауны сорар идем, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент район башлыкларына эшмәкәрлек өчен шартлар тудырырга кирәклегенә игътибарны кат-кат юнәлтте.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, хакимият өчен төп макроикътисади бурыч – инвестицион активлыкны стимуллаштыру.

– Узган ел нәтиҗәләре буенча республика предприятие-оешмалары тарафыннан якынча 650 млрд сум күләмендә табыш алынган. Предприятие директорларына һәм милекчеләренә мөрәҗәгать итәм: бу финанс ресурслары Татарстанда калырга һәм инвестицион проектларны эшләтеп җибәрү һәм сезнең продукциянең конкурентлылык сәләтен арттыру өчен база булып торырга тиеш, – дип билгеләп үтте Президент.

Аның фикеренчә, районнар икътисадын үстерү өчен тагын бер мөмкинлек – сәнәгать парклары. Аларның резидентлары сәнәгать җитештерүе күләменең якынча 10 процентын формалаштыра. 2021 елда 7 меңнән артык яңа эш урыны булдырылган. Паркларны үстерү өчен барлык шартлар да тудырылган: резидентлар өчен салым ташламалары, төзелешкә кредитлар бирелә. Шуңа да карамастан, 9 районда сәнәгать парклары билгеләнгән таләпләргә туры килми. Нәтиҗәдә аларның резидентлары дәүләт ярдәме инструментларыннан файдалана алмый. Рөстәм Миңнеханов әлеге районнар җитәкчелегенә сәнәгать мәйданчыкларының нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрергә кушты.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бураннарга чыгып йөгерер идем,
Адаштым дип хәбәр салсаң әгәр.
Көртләр аша ничә чакрым икән
Синең кыштан минекенә кадәр?

Боз җилгәргән җансыз җилгә каршы
Атлар идем әле йөзем куеп.
Барлыгыңны белсәм, дөньясында
Бер югалыр идем, эзне җуеп.

Тик бер эрер өчен, учларыңа
Кар бөртеге булып төшәр идем.
Офыкларда син көткәнне белсәм,
Кар дәрьясын мең кат кичәр идем.

Бозга әйләнсен лә үксез җаным,
Сыкы кунган юлда йөгенсәм мин...
Сине барыбер эзләп табармын күк,
Бураннарга чыгып йөгерсәм мин.

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Һәйкәлләр нигә кирәк?

Газетаның 5 февраль санында басылып чыккан «Татарның ике бөек улы» мәкаләсен укыгач, битараф кала алмадым. Шушы уңайдан язылганнарны хуплап, үз тәкъдимнәремне дә җиткерәсем килә. Галиәсгар Камал театры янында Тукай бүләге иясе Илһам Шакировка һәйкәл кую бик урынлы булыр иде. Бу теләкнең тормышка ашуын татар халкы бик көтә дип уйлыйм. Күз алдына китерегез әле: Илһам Шакиров сыны тора, аның уң кулы ягында – Габдулла Тукай, каршысында – Салих Сәйдәшев. Яңа проект буенча икенче бинага күчеп китү сәбәпле, яшьләргә тапшырылачак Камал театрыннан чыккан яшьләр, килгән кунаклар, мосафирлар Кабан күле буендагы динамиклардан Тукай сүзләренә Сәйдәшев иҗат иткән Илһам Шакиров башкаруындагы «Туган тел»не, «Әдрән диңгез»не, «Кара урман»ны тыңлап ләззәтләнерләр. Минемчә, моны бигрәк тә үсеп килүче буын вә читтә яшәүчеләр өчен эшләргә кирәк. Казан шәһәрендә туып үскән, чиркәү хорында җырлап, опера җырларын оста итеп башкарган Федор Шаляпин һәйкәле дә ерак түгел, Бауман урамында. Аннан: «Кайда, ничек итеп шулай оста итеп җырларга өйрәндегез?» – дип сорагач, ул: «Мин җырыма татар моңын кушып җырлыйм», – дип җавап биргән. Аның сыны куелган урын халыкның яраткан урынына әверелде. Илһамыбыз да кунакларны, туристларны үзенә чакырып торыр иде.

Телебезне саклауга, киләчәк буыннарны тәртипле итеп үстерүгә зур өлеш керткән гүзәл затларыбызның хезмәтләрен дә онытмыйсы иде. Мин бигрәк тә Россиянең, Татарстанның һәм Башкортстанның халык җырчысы Фәридә апа Кудашева, татарның сандугачы, күренекле композитор Сара апа Садыйкованы һәм кабатланмас моң иясе, Татарстанның данлыклы җырчысы Әлфия апа Авзалованы күз алдында тотам. Аларның да исемнәрен мәңгеләштерәсе иде. Татарлар шулай ук Казан ханлыгы патшабикәсе Сөембикәнең һәйкәлен дә зарыгып көтәләр.

Без, тарихны укып, күп кенә шәхесләребезнең исемнәрен, кылган гамәлләрен беләбез, ә күз алдына китерә алмыйбыз. Шуңа күрә тарихи шәхесләребезнең һәйкәлләрен манзара кылу беркемгә дә комачауламас иде.

Гарафетдин ХИСАМЕТДИНОВ.
Казан

ӘЛЛӘ НИ АРАДА ҮСЕП ҖИТТЕЛӘР

Мамадыш районы Югары Сон авылында гомер итүче Сәвия Гыйлаҗетдинова тормыш мәшәкатьләре белән 75 яшьлек матур юбилееның ишек какканын сизми дә кала. Исең китәр, күпме вакыт узган бит.

Сугыштан соңгы, илебез аякка басарга тырышып яшәгән авыр чорга туры килә аның балачагы. Шөкер, әтисе Котдус абый Бөек Ватан сугышыннан исән-имин, җиңү яулап кайта. Әниләре колхозда төрле эшләрдә эшли. 1947 елның гыйнварында, кышның суык көнендә, гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә Сәвия. Аңа өч яшь булганда, барысын да ятим калдырып, әтиләре фаҗигале төстә Идел елгасында батып үлә. Сәвиядән соң тагын бер кыз бала туа әле. Төпчек балага Нурия дип исем бирәләр. Аны карап үстерү апасы Сәвиягә туры килә. Алар бергә уйныйлар, кайвакыт, үзара тарткалашып, нәрсәдер бүлешеп тә алалар. Апасы малайлар белән көч сынашса да, арага кереп кысыла торган була сеңлесе. Кайвакыт әнисенә кайтып әләкли. Әмма ничек кенә булмасын, алар агылый белән тагылый кебек булалар. Хәзер дә бер-берсен сагынып, һәр очрашуга шатланып яшиләр.

Сәвия ханым үзенең балачагын «яланаяклы» дип искә ала. Язгы кояш карны эретеп бетерергә дә җитешмәгән мәлне көтеп ала балалар. Аяк-куллары «чебиләп», яргаланып, кытыршыланып бетә. Әниләре мунчада мунчалага кер сабыны сылап, аларның елаганнарына да карамый ышкып юа да каз мае сөртеп куя. Бу иң яхшы дәва була.

Кыз беренче сыйныфка Алкин авылындагы башлангыч мәктәпкә бара. Ул чакта мәктәпләр утын ягып җылытыла. Ягарга утын җитмәгәнлектән, һәр балага ике ярка утын алып барасы. Әниләре ни пешерсә, шуны тыгып җибәрә. Күбрәк бер телем ипи белән сөт җибәрә. Сәвиягә уку җиңел бирелә, яхшы билгеләргә генә укый. Өченче класстан соң укуын Тәкәнеш мәктәбендә дәвам итә. Әле кечкенә булганлыктан, сагынуга чыдый алмый: 25 чакрым ераклыктагы авылына берүзе качып кайтып китә торган була. Ул чакларны искә алганда, Сәвия ханым, күрде инде безнең башлар, дип уфтанып куя.

1965 елда мәктәпне яхшы билгеләренә генә тәмамлый ул. Әнисенең укытырга мөмкинлеге булмагач, кая да булса эшләргә ният кылып, мәгариф бүлегенә юл тота. Аны Үсәли урта мәктәбенә пионервожатый итеп билгелиләр.

Югары Сондагы «Спартак» колхозына билгеләнгән Ирек исемле яшь рәис Сәвиягә бер күрүдә гашыйк була. Өч ай да эшләргә өлгермәгән кызны, 18 яше дә тулмаган килеш, ат белән Югары Сонга урлап алып кайта. Кызны Югары Сон җидееллык мәктәбенә рус теле укытучысы итеп күчерәләр. Ул Казан педагогия институтының читтән торып уку бүлегенә укырга керә. Коллектив белән дус, тату эшлиләр. Барысы да яшьләр, активлар, тормышлары да бер чама. Бәйрәмнәрдә гаиләләр белән җыелалар, табигатькә дә ял итәргә бергә чыгалар.

Сәвия ханым, кечкенәдән ныгып үскәнгә, бер эштән дә курыкмый. Ирен өч кыз һәм бер малай белән дә куандырырга өлгерә. Каенанасы белән дә килешеп, фикерләшеп яши.

Авылда балалар күп булганга, колхоз рәисе балалар бакчасы ачарга кирәк дигән фикергә килә. Озак та үтми, авыл уртасында мәһабәт бина калка. Җиләк-җимеш бакчасы да булдырыла. Сәвия ханымны шушы бакчага мөдир итеп күчерәләр. Шул вакыттан 19 ел мөдир булып тора ул. Бакча үз чорында Татарстан буенча алдынгы урында бара. Махсус киемнәр тектереп, телевидениедән дә чыгышлар ясыйлар, балаларны ел саен Казанга циркка да алып баралар. Мөдир хезмәттәшләре – музыка белгече Гүзәлия Фәләховага, тәрбияче Наҗия Рәхимовага, хезмәткәр Оркыя Сәләхиевага бик тә рәхмәтле.

Хәзер Сәвия ханым лаеклы ялда. Иреге генә иртәрәк ташлап китте аны... Балалары бар да урнашкан, гаиләле. Кече кызы үзе белән яши. Сәвия ханым эшсез тора алмый. Аның яраткан һөнәре – бакча үстерү. Кыш көннәрендә бәйләү белән мавыга. Дүрт оныгы яшәргә көч биреп, шатлык өстәп торалар. «Элек, һәр ял саен кайтып, өебезне шау-гөргә күмеп, миңа өч көнлек эш калдырып китәләр иде. Әллә ни арада үсеп җиттеләр. Менә өлкән оныгым Азатның малае Самир туды. Шуны күрү бәхетенә дә ирештем. Шатлыгымның чиге юк! Аллаһка шөкер, исән-сау гына булсыннар!» – дип шатлыгы белән уртаклашты ул. Без дә Сәвия ханымга саулык, озын гомер, балалары-оныклары бәхетенә куанып яшәвен теләп калабыз.

Рәйсә МУЛЛАӘХМӘТОВА. Мамадыш

Хуҗа Хәсәннең батыр кызы

15 февральдә Данилова (Кузнецова) Ольга Власовнаның якты дөньяга килүенә 100 ел тулды. Ул укытучы булып эшләгән, 41 нче пулемет полкы составында кулына корал алып туган илне саклаган. Авылыбыздан Ватан сугышында катнашкан бердәнбер хатын-кыз.

Россия Оборона министрлыгы архивыннан алынган белешмә нигезендә әлеге полк 1943 елда Курск шәһәреннән дошманны куакуа, Украина, Польша авыл, шәһәрләрен азат итүдә катнаша һәм 1945 елның 28 мартында Германия территориясенә үтеп керә. Ольга Власовна Берлинны штурмлауда да катнаша. Пулеметчылар отделениесе командиры була. Берлинны алуда актив катнашкан өчен сугышчан дәүләт бүләге дә бирелә.

Кызганыч, моңа кадәр Ольга Данилованың каберендә Бөек Ватан сугышында катнашучы буларак истәлек билгесе дә юк иде. Сугышта катнашу Ольга Власовнаның сәламәтлеген бик нык какшата. Ул 1961 елда 39 яшен дә тутыра алмыйча вафат була. 5 баласы ятим кала.

Ольга Данилованың исемен мәңгеләштерү максатыннан 2017 елның 4 июнендә Россия Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов ярдәме белән аның каберенә, ниһаять, һәйкәл урнаштырылды, ә бөтен чыгымнарын Яшел Үзән районы башкарма комитеты каплады. Шул ук вакытта Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәдәният министрлыгы, Татарстанның Сугыш ветераннары советы һәм Ольга Власовнаның язмышына битараф булмаган бик күп гади кешеләр Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы һәм Кайбыч район хакимияте башлыгына да мөрәҗәгать иткәннәр иде.

2020 елның июнь аенда Кайбыч районы хакимияте башлыгы Альберт Рәхмәтуллин, җирле үзидарә башлыгы белән җыелышлар үткәреп, авылыбызның Үзәк дип аталган элеккеге тарихи зур урамын Ольга Данилова урамы дип үзгәртергә карар кабул итте. Шушы тарихи вакыйга Ольга Власовнаның нәселе өчен генә түгел, ә авыл халкының күбесе өчен дөреслек һәм гаделлек бәйрәме булып, җаннарында горурлык һәм рухи хисләрне уятты дип әйтә алабыз. Хәзер инде батыр хатын-кызның фоторәсеме дә Тау ягы татар керәшеннәре музеенда, Туган якның күренекле шәхесләре сафында эленеп тора. Ольга Власовнаның балалары, оныклары, оникчыклары, якыннары һәм бертуган энесе, авылдашлары исеменнән Кайбыч районы хакимияте башлыгы Альберт Рәхмәтуллинга, Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы Светлана Матвеевага һәм дә Россия Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдиновка бик зур рәхмәтебезне юллыйбыз, аларга нык сәламәтлек һәм уңышлар телибез. Җыелышларда актив катнашып бу мәсьәләне уңай хәл иткән өчен намуслы, горур халкыбызга Ходаебызның рәхмәте яусын!

Вячеслав ДАНИЛОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың суд системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды суд составы рәисе **Худобин** Юрий Павлович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Судының отставкадагы судьясы **Шәрифуллин** Рамил Әнвәр улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Эшендә уңышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан технология һәм дизайн көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Даутов** Ирек Фәрит улы; граждан авиациясен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «ЮВТ АЭРО» акционерлык җәмгыяте очучылык хезмәтенең 1 номерлы авиация эскадрильясе командиры **Хәмзин** Риф Мәгариф улы; торак-коммуналь хуҗалык тармагында күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – Татарстан Республикасы баш дәүләт торак инспекторы **Крайнов** Сергей Аркадьевич; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Джи Эм Си Консалтинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Маштакова** Галина Юрьевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «В.Б.Шнепп исемендәге үзәктән куучы һәм роторлы компрессорлар буенча фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык институты» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Әхмәтҗанов** Альберт Мингаяз улы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының икътисад һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеге инфраструктурасы мәсьәләләре комиссиясе рәисе **Гыймадетдинов** Айрат Фердинанд улы, «Телевидение һәм радиотапшырулар шәһәр агентлыгы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Малькевич** Александр Александрович, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының икътисад һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеге инфраструктурасы мәсьәләләре комиссиясе рәисе урынбасары **Сафин** Фәрит Рәшит улы, Казан шәһәре Совет районының «Немец теле тирәнтен өйрәнелә торган 72 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Смолкина** Наталья Викторовна, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе идарәсе рәисе **Старостин** Сергей Петрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел»** медале белән бүләкләнде.

***

«Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләре: тәҗрибә производствосы цехы башлыгы урынбасары **Габдрахманов** Динар Наил улына, конструкторлык бюросы директорының эксплуатацияләүне конструкторлык ягыннан тәэмин итү буенча урынбасары **Головин** Андрей Анатольевичка, «70» эшләнмәсен төзекләндерү һәм яңарту производствосының очкыч аппаратлар слесаре-җыючысы **Козлов** Сергей Николаевичка, технологик җиһазлар җитештерү цехы токаре **Мусин** Евгений Валерьевичка, Ту-160 агрегат-җыю производствосының очкыч аппаратлар слесаре-җыючысы **Хәсәнов** Айрат Әхтәм улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тәтеш муниципаль районындагы «Тәтеш балкышы» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль хезмәткәре **Корсакова** Зоя Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыятенең план-икътисад бүлеге башлыгы **Идиятова** Нурия Хабри кызына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының макроикътисади фаразлау бүлеге башлыгы **Ягнова** Ирина Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Арбитраж суды судьясы **Мәҗитов** Айрат Нариман улына, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе судлар эшчәнлеген оештыру-хокукый, мәгълүмати һәм статистик тәэмин итү бүлеге консультанты **Мозаффарова** Венера Искәндәр кызына, Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Рәшитов** Илдар Зөлфәр улына, Татарстан Республикасы Арбитраж суды суд составы рәисе **Харин** Роман Сергеевичка, Казан шәһәренең Идел буе район суды судьясы **Хәсәнова** Эльвира Кәримулла кызына, Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы **Шкаликов** Роман Романовичка **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Мифтахов** Александр Григорьевичка; «Чаллы дәүләт курчак театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең курчак уйнатучы артисты, «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Морзаханова** Ландыш Рәшит кызына; «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең курчак уйнатучы артисты **Нәҗипова** Лилия Юныс кызына; «Кызыл тау» мәдәният үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Мортазин** Илгизәр Әнәс улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «Инженерлык лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы **Апраксин** Максим Сергеевичка, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Лесной авыл клубы мөдире **Вохмина** Гөлия Рашат кызына, «Мамадыш шәһәренең композитор Яруллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе концертмейстеры **Гиниятов** Рөстәм Шамил улына, «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең скрипка классы буенча укытучысы **Дәүликамова** Луиза Хамматсадыйк кызына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе аккомпаниаторы **Җәләлов** Марсель Саудахан улына, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты каршындагы Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Зарипова** Равилә Гыйльметдин кызына, «Чистай мәдәният үзәге» автоном муниципаль учреждениесенең халык ялын оештыру бүлеге мөдире **Злыднина** Динара Мансур кызына, «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең театраль дисциплиналар укытучысы **Зотин** Андрей Валерьевичка, Балтач муниципаль районы «Балтач үзәкләштерелгән авыл клубы системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 38 номерлы филиалы – Иске Көшкәт авылы клубы мөдире **Щербакова** Светлана Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Армый-талмый Буа шикәр эшкәртү заводы директоры вазыйфасын башкарган **Миннулла Идиятулла улы КЕПЕЧЕВ**ка 80 яшь тулды.

Сез – Буа шикәр заводын Россия күләмендә алдынгы заводлар рәтенә бастырган шәхес. Хезмәтегез дәүләт тарафыннан югары бәяләнеп, «Халыклар дуслыгы», «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденнарына, «Хезмәттәге казанышлар өчен» медаленә, «Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булдыгыз. Завод янында күпкатлы йортлар, яңа коттеджлар белән эшчеләрне сөендердегез.

Тормыш иптәшегез Роза Измайловна белән матур гаилә корып, ике кыз үстердегез. Гомерен балалар укытуга багышлаган хатыныгыз сезгә ныклы терәк, хезмәткә рухландыручы булды. Бүген кызларыгыз, 3 оныгыгыз сезне уңышлары белән шатландырып яшиләр. Киләчәктә дә Сезгә Аллаһы Тәгалә исәнлек-саулык, җан тынычлыгы бирсен, туар таңнарыгыз аяз һәм имин булсын.

Буа шикәр заводы җитәкчелеге,
профком, ветераннар советы

Кызыксыну

Балаларга белем бирергә дә, сыр ясап сатарга да өлгерә. Чирмешән районының Кармыш мәктәбендә география фәнен укытучы Рәмия Шәмгунова, Казанга барып, яңа һөнәр үзләштергән. Үз белгәннәрен хезмәттәшләренә өйрәтә хәзер. Эремчектән түгел, сөттән ясарга.

Бу якларга 19 ел элек Аксубай районының Яңа Үзи авылыннан килен булып килгән ул. Авылда яшәгәч, мин – укытучы, дип торып булмый, мал-туарын да асрарга, сыерын да саварга туры килә. Шәмгуновлар 4 сыер тота. Сөтен дә саталар, аннан эремчек, каймак, сырын да ясыйлар.

– Укытучы кеше бит ул гомер буе яңалыкка омтылып яши. Сыр ясауга тотыну да кызыксынудан башланды. Эремчектән әзерләгән бар иде, тик сөттән юк. Туганнарым Казанда мастер-класс уздыручы хатынны бик мактагач, тәвәккәлләргә булдым. 10 мең сум түләп, ике көн курсларда укып кайттым. Самарадан күченеп килгән белгеч әзерләү технологияләрен өйрәтте. Аның сырлары телеңне йотарлык.

Вакытың булмаса, сыр ясарга тотынмаска кирәк, дип киңәш бирә ул. Шарты туры килмәсә, эш барып чыкмаячак. Шуңа күрә ашыкмыйча эшләү хәерлерәк. Әзерләү процессы 12 сәгатькә кадәр сузыла.

– Беренчесе әллә ни искитәрлек чыкмый, тора-бара остарасың инде. Сепаратордан аерган сөт ярамый, сыр каты чыгачак. Температураны саклаудан, әчетүдән дә күп нәрсә тора. Иртәнге сөт белән кичкесе яки ике төрле температурадагы кушылса да, җае китәчәк. Сырларның нигезе бер төрле, әмма аны эшләү процессы аерыла. Озак сакланган саен тәмлерәк тә, тыгызрак та килеп чыга. Укроп кушкан бар, башка тәмләткечләр кушмыйм. Мин күбрәк тиз ашала торганнарын, ягъни сулугуни, косичка, качотта, брынза кебек төрләрен ясыйм. Авыл кешеләре дә сатып ала, әмма күбрәк Казанга җибәрәм. Химия кушмагач, табигый ризыкны тиз алып бетерәләр. Килосы – 700 сум, – дип сөйли сыр ясау остасы.

Кеше мактап ашагач, тагын ясыйсы килә, ди. Күпме продукция сатканын исәпләми. Туганнарын сыйларга да җитә, үзләре дә әлеге сыйдан өзелмиләр. Бетә башласа, балалары: «Әни, кайчан сыр ясыйсың инде?» – дия башлый икән. Тәмлене кем яратмый! Рәмия ханым тагын да күбрәк төрләрен ясарга өйрәнергә хыяллана. Юк, хезмәт укытучысы булырга җыенмый ул. Хуҗабикә бары шулай һөнәрләрен генә арттыра.

Сәрия МИФТАХОВА

РӘМИЯ ШӘМГУНОВАдан БРЫНЗА СЫРЫ РЕЦЕПТЫ

– Кәстрүлгә 20 литр сөт салып, 39 градуска кадәр җылытам. Аннан 1 стакан әчеткеч (сыворотка кибетләрдә сатыла) салам. Тигез таралсын өчен, яхшылап болгатам. Сүндергәч, 10–15 минуттан әзер ферментларны салып, яхшылап болгатып, капкачын ябып куям. Ул җылы урында торырга тиеш. 45 минуттан ойый башлый. Куерганын пластмасс бөке салып карыйм, ул йөзми башлый. Аннан кәстрүлдәге массаны шакмакларга кискәләп болгатам. Әкрен генә утта 20 минут бутап торырга кирәк. Кисәкләр яхшылап тыгызлансын, өлгерсен өчен кирәк бу. Суын агызып, төрле пластмасс формаларга куям. Анда тыгызланып тора, як-ягын әйләндерәм. Шушы формаларны мичтә 30–35 градуста бераз торгызып алам. Алгач та савытта әйләндерүемне дәвам итәм. Тыгызлангач, тозлыкка салам. Тозлыкны болай әзерлим: 5 литр суга бер кап тоз кушам. Шуңа сырны салып, ун сәгать тотам. Менә шуннан табынга куярга була.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, хатыны **Татьяна Николаевна ФОМИНА** вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы Экспертлар советы әгъзасы Фомин Анатолий Алексеевичның авыр кайгысын уртаклаша.

КПРФның Татарстан республика комитеты, партиянең Аксубай район комитеты беренче секретаре **Рәмис Вил улы САФИУЛЛИН** вакытсыз вафат булу сәбәпле, гаиләсе, балалары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Х.Г.Миргалимов, А.В.Прокофьев, А.В.Комисаров, Ф.М.Сафин, И.Р.Вәлиуллин, С.В.Федоров, М.З.Гарифуллин, С.Н.Виноградов, М.С.Сәмигуллин, Н.М. Атласов, А.В. Семенихин, А.Ә. Яһудин

МӨҺИМ ДӘРЕС

«ТАТНЕФТЬ» ТАБИГАТЬКӘ САКЧЫЛ КАРАШКА ӨЙРӘТӘ

Экология

Дөньяны үзгәртәсең килсә, үзеңнән башла. Бу сүзләрне һәммәбезнең дә ишеткәне бар. Хәтта бер генә тапкыр да түгел! Тик асылына төшенергә тырышканбызмы икән? Экологик проблемалар яссылыгында карасак, инде төшенер вакыт җиткәндер. Иң яхшысы – табигатькә сакчыл карашны балачактан тәрбияләү. «Татнефть» шул эшкә алынган да инде. Табигать хакына, киләчәк хакына.

tatneft.ru

«Татнефть» экология һәм социаль үсешкә бәйле мәсьәләләргә һәрвакыт җитди карады. Компания нигезе, аның фәлсәфәсе дә шуңа корылган. Әйләнә-тирә мохитне саклауга зур игътибар бирү дә кичә-бүген генә барлыкка килгән сәясәт түгел. 2015 елдан «Татнефть» тотрыклы үсеш максат һәм принципларын (ЦУР. – **Ред.**) тормышка ашыра (барлыгы 17 максат. – **Ред.**). 2019 елдан исә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Глобаль килешүенә дә кушылды.

Максатларның күбесе табигатькә, әйләнә-тирәгә сакчыл караш тәрбияләүгә юнәлгән. Моны балачактан башлау җиңелрәк тә, дөресрәк тә. Балаларның күңелләренә салынган орлык киләчәктә нәтиҗәсен бирми калмас.

Шуның өчен дә «Татнефть»нең тотрыклы үсеш максатлары илчеләре 2020 елдан махсус программа буенча укыту эшләре белән шөгыльләнә. Илчеләр – компаниянең волонтер булырга ризалашкан хезмәткәрләре, Әлмәт югары уку йорты студентлары. Аларны корпоратив институтта махсус өйрәтәләр. Аннары алар үзләре мәктәп укучыларын өйрәтә. Әлеге чара «Иң мөһим дәрес» дип атала.

Юлия Даньшинаны табигать һәм әйләнә-тирәне саклау мәсьәләләре һәрвакыт кызыксындырган. Әле былтыр гына ул Әлмәттә узган II Халыкара Нефть-газ яшьләр форумының HOT Challenge хакатонында катнашкан. Командада көнкүреш каты калдыкларын юк итү турында фикер алышканнар.

– Бу проблемага битараф кала алмадым. Пластикны эшкәртү мәсьәләсен тирәнтен өйрәнә башладым, шул рәвешле шәһәрләребезнең нинди аяныч хәлдә булуын аңладым, – ди ул. – Тәрбияне балалардан башларга кирәк дип уйладым. Алар белән эшләү, аңлату җайлырак. Олыраклар белән килешү кыенрак шул… Әмма нидер эшләргә кирәк!

Алия Сәләхова да волонтерлар сафына бөтен дөньяны борчыган мәсьәләләргә битараф булмавы нәтиҗәсендә кушыла.

– Компаниянең тотрыклы үсеш максатларын гамәлгә ашыруда үз өлешемне кертәсем килде. Дөньякүләм проблемаларны ялгызың гына чишә алмыйсың. Әмма һәр кеше үзеннән күпмедер өлеш кертсә, үзгәртергә тырышса, ни буласын күз алдыгызга китереп карагыз әле! – ди ул. – Баштарак куркытты, чөнки халык алдында чыгыш ясау осталыгым да юк иде, теманы да яхшы белмим төсле тоелды. Институтта әзерлек вакытында күп нәрсәләргә ачыклык керде. Шунда укыганда үзем дә чүпне аерым җыя башладым. Мәктәптәге беренче чыгышым балаларны кызыксындырганын күреп, программаның нәтиҗәлелегенә инандым.

Илчеләрне укыту программасы турында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да сөйләделәр. Республика җитәкчесе аны югары бәяләде һәм Татарстанның һәр мәктәбендә шундый дәресләр узсын иде дигән теләген белдерде. Моның өчен битараф булмаган кешеләрнең – волонтерларның икенче төркемен туплаганнар, аларны укыту башланган да инде. Февраль аенда мәктәп укучылары белән экран аша гына очрашулар чын очрашуга әверелер дигән өмет бар. Ә әлегә балаларны ZOOM аша укыталар. Онлайн дәресләр 17 гыйнвардан башланган. 5–6 сыйныф укучылары «Иң мөһим дәрес»тә ачлык, су җитмәү, планетаны пластиктан арындыру кебек җитди мәсьәләләр турында уйлана. Беренче атнада әһәмиятле дәрестә 340 мәктәптән 13593 бала катнашкан.

2021 елда илчеләр бу программа буенча Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы, Казан һәм Тольятти шәһәрләрендәге 64 мәктәптә 6 меңнән артык бала өчен дәрес оештырган. 2022 елда «Татнефть» программаны җәелдерергә ниятли. Быел мөһим мәсьәләләр турында республиканың 1 меңләп мәктәбендә 97 меңләп укучыга сөйләргә телиләр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯШЬЛЕККӘ КАЙТУ

Соклану

Яшел Үзән районының Норлат авылында яшәүче өлкәннәрне республикада да беләләр. «Яшь йөрәкләр» дип аталган төркемгә йөрүчеләрнең иң яшенә – 50, иң олысына – 83 яшь. Төркемне Ләлә Хаҗипова җитәкли.

– Картаерга вакыт юк безнең, – дип башлады сүзен Ләлә апа. – Башта Чаллыда, аннары Алабугада яшәдем һәм төрле җитәкче урыннарда эшләдем. Пенсиягә чыккач, авылга кайтырга уйладым. Кайттым да өлкәннәрне бергә җыясым килде. Иң элек Болгар белән Биләргә сәяхәткә бардык. Әнә шуннан аерылышмадык инде.

Ләлә апаның максаты – пенсиядәге кешеләрне дөньяга чыгару. Авылга кайткач, күрә ул: өлкәннәрнең күбесе үзләренә вакыт таба алмый, тормышлары йорт мәшәкатьләре белән чикләнгән. Гомерләре эш дип, баланы аякка бастырам, дип үткән әби-бабайларны, картлыкларында булса да, үз кадерләрен күрергә өйрәтәсе иде бит.

– Баштарак аңламаучылар да табылды. Янәсе, бу хатын әбиләрне үзенә файда булганга җыя инде. Ә минем авылым өлкәннәрен яшәртәсем, тормышка карашларын үзгәртәсем килде. Тора-бара эшебезне күрделәр, аңладылар, – ди ул.

Өлкәннәрнең очрашулары, бергә җыелып, бәйрәм үткәрүдән башлана. Аннары скандинавча йөрергә өйрәнәләр. Кышын чаңгыга басалар, тауда чана шуалар. Күрше Чувашия Республикасына – бассейнга, атнасына бер тапкыр авыл спортзалына йөриләр. Ләлә апа әйтүенчә, спорт белән шөгыльләнә башлагач, әбиләрнең авырулары кимегән. Йокысызлыктан интегүчеләр дә юк икән хәзер.

– Спорт күнегүләрен үзем ясатам. Әбиләрнең яшьләрен исәпкә алып, буыннарга файдалы күнегүләр сайлыйм. Баштарак авыл кешесенә таяк тотып йөрү сәер тоела иде. Хәзер менә кан басымының җайлануын белеп, безгә күрше авыл кешеләре дә ияреп чыгалар. Хәрәкәтнең файдасы күп, – ди Ләлә апа.

Авылдашы Фәрдәнә әбигә 83 яшь. Ул да «Яшь йөрәкләр» төркеменә йөри. Әбинең балалары читтә яши.

– Моңарчы ничек яшәдем икән? – дим. – Ләлә кайтканчы, мин тәрәзәдән урамны күзәткән песи кебек идем. Беркая чыкмадым. Аллаһы Тәгалә Ләләне безнең бәхеткә авылга кайтарган. Аңа ияргәннән бирле бөтенләй үзгәрдем. Өемдә җаныма тынычлык тапмыйм, эчем поша. Ә кызлар белән очрашсам, җаным ял итә. Бар авыруларым, борчуларым юкка чыга, кире яшьлеккә кайткандай булам, – ди ул.

Ләлә апа әбиләрне кайларга гына алып бармый! Казанны да күргәннәр. Яңа ел алдыннан ике ел рәттән Казансу яры буенда ял иткәннәр. Төп чыршыны да карап кайтканнар. Әбиләрнең бу матурлыкны күреп күзләре дымланган.

– Аларның күңелен күрсәм, үземнең дә эшем уңа. Казанга театр-концертка барсак, ресторан-кафеларга алып барырга тырышам. Алдан шеф-поварны чакырып сөйләшәм. Өлкәннәр арасында 8 мең сум пенсия алучылар да бар икәнлеген искәртәм. Хәлгә керәләр, бер ресторан хуҗасы әбиләрне 300 сумга ашатып чыгарды. Ә менә «Ак барс» хоккей командасы уйнаганда, уенчыларга оекбашлар бәйләп алып бардык. Догалары кабул булды, ул көнне җиңделәр, – ди Ләлә апа.

2018 елда алар Россия Президенты грантында катнашырга булалар.

– Аңарчы ярдәм сорап кая гына бармадым. Ләкин буш кул белән кайтып китәргә туры килә иде. Шуннан соң уйлаштык та улым исеменә коммерцияле булмаган социаль оешма ачтык. Грант алуның тәртибен интернеттан өйрәндем. Төннәр буе яздым. Гаризаны җибәргәч тә, бер кешегә әйтмәдем. «Яшел Үзән районы әбиләрен кем белсен дә аларны грантка кем уздырсын инде?» – дип өметемне өзгән идем. «Сез җиңдегез», – дигән хәбәр килгәч, шаккаттым. 500 мең сумлык грант оттык. Бу акчаны тиененә кадәр өлкәннәр өчен тотым, – ди Ләлә Хаҗипова. – Акчага төркемдәгеләр өчен 15 велосипед, чаңгылар, скандинавия таяклары, флешкалар, музыка уйнатыр өчен колонка, бөҗралар, башка кирәк-ярак алдык, – ди ул.

Быел алар тагын шушы ук грантны откannар. Бу акчаны авыл туризмын үстерергә тотарга җыеналар. Норлатта туристларны кызыксындырырлык урыннар байтак. Үзләрендә этнография музее булса, күрше Ачасырда – Каюм Насыйри музей-утары. Җәй көне ял итәр өчен мөмкинлекләр тагын да зуррак, диләр. Норлат әбиләренең укучыларга әйтер сүзләре дә бар. «Яшәп калыгыз, үзегезне яратыгыз, дөнья күрегез», – ди алар. Хәрәкәттә бәрәкәт шул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 225

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ 2021 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

Кереш

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турындагы әлеге еллык доклад 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында»гы Татарстан Республикасы Законының 26 нчы маддәсенә ярашлы рәвештә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Конституция суды рәисенә, Татарстан Республикасы Югары суды рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

Доклад әзерләгәндә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрдән килгән шикаятьләр, Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мәгълүматлары, шулай ук Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре тәкъдим иткән мәгълүматлар, хокук саклау оешмаларыннан килгән яки массакүләм мәгълүмат чараларында басылган кеше хокукларын бозу турында мәгълүматларны тикшерү йомгаклары, республика ведомствоара комиссияләр материаллары һәм башка чыганаклар анализланды.

Докладта Вәкаләтле вәкилнең 2021 елгы эшчәнлегенең статистика мәгълүматлары китерелде. Шуның белән бергә, докладта гражданнарның сайлау, социаль хокукларын яклау буенча, мәҗбүри тоту урыннарында гражданнар хокукларын яклау буенча, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә агарту буенча кайбер проблемалы мәсьәләләр чагылыш тапты. Доклад структурасы боларга туры килә торган бүлекләрне үз эченә ала, ә аның йомгаклау өлешендә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны көчәйтүгә юнәлтелгән кайбер чараларны тормышка ашыру мөмкинлеген карарга тәкъдим ителә. Әлеге тәкъдимнәр хокук яклау эшчәнлеген камилләштерергә мөмкинлек бирер, дип ышанабыз.

1 бүлек. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре мониторингы

Вәкаләтле вәкилгә ел дәвамында килгән мөрәҗәгатьләрне (гаризаларны, шикаятьләрне, тәкъдимнәрне), «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мөрәҗәгатьләрен, социаль челтәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган яисә «ГЛОНАСС+112» системасы аша җибәрелгән мәгълүматны анализлау Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә хәлне бәяләүнең төп инструментларының берсе булып тора.

2021 елда Вәкаләтле вәкил адресына республикада яшәүчеләр 6195 тапкыр мөрәҗәгать иттеләр. Язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны – 3692, шулардан: почта элемтәсе аша – 692 мөрәҗәгать, электрон почта аша – 473, интернет-кабул итү бүлмәсе аша – 576, халыктан турыдан-туры – 286, телефоннан шалтырату буенча – 533, ГЛОНАСС аша 436 мөрәҗәгать алынды.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең төп өлеше – Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

Вәкаләтле вәкилгә Казан, Чаллы кебек зур шәһәрләрдә яшәүчеләр генә түгел, муниципаль районнарда яшәүчеләр дә, бигрәк тә Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Яшел Үзән, Түбән Кама районнарында яшәүчеләр еш мөрәҗәгать итә. Вәкаләтле вәкилгә шулай ук Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә: Краснодар краенда, Пермь һәм Саратов өлкәләрендә, Башкортстан Республикасында яшәүчеләр яки килүчеләр дә мөрәҗәгать итә.

Узган еллардагы кебек, вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарны атналык шәхси кабул итү генә түгел, ә хисап чорында вәкаләтле вәкил тарафыннан 485 кеше шәхсән кабул ителгән бердәм тематик кабул итү үткәрү практикасы да дәвам итте. Коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау белән бәйле чикләү чаралары гамәлдә чакта, Вәкаләтле вәкил, аның Аппараты хезмәткәрләре Skype, Zoom, WhatsApp яисә телефон элемтәсе аша видеоэлемтә режимында гражданнарны кабул итүне тормышка ашырды.

2021 елда вәкаләтле вәкил тарафыннан 40 шәхси кабул итү булды (229 граждан кабул ителгән) һәм 24 уртак тематик кабул итү уздырылган (256 граждан кабул ителгән).

Күрсәтелгән чорда Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе белән (20.02.2021 – 13 мөрәҗәгать, 14.05.2021 – 10 мөрәҗәгать, 06.08.2021 – 5 мөрәҗәгать, 27.12.2021 – 14 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасында дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе белән (02.02.2021 – 4), Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе белән (06.08.2021 – 7 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән (16.03.2021 – 9 мөрәҗәгать, 14.09.2021 – 8 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы прокуратурасы белән (18.03.2021 – 39 мөрәҗәгать, 07.09.2021 – 9 мөрәҗәгать, 10.12.2021 – 7 мөрәҗәгать), Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстандагы тикшерү идарәсе белән (19.04.2021 – 15 мөрәҗәгать, 27.10.2021 – 12 мөрәҗәгать, Чаллыга барып кабул итү, 09.11.2021 – 13 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән (15.06.2021 – 10 мөрәҗәгать), Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан төбәк бүлеге һәм »Татарстан Республикасы буенча баш медик-экспертиза бюросы» учреждениесе белән (13.04.2021 – 6 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән (31.05.2021 – 7 мөрәҗәгать), Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге белән (24.08.2021 – 4 мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты белән (26.08.2021 – 1 мөрәҗәгать) уртак тематик кабул итүләр оештырылды.

Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы прокуратурасы, 16 нчы медик-санитар часте, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстандагы идарәсе вәкилләре, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер-министрының хокук саклау һәм административ эшчәнлек буенча ярдәмчесе Д.Хамадишин белән берлектә, видеоконференцэлемтә (телемедицина) системасын кулланып, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 8 нче, 10 нчы, 19 нчы төзәтү колонияләре, 17 нче КП медицина частьләренә кушылып, хөкем ителгәннәрне дүрт читтән торып кабул итү үткәрде. Аларда 31 тоткын шәхси сораулары буенча консультация алды.

Гражданнарның телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләре белән эшләү – Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе. Вәкаләтле вәкил Аппаратына көн саен килә торган корреспонденцияләрне анализлау дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар ягыннан комплекслы хәл итүне һәм актив игътибарны таләп итүче системалы проблемаларны билгеләргә мөмкинлек бирә.

Проблемалы урыннарны ачыклау һәм гражданнар белән актив эшләү өчен Вәкаләтле вәкил Аппараты даими рәвештә «кайнар элемтә»ләр үткәрә.

2021 елда 9 «кайнар элемтә» үткәрелде: җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә гражданнар хокукларын үтәү мәсьәләләре буенча (29.07.2021 – 10 шалтырату), белем алучыларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча (10.09.2021 – 138 шалтырату), 2021 елда сайлауларга әзерләнү һәм үткәрү чорында гражданнарның сайлау хокукларын яклауны күзәтү мәсьәләләре буенча (09 – 19.09.2021 – 73 шалтырату), мәгариф учреждениеләрендә туклану оештыру буенча (20.02.2021 – 104 шалтырату), сәламәтлекләре чикле кешеләр хокукларын яклау мәсьәләләре буенча (09.04.2021 – 98 шалтырату), чакырылыш вакытында гражданнарның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча (02.04.2021 – 10 шалтырату, 20.10.2021 – 5 шалтырату), торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча (30.11.2021 – 71 шалтырату), гражданнарның хезмәткә хокукларын яклау мәсьәләләре буенча (23.11.2021 – 5 шалтырату).

«Кайнар элемтә» вакытында гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр телефоннан кабул ителгән мөрәҗәгать рәвешендә карточка итеп теркәлеп, алга таба карау һәм мөрәҗәгать итүчеләргә җавап бирү өчен Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары карамагына җибәрелә. Без 95 шундый мөрәҗәгать буенча запрослар җибәрдек.

tatarstan.ru

Килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләп, Вәкаләтле вәкил гражданнар шикаятьләре буенча чаралар күрү өчен законда каралган төрле инструментларны куллана: тикшерүләр үткәрә, судларга юлламалар җибәрә, тәкъдимнәр, запрослар җибәрә.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил Аппаратның гражданнарның хокукларын торгызу, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасыннан кулланучылар белән эшләүне координацияләү бүлеге хезмәткәрләре белән бергә 550 тикшерү үткәрде, шул исәптән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

– гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә белемгә хокуклар бозылу («371 нче балалар бакчасы» ораль полиомиелит вакцинасы кадаткан балаларны аеруга шикаять; Казан шәһәренең Киров районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 135 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», Арча муниципаль районының Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре Совет районының «187 нче күп профильле лицее», Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», Әлмәт шәһәренең «12 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», «Россия Герое А.В.Козин исемендәге 7 нче гимназия», педагогик процесста катнашучылар арасында низаглы хәл; Казан шәһәренең Киров районы «182 нче политехник лицее» – баланы беренче сыйныфка алудан баш тарту; Казан шәһәренең Совет районы «11 нче күп профильле лицее», физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен уку процессын тиешенчә оештырмау);

– медицина ярдәме алуга хокуклар бозылу («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы балалар республика клиник хастаханәсенең 2 нче консультатив сырхауханәсе, табиб эше; «Академик В.М. Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» филиалы, мөрәҗәгать итүченең кызын тоту шартларыннан, дару препаратлары билгеләгән табиблар эшеннән риза булмау);

– торак-коммуналь хуҗалык тармагы эше («Уңайлы йорт» идарәче компаниясе, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүне дөрес исәпләмәү, тиешенчә хәбәр итмичә торак бинасында электр белән тәэмин итүне туктату);

– торак белән тәэмин итү (махсус торак биналары наймы килешүләре буенча махсус торак фондыннан торак белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертүдән баш тарту);

– хөкем ителгәннәрнең, кулга алынган гражданнарның матди-көнкүреш шартлары белән танышу (республиканың төзәтү учреждениеләрендә – 11, тикшерү изоляторларында 7 тапкыр булдык) һәм башкалар.

Хисап чорында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларның җаваплы вазифадагы затларына һәм оешмаларга, Вәкаләтле вәкил гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү учреждениеләре эшчәнлегендә мәгариф өлкәсендәге бозылган хокукларны торгызу кирәклеге турында кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрде (мисал өчен, граждан Б. мөрәҗәгатьләре буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсенә), граждан С. мөрәҗәгате буенча Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсенә, граждан Ф. мөрәҗәгате буенча Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенә), сәламәтлек саклау өлкәсендә (граждан Ж. мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Балалар республика клиник хастаханәсе»нә), торак өлкәсендә (граждан М.шикаяте буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына) һәм башкалар.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкилнең шундый 40тан артык тәкъдиме юлланды.

Вәкаләтле вәкил «ГЛОНАСС+112» системасы аша кабул иткән мәгълүмати хәбәрләр саны 2503не тәшкил итте. Аларның төп өлеше – (1166сы) торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән бәйле (тиешенчә хезмәт күрсәтмәү, идарәче оешмалар эшчәнлеге, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүдәге өзеклекләр яисә тулысынча су белән тәэмин ителмәү, гомуми мөлкәтне тоту һ.б.); медицина ярдәмен күрсәтмәү (386) (дару препаратлары булмау, табибларга язылу мөмкинлеге булмау, ашыгыч медицина ярдәме эше); гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны яклау мәсьәләләре, шулай ук балаларының өлкән яшьтәге ата-аналарын тәрбияләү бурычын үтәмәү белән бәйле (гаилә әгъзаларына карата физик һәм психологик җәбер, балаларны, өлкәннәрне куркыныч астына кую).

Вәкаләтле вәкил Аппаратына «ГЛОНАСС+112» системасы аша Х. гражданның авыр тормыш хәле турында мәгълүмат килде.

Мөрәҗәгать итүче янына баргач, аның балачактан инвалид булуы, урамга чыкмыйча йорт буенча гына хәрәкәт итүе, үз акчасына сатып алына торган махсус эчке киемнән файдалануы ачыкланды.

Килеп туган вазгыятьне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләүнең шәхси программасын эшләүдә булышуны сорап, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча баш медик-социаль экспертизасы бюросы» җитәкчесенә хат юллады. Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча баш медик-социаль экспертизасы бюросы» мәгълүматы буенча, Х. 1999 елда ул вакытка гамәлдә булган законнар нигезендә инвалид итеп расланган, ул вакытта шәхси программа эшләнмәгән.

Шәхси программа эшләү өчен Х. гражданга хәзерге вакытта мөрәҗәгать итүченең сәламәтлеге торышыннан чыгып, белгечләре кирәкле медицина документлары рәсмиләштерүгә вәкаләтле медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә һәм гражданны шәхси программа эшләү өчен Баш бюрога җибәрергә тәкъдим ителде.

Х. гражданның проблемасын хәл итү өчен аның гаризасы күчермәсе Баш бюро Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелде.

Хисап чорында гражданнардан Вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрдә 4067 мәсьәлә күтәрелде.

2021 елда популярлык һәм мөһимлек буенча беренче урында «Социаль, икътисадый һәм мәдәни хокукларны һәм ирекләрне яклау» блогы, әлеге проблема буенча сораулар саны – 1874. Әлеге блокка хокукларның түбәндәге төркемнәре керә.

1. Торакка хокук – 648 мөрәҗәгать.

Гражданнар, барыннан да элек, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүне исәпләү, идарәче оешмалар тарафыннан сыйфатсыз хезмәтләр күрсәтү, күпфатирлы йортларда агымдагы һәм капиталь ремонт үткәрү, торак бирелмәү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итте. Бу һәм башка күп кенә мәсьәләләр авыр һәм даими контроль таләп итүче мәсьәләләр булып кала.

Вәкаләтле вәкил адресына ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торакка хокукларын яклау һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча күп мөрәҗәгатьләр килә.

Әлеге төргә кергән гражданнардан килгән һәр мөрәҗәгать эшнең барлык шартларын исәпкә алып, аерым бер дулкынлану белән җентекләп өйрәнелә.

Ноябрьдә Вәкаләтле вәкил адресына ятим балалар төренә карый торган Казан шәһәре кешесе, аны ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлегенә һәм аларның махсус торак фондында торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле кешеләре исемлегенә кертүдә ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте.

Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, мөрәҗәгать итүче вәкаләтле органга беренче мөрәҗәгать итү көнендә үк әлеге исемлеккә кертелде.

Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны кызы, Б. гражданканың әнисе фатирында яшәү шартлары канәгатьләнерлек булмавы турындагы мөрәҗәгате буенча, 2021 елның 21 июнендә Вәкаләтле вәкил анда яшәү шартлары белән танышу максатында сугыш ветераннары өчен төзелгән махсуслашкан муниципаль йортта булды. Очрашуда йорт мөдире һәм идарәче компания вәкилләре катнашты. Мөрәҗәгать итүченең әнисе – Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны белән очрашу барышында яшәү шартларына шикаятьләр кермәде.

Әмма Вәкаләтле вәкил тарафыннан кайбер тәкъдимнәр һәм кимчелекләр әйтелде, шул исәптән идарәче компаниягә тәрәзә блокларының тыгыз ятуына игътибар итәргә һәм көзге чорда фатирларда җылылык саклауны тәэмин итү һәм йортта яшәүчеләрнең торак-коммуналь түләүләре дәрәҗәсен киметү максатларында аларның герметиклыгын тикшерергә тәкъдим ителде, шулай ук мөрәҗәгать итүченең әнисенең фатирында плинтусларны алыштыру турында үтенеч белдерелде.

2. Социаль тәэмин итүгә хокук – 365 мөрәҗәгать.

Мөрәҗәгатьләрнең әлеге төре инвалидларны пенсия белән тәэмин итү, социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча шикаятьләрне («уңайлы тирәлек» булдыру, инвалид дип тану, техник тернәкләндерү чаралары, шифаханә-курорт тәэминаты), гражданнарның төрле төрләренә ташламалар, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә булу һәм башкаларны үз эченә ала.

Балалар лагерена юллама сатып алганда «кэшбэк» кулланылу турындагы акцияне белгәч, гражданка В. оныкларына бүләк ясарга була, балалар лагерена юлламалар сатып ала. Әмма балалар лагере өчен юллама бәясенең 50 процентын кире кайтару өчен мөрәҗәгать иткәндә, үтенече юлламаларның турыдан-туры балалар ялын оештыручы оешмада түләнүенә бәйле рәвештә кире кагылган. Шул ук вакытта, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2021 елның 19 маенда дөнья күргән 759 нчы карары нигезендә, акчаларны кире кайтару өчен туроператор аша юллама түләү мәҗбүри шарт булып тора. Әлеге сорау буенча гражданка төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать иткән, әмма һәркайда баш тартканнар. Шуннан соң ул Вәкаләтле вәкилгә мәсьәләне хәл итүдә мөмкин булган ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте. Безнең катнаштан соң мәсьәлә уңай хәл ителде.

3. Хезмәткә хокук – 153 мөрәҗәгать.

Гражданнар хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе, эштән китәргә мәҗбүр итү, иректән мәхрүм итү урыныннан азат ителгән, инвалид статусы булган аерым гражданнарны эшкә урнаштыру катлаулыгы турында мөрәҗәгать иттеләр.

4. Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокук – 246 мөрәҗәгать. Мөрәҗәгатьләрнең күбесе дәвалау-профилактика ярдәме һәм дарулар белән тәэмин итү белән бәйле иде.

Февральдә Вәкаләтле вәкилгә граждан П. үзен һәм хатынын, 3 нче һәм 2 нче төркем инвалидларны дару препаратлары белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте. Алар берничә ай буе ташламалы даруларын алмаган.

Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре чикләрендә карар кабул итүне сорап Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хат җибәрде.

Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче телефон аша хәбәр итте, аларга дару препаратлары бирелгән.

5. Белем алуга һәм мәдәни кыйммәтләрдән файдалануга хокук – 348 мөрәҗәгать.

Әлеге төр буенча мөрәҗәгатьләр статистикасына үткәрелгән анализ шуны күрсәтә: мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар булмау, баланы мәктәпнең беренче сыйныфына алудан баш тарту, балаларны укырга куркынычсыз йөртүне оештыру, сәламәтлеге чикле балаларга белем бирү белән бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкилгә шикаятьләр килү дәвам итә.

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре системасында белем алуга хокук аерым урында тора. Белем дигәндә кеше, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренә юнәлтелгән тәрбияләү һәм укыту процессы контрольдә тотыла.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкилгә уку йортларында белем бирүне оештыруга, белем бирүдә катнашучылар арасында низаглы хәлләр булуга шикаятьләр килде. Вәкаләтле вәкил фикеренчә, мондый хәлләргә юл куярга ярамый һәм бу низаглы хәлләрне тирәнәйтү һәм арттыру очракларына юл куймау өчен урынга барып мәҗбүри тикшерүне, шулай ук мәктәп хакимияте һәм укытучыларның укучыларның ата-аналары белән эш ысулларын өйрәнүне таләп итә.

Мәгариф оешмалары биналарының торышы турындагы мәсьәләне кузгатмыйча ярамый. Белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын даими яңарту һәм төзекләндерү аларның устав бурычларын гамәлгә ашыру өчен мөһим шарт. Сыйфатлы белем алу бары тик уңайлы һәм барлык санитария таләпләренә җавап бирә торган биналарда гына мөмкин – бу үсеп килүче буынның иминлеге нигезе.

Мартта Вәкаләтле вәкилгә Менделеевск шәһәренең балалар бакчасында капиталь ремонт үткәрү үтенече белән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ата-аналары мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьтә хәбәр ителгәнчә, балалар бакчасы бинасы 1987 елда файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт үткәрелмәгән, 2012 һәм 2015 елларда агымдагы ремонт эшләре генә үткәрелгән. Мөрәҗәгать иткән вакытка, 10 нчы, 13 нче төркемнәрдә һәм музыка залында түбә ага, еш су агу нәтиҗәсендә обойлар купкан, юештән штукатуркага зыян килгән, төркемнәрдә дымлылык югары, бу балаларның сәламәтлегенә начар йогынты ясый.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгына хатлар җибәрде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау программасына кертүгә муниципаль берәмлек тарафыннан гаризалар кермәгән. Шунлыктан балалар бакчасын капиталь ремонт программасына кертү мәсьәләсе каралмаган.

Район хакимиятенең балалар бакчасына капиталь ремонт ясауны оештыру бурычларын тиешенчә үтәмәве факты буенча Вәкаләтле вәкил өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск районы прокурорына хат юллады. Прокурор тикшерүе нәтиҗәләре буенча прокурор чаралар күрде. Муниципаль районнан алынган мәгълүматка караганда, күрсәтелгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасы «2022 елда мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау» программасына кертелгән.

2021 елда кеше хокукларын бозуның масштаблы, ә кайвакыт фаҗигале очраклары да игътибарсыз калдырыла алмады.

2021 елның 11 маенда Казанда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә кылынган аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә бөтен Россияне тетрәткән вакыйгаларга бәйле рәвештә, вәкаләтле вәкил адресына Казандагы «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә һәлак булганнарның һәм зыян күрүчеләрнең гаиләләренә ярдәм чаралары буенча да, шулай ук корал йөртү һәм сату өлешендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен катгыйландыру буенча чаралар күрү мәсьәләләре буенча да гражданнар мөрәҗәгатьләре килде.

Һәлак булганнарның һәм зыян күрүчеләрнең гаиләләренең вәкаләтле әгъзаларына фаҗига урынында һәм һәлак булганнарның мәетләрен танып белү чорында ярдәм (психологик ярдәм, юридик мәсьәләләр буенча консультацияләр, озату) күрсәтелгән.

Республикада Татарстан Республикасы Президенты кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 11 маендагы 882-р номерлы күрсәтмәсе кабул ителде, анда Казан шәһәрендә 11.05.2021 елда кылынган аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм түләү тәртибе расланган иде.

Күрсәтелгән күрсәтмә белән бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү түбәндәгечә билгеләнде:

– Казан шәһәрендә 2021 елның 11 маенда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба – һәлак булучының (вафат булучының) гаилә әгъзаларына (хатынына), балаларына, ата-аналарына (законлы вәкилләренә) һәм һәлак булучының (вафат булучының) иждивениесендә булган затларга (вафат булучының) аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә кылынган һәр гаилә әгъзасына (вафат булучының) 1,0 млн сум күләмендә;

– аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә сәламәтлеккә авыр һәм уртача авырлык алган гражданнарга – 400,0 мең сум күләмендә, аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә сәламәтлеккә җиңелчә зыян алган гражданнарга – бер кешегә 200,0 мең сум (алга таба – сәламәтлеккә зыян алган гражданин).

Фаҗигадән соң, мәктәп укучыларыннан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 56 гимназия хезмәткәре түләүләр алды.

Җәй көне Кара диңгездәге лагерьда 600дән артык бала ял итте, 236 кеше Татарстан шифаханәләрендә сәламәтлеген торгызды, 30га якын бала республика лагерьларында булды.

Бик кыска вакыт эчендә бинаның эче һәм тышы төзекләндерелде, ә гимназия территориясендә үз бассейны барлыкка килде.

Вакаләтле вәкил тарафыннан «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына граждан коралының аерым төрләрен сатып алу хокукы барлыкка килгән яшен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты буенча тәкъдимнәр җибәрелде.

6. Гаиләне, аналарны, аталарны һәм балачакны яклауга хокук буенча – 64 мөрәҗәгать.

Мөрәҗәгатьләр нигездә балаларга карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яисә ата-ана хокукларыннан чикләү, ата-ананың берсенең бала белән аралашу тәртибен билгеләү, опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләренең эшенә кагылышлы мәсьәләләр буенча алынды.

Балаларны кайгырту – ата-аналарның иң мөһим бурычы. Балигъ булмаган балаларның хокукларын яклап, дәүләт һәм җәмгыять аларның физик, акыл һәм әхлакый үсеше өчен уңай шартлар тудыра.

Вәкаләтле вәкил Аппаратына балигъ булмаган баланы тәрбияләгәндә ата-ананың бурычларын тиешенчә үтәмәве һәм спиртлы эчемлекләр куллануы турында аноним мәгълүмат килде.

Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Совет районы хакимияте башлыгына хәлне ачыклау, балигъ булмаган баланың яшәү шартларын тикшерү өчен мәгълүмат җибәрде.

Кызганычка, хәбәрдә күрсәтелгән фактлар расланды.

Балигъ булмаган кыз әнисенең тәртибе Казан шәһәренең Совет районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә РФ КоАП 5.35 маддәсенең 1 өлеше буенча каралган инде. Гаиләдәге вазгыять шулай ук Казан шәһәре Совет районының муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы утырышында каралган, анда гаиләне ведомствоара исәпкә кую турында карар кабул ителгән.

Профилактика эше кысаларында балигъ булмаган баланың әнисе белән вазифаларын тиешенчә үтәү кирәклеге турында әңгәмә үткәрелгән. Гражданка З., балигъ булмаган баланың әнисе, әгәр спиртлы эчемлекләр кулланса, законга ярашлы рәвештә аңа соңгы чаралар күреләчәге турында кисәтелгән.

Хатта гражданка З.ның Казан шәһәре Совет районы муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумына алкоголь бәйлелегеннән дәвалануы турында белешмә тәкъдим итүе турында әйтелгән.

7. Уңайлы әйләнә-тирә мохитка һәм җиргә хокук – 50 мөрәҗәгать.

Сораулар атмосфера һавасын пычратуга, чүп полигонының атмосфера һавасы сыйфатына йогынтысына, җир

бәхәсләренә, суны саклауга һәм башкаларга кагылды. Әлеге төр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрендә күтәрелгән сораулар аз булуга карамастан, мөрәҗәгать итүчеләр белдергән проблемалар көн кадагында.

Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә элеккечә үк санитар-эпидемиологик законнар таләпләрен бозу киң таралган проблема булып кала, алар атмосфера һавасының пычрануына, шул исәптән, пычратучы матдәләрнең тиешле концентрациядән артуына китерә. Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәлә белән соңгы елларда ныклап шөгыльләнә.

Вәкаләтле вәкилгә берничә тапкыр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында «Яратель» кошчылык фабрикасының биологик калдыкларны (кош тизәген) тиешенчә урнаштырмавы буенча мөрәҗәгать иттеләр, бу исә һаваның пычрануына китерә. Әлеге проблема буенча Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында берничә мөрәҗәгать басылып чыкты, Лаеш муниципаль районының Столбище авылыннан килгәнен 180нән артык кулланучы яклады, бу әлеге хәлнең чынлап та гражданнарны нык борчуын раслый.

Әлеге шикаятьләр буенча, Вәкаләтле вәкилгә җибәрелгән Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы мәгълүматы буенча, контроль-күзәтчелек органнары тикшерүләр уздырган, алар барышында кошчылык фабрикасы ягыннан закон бозулар расланган, административ хокук бозу турында эш кузгатылган, аның буенча гаепле зат җаваплылыкка тартылган.

Шулай ук, Зәй муниципаль районы Перцовка авылындагы «Завод ТЕХНО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять карамагындагы сәнәгать предприятиесенә һаваны пычрату мәсьәләсе буенча Вәкаләтле вәкил исеменә килгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенә җибәрелде, нәтиҗәдә, мөрәҗәгать итүдә бәян ителгән фактлар расланды, һәм күрсәтелгән юридик зат административ җаваплылыкка тартылды, шулай ук аның адресына ачыкланган хокук бозуны бетерүне сорап күрсәтмә җибәрелде.

Популярлык һәм мөһимлек буенча «Җинаять процессында, мәҗбүри тоту урыннарында, административ хокук бозулар турында эшләр буенча кеше хокукларын яклау» блогы икенче булды – 778 мөрәҗәгать.

Россия Федерациясе субъектларындагы Вәкаләтле вәкилләр, җинаять-суд эшләрен гамәлгә ашыручы органнарның вазыйфадагы затлары булмаса да, Вәкаләтле вәкил шикаятьләрне карый торган субъектлар даирәсенә кермәсә дә, гаделлек хакына шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хисап чорында җинаять эшләре кузгатуның нигезсез булуына карата, судта эшләрне озак карау, тикшерү гамәлләренең законлылыгы, җинаять эшләре буенча хөкем карарларының законлылыгы, гаделлеге һәм нигезлелеге буенча шикаятьләр (мөрәҗәгатьләр, гаризалар) килү дәвам итте.

Дәлилләрне тикшерү өчен гражданнар мөрәҗәгатенең нигезләре булган очракта, мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы прокуратурасы һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасында төзелгән килешү нигезендә прокуратура органнарына җибәрелә.

Вәкаләтле вәкил Аппаратына транспорт чаралары кую урыны кагыйдәләрен бозган өчен административ җәза билгеләүләре турында аңа чыгарылган карардан риза булмавы турында Ф. гражданнан шикаять килде.

Мөрәҗәгать итүче нотариус хезмәте алганда Казан шәһәренең Вишневский урамында үз транспорт чарасы белән туктап торган өчен өч тапкыр административ рәвештә штрафка җәлеп ителүе турында хәбәр итте. Ул инвалид һәм йөрәге белән проблемасы булган кеше буларак, инвалидлар өчен урын булмаганлыктан, машинасын туктвлыш урынына урнаштыра алмаган.

Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең китергән дәлилләрен искә алып, һәм шикаять буенча чара күрүне сорап, Эчке эшләр министрлыгының Татарстан буенча ЮХИДИ идарәсе җитәкчесенә хат җибәрде.

ЮХИДИ идарәсенең юл хәрәкәтендә административ хокук бозуларны теркәү автоматлаштырылган үзәге җитәкчесе мәгълүматы буенча, административ хокук бозулар турында эшләр буенча карарлар юкка чыгарылган, мөрәҗәгать итүчегә карата ачылган эшләр туктатылган.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, мәҗбүри тоту урыннарындагы затлардан килгән мөрәҗәгатьләр (гаризалар, шикаятьләр) саны елдан-ел кимеми (төрле мәсьәләләр буенча). Нигездә, мөрәҗәгать итүчеләр канәгатьләнерлек булмаган медицина һәм матди-көнкүреш тәэмин ителешенә, җинаять-башкару системасы хезмәткәрләренең хокуксыз гамәлләренә (яки эшләмәвенә), җәза үтәүдән вакытыннан алда азат ителгәндә каршылыкларга зарланды; җәзаны алга таба үтәү өчен башка төзәтү учреждениесенә күчерү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итте.

Ләкин, мәсәлән, җәзаны үтәү белән дә, тулаем алганда җинаять-башкару системасы белән дә бәйле булмаган, мәгълүмати-агарту характерындагы үтенечләр дә булды (белешмә материаллар бирү үтенечләре). Мондый мөрәҗәгатьләр мисалы сыйфатында Ямал-Ненец автономияле округының төзәтү учреждениесендә җәза үтәүче хөкем ителгәннәрнең – М. һәм З. мөрәҗәгатьләрен билгеләп үтәргә мөмкин. Төбәкнең ераклыгына карамастан, гражданнар Татарстанның Вәкаләтле вәкиленә 8 тапкыр мәгълүмат бирүне сорап мөрәҗәгать итте.

Пенитенциар учреждениеләрдән килә торган мөрәҗәгатьләр, мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләрен тикшерү өчен, махсуслаштырылган прокуратурага гына түгел, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә дә җибәрелә, еш кына Вәкаләтле вәкил, Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясендәге коллегалар белән бергә, урыннарга чыгып тикшерелә. Килгән вакытта һәрвакыт хөкем ителүчеләр белән шәхси сораулар буенча да, көнкүрешкә кагылышлы мәсьәләләр буенча да әңгәмәләр үткәрелә.

Вәкаләтле вәкил шулай ук ел саен төзәтү учреждениеләреннән азат ителүче затларның мөрәҗәгатьләрен дә карый. Хөкем ителүче затлар үзләренең иректәге киләчәге һәм, төзәтү учреждениесеннән соң, үзләренә яраклы эш, торак табып булмас дип, җәмгыятьтә «үз урыны»ма кире кайта алмам, дип борчыла. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, республика муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары, шулай ук коммерциячел булмаган оешмалар белән бергә, төзәтү учреждениеләреннән азат ителгән затларга килеп туган тормыш авырлыкларын җиңәргә булышу максатыннан, системалы эш алып бара.

Гражданнарның Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләре статистикасында тагын дүрт тематик блок бар, алар буенча мөрәҗәгатьләр дә килде. Алар 2021 елда төп түгел иде, тик шулай да мөһим булдылар. Болар:

«Гражданлык һәм сәяси хокуклар һәм ирек» – 391 (сайлау һәм сайлану хокукы) – 76; Россия Федерациясе гражданлыгына хокук, ирекле хәрәкәт итү, тору һәм яшәү урынын сайлау – 58; вөҗдан һәм дин иреге – 2; дәүләт һәм муниципаль органнарга мөрәҗәгать итү хокукы – 255).

Вәкаләтле вәкил Аппаратына яшәүгә рөхсәт алуга гариза бирү вакытын озынайтуда булышуны сорап Э. гражданы мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать эчтәлегеннән аңлашылганча, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт вакыты 2021 елның 26 сентябрендә тәмамлана. Шуңа бәйле рәвештә, Э. 2021 елның 20 маенда яшәүгә рөхсәт бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән. Ләкин гаризаны кабул итүдән баш тартканнар, чөнки ул тәкъдим иткән рус телен белү, Россия тарихы һәм Россия Федерациясе законнары нигезләрен белү турындагы документны караганда, кияүгә чыкканчыга кадәр булган элеккеге фамилиясе күрсәтелгән. Гражданка Э. ашыгыч рәвештә рус телен белү, Россия тарихын һәм Россия Федерациясе законнары нигезләрен белү имтиханын тапшырды, ләкин «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендә дөнья күргән 115 нче Федераль законның 8 маддәсе 5 пункты нигезендә яшәүгә гаризаны бирү датасыннан соң икенче көндә генә нәтиҗә алды.

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры адресына Вәкаләтле вәкил Э. гражданнын 2021 елның 20 маенда яшәү өчен рөхсәт бирүгә язган гаризасын карауны сорап хат юллады. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының миграция мәсьәләләре идарәсе башлыгы мәгълүматы буенча, 2021 елның 19 июнендә Россия Федерациясендә яшәү өчен рөхсәт бирү турында гражданка Э.ның гаризасы карауга кабул ителде.

Ел саен Вәкаләтле вәкилгә чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар аларның Россия Федерациясендәге хокукый хәлен легальләштерү яки илдән чыгарып җибәрү буенча чаралар кабул итүне тизләтүгә булышлык итү, шул исәптән, шәхесне ачыклаучы документ алу, дәүләтнеке булуын билгеләү һәм раслау, мәҗбүри чыгарып җибәрү рәвешендә административ җәза билгеләү турында судлар карарлары белән ризалашмау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итә.

Узган еллардагы кебек үк, 2021 елда да Вәкаләтле вәкил һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасындагы чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгенә барды. Ноябрь аенда Вәкаләтле вәкилгә вакытлыча тоту үзәгендә булганда 4 мөрәҗәгать керде.

Кызганычка, республикада чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукый хәле билгесез булып кала торган вазгыять саклана. 2020 һәм 2021 елларда пандемия чит ил гражданнары илләренә кайтару эшен тагын да тирәнәйтте. Россия Федерациясе чикләреннән чыгарылып җибәрелергә тиешле, иле ачыкланып бетмәгән гражданлыгы булмаган затлар элеккечә үк вакытлыча тоту үзәгендә тотыла.

Вәкаләтле вәкил чит ил гражданнары мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә еш кына булышлык күрсәтүне сорап чит илләрнең кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләренә яки Татарстан Республикасында эшләүче генераль консулларга мөрәҗәгать итә. Шундый хезмәттәшлек мисалы итеп, Вәкаләтле вәкилнең Үзбәкстан Республикасының Казан шәһәрендәге генераль консулына мөрәҗәгать итүен күрсәтергә була, ул чит ил гражданины хокукый хәлен легальләштерү яки Россиядән чыгарып җибәрү өчен алга таба чаралар күрү максатыннан Үзбәкстан Республикасы гражданлыгы булу-булмавын раслаучы документлар бирүне сорады.

Нәтиҗәсез, Вәкаләтле вәкилгә вакытлыча тоту үзәгендә булмаган чит ил гражданнарыннан да мөрәҗәгатьләр килә.

Әйтик, мөрәҗәгать итүче якын туганы Россия Федерациясе гражданы буларак, вакытлыча яшәүгә рөхсәт алу процедурасын башкармыйча, Россия территориясендә яшәргә рөхсәт алырга теләгән.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясендә яшәүгә гадиләштерелгән тәртиптә рөхсәт алуга комачаулык итүче сәбәпләр дә бар.

Андый очракларда Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән затларның туганлыгын раслау өчен кирәкле документлар: архив документлары күчермәләре, туу турында таныклык күчермәләре алуда булышуны сорап, чит илләрдәге кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә хатлар җибәрә.

Шундый тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә үз мөрәҗәгатьләрендә чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар күрсәткән мәсьәләләр тиз чишелеш таба.

«Закон кысаларында суд эшләре буенча хокукларны яклау» – 195 (суд карарын үтәмәү – 38, суд приставлары хезмәте эшчәнлеге – 123, гаилә әгъзаларының алимент йөкләмәләре – 29, башка мәсьәләләр – 5).

«Хәрби хезмәткә чакырганда хәрбиләрнең хокукларын яклау» – 55 (альтернатив гражданлык хезмәте – 10, хәрби бурыч (кичектерү, чакырылыш тәртибе, хәрби комиссариатлар эше, чакырылыш комиссияләре эше) – 30, хәрби хезмәт (хәрби хезмәткәрләрнең вәкаләтләрен һәм хезмәт бурычларын үтәү; контракт буенча хәрби хезмәт узу, контрактны өзү, вакытыннан алда өзү; хәрбиләрнең чакырылыш буенча хезмәт узу, хәрби хезмәткәрләрне вакытыннан алда азат итү; хәрби хезмәткәрләрнең законсыз эш итү фактлары, сәламәтлекне саклау һәм хезмәт узу чорында медицина ярдәме) – 7, хәрби хезмәткәр статусы (хәрби хезмәткәрләрне, хәрби хезмәттән азат ителгән хәрбиләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль яклау) – 8).

Вәкаләтле вәкилгә хисап чорында аналардан чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы улларының хәрби хезмәткә яраклылык төрен билгеләү һәм хәрби хезмәткә чакыру турында чакырылыш комиссиясе тарафыннан бәяләмә чыгарганда нигезләрнең законга туры килүен тикшерү уздыру максатында стационар тикшерү үткәрүгә ярдәм итү үтенечләре килде.

Мөрәҗәгатьләрдә билгеләп үтелгәнчә, кулында медицина документлары белән расланган билгеле бер диагноз булганда, әлеге документлар хәрби комиссариат тарафыннан игътибарга алынмый.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хәрби комиссары адресына хәрби хезмәткә чакыру турында бәяләмә чыгарганда мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән дәлилләрне тикшерүне оештыруны сорап хатлар җибәрде.

«Финанс һәм хуҗалык эшчәнлеге өлкәсендә кеше хокукларын яклау» – 327.

Гражданнарга үзләрен борчыган проблемалар турында ирекле хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган нәтиҗәле инструмент буларак үзен күрсәткән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге турында без 572 мөрәҗәгать алдык. Гражданнар «Гариза хәл ителде» һәм «Дәлилләнгән кире кагу» дигән нигезләнмәгән статус бирү белән килешмәү турындагы, шулай ук күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне алга таба хәл итү өчен системага кире кайтару турындагы үз мөрәҗәгатьләрен Вәкаләтле вәкил адресына җибәрә.

Кызганычка, ел дәвамында җаваплы башкаручылар тарафыннан мөрәҗәгатьләрне хәл итүгә формаль якын килү очраклары күзәтелә. Мондый очракларда Вәкаләтле вәкил чараларны оператив кабул итү өчен мөрәҗәгатьләрне карауда катнашырга тиеш.

Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталы интернет-кабул итү бүлмәсе аша «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы Б.дан Казан шәһәре Әбүбәкер Терегулов исемендәге урам юлындагы чокырларны күмү кирәклеге хакында 1739682 нче мөрәҗәгатьнең үтәлеше мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать керде.

Әлеге мөрәҗәгать 2017 елдан хәл ителмәгән һәм куелган срокларда башкарылмаганлыктан, берничә тапкыр җаваплы үтәүчегә кире кайтарылган.

Алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вахитов һәм Идел буе районнары хакимияте җаваплы үтәүчеләренең мондый гамәлләренә юл куярга ярамый.

Вәкаләтле вәкил Б.ның мөрәҗәгатен карау һәм аны билгеләнгән вакытка үтәү турында хакимият башлыгына хат җибәрде.

Вәкаләтле вәкил катнашыннан соң «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән бу мөрәҗәгать үтәлде, юлның бу участогында чокырлар ямалды.

2021 елда Татарстан Республикасы «Халык контроле» системасында 2021 елның 31 декабренә булган мәгълүматларга караганда, барлык статуслардан кайтарылган мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, 83763 мөрәҗәгать бастырылган, бу 2020 ел белән чагыштырганда 9 процентка күбрәк (76455 мөрәҗәгать), шулардан: 65566 мөрәҗәгать хәл ителгән – 78% (узган ел белән чагыштырганда 9 процентка күбрәк – 59382 мөрәҗәгать), 10964 мөрәҗәгать буенча эшләр планлаштырылган, 5654 мөрәҗәгать дәлилле кире кагылган, 1579 мөрәҗәгать – эштә.

Гражданнардан кергән комментарийларның гомуми саны 2 миллион 247 мең 852, теләктәшлек белдерүчеләр – 1 миллион 489 мең 291.

Хисап чорында системадан кулланучылар «Территорияләрне комплекслы төзекләндерү» төре буенча барыннан да активрак мөрәҗәгать җибәргәннәр – 28 382 мөрәҗәгать, «Муниципаль юлларны тоту һәм ремонтлау» – 16812 мөрәҗәгать, «Коммуналь хезмәт күрсәтүләр» – 4233 мөрәҗәгать, [illegible] – 3411 мөрәҗәгать, «Тышкы рекламаны бозу» – 3412 мөрәҗәгать, «Җәмәгать транспорты» – 2191 мөрәҗәгать, «Сукбай хайваннар» – 1579 мөрәҗәгать.

2021 ел башыннан «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында социаль челтәрләрдән килгән 262 мөрәҗәгать басылып чыкты, шуларның 191е хәл ителде, 48е буенча эш планлаштырылган, 4се эштә, 19 мөрәҗәгатькә, аларны үтәү мөмкинлеге булмау сәбәпле, «Дәлилле кире кагу» статусы бирелде.

2021 елда республика территориясендә гамәлгә ашырыла торган тармак инвестиция программалары нәтиҗәсендә автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләре буенча 16910 мөрәҗәгать һәм территорияләрне төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерүгә кагылышлы 29687 мөрәҗәгать уңай хәл ителде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын камилләштерү буенча даими эш алып барыла. Әйтик, 2021 елның 1 июненнән гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, халыкның социаль канәгатьлелеген арттыру һәм гражданнар белән җәмәгать контроле механизмын булдыру, шул исәптән «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру кысаларында, яңа юнәлешләр кертелде: «Төзекләндерү һәм инфраструктура», «Юллар», «Торак-коммуналь хуҗалык», «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «ТКО» һәм «Транспорт». Хәзерге вакытта системада 102 төр буенча мөрәҗәгатьләр кабул ителә. «Төбәк белән идарә итү үзәге»нең Проект офисы эшчәнлеген тәэмин итү кысаларында Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Бердәм порталы базасында эшли торган кире элемтә платформасы аша 2021 елның августыннан төрле мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре кабул ителә башлады. 2021 елда кире элемтә платформасы аша Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына барлыгы 28101 хәбәр килде.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне сыйфатлы һәм оператив башкару максатларында, 2021 елда Вәкаләтле вәкил Аппаратында һәм муниципаль районнарда, шул исәптән видеоконференция режимында, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкилләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм җаваплы башкаручылары катнашында 29 эш киңәшмәсе уздырылды. Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгән объектлар буенча 520 күчмә тикшерү уздырылды, һәм 3674 мөрәҗәгать нигезсез статуслар бирелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында җаваплы башкаручыларга эшкә кайтарылды.

Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килә торган мөрәҗәгатьләрнең сыйфатын яхшырту һәм аларны вакытында карау буенча бергәләп эшләү һәм үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә, хисап чорында карау сроклары бозылган мөрәҗәгатьләр санын шактый киметүгә, шулай ук уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләрнең санын арттыруга ирешелде. Шулай ук республиканың барлык муниципаль районнары һәм шәһәр округлары «Уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр өлеше» индикаторын үти алды.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне үтәү буенча Әгерҗе (83%), Аксубай (79%), Актаныш (78%), Апас (82%), Әтнә (90%), Баулы (85%), Балтач (79%), Бөгелмә (80%), Чүпрәле (88%), Кама Тамагы (100%), Лениногорск (81%), Мамадыш (87%), Менделеевск (82%), Минзәлә (80%), Мөслим (87%), Түбән Кама (80%), Питрәч (86%), Балык Бистәсе (86%), Саба (91%), Сарман (77%), Тәтеш (83%), Теләче (81%), Чистай (78%), Ютазы (88%) муниципаль районнары һәм Чаллы шәһәр округы (86%) башкарма комитетларында актив эш алып барылды, аларда системага килгән мөрәҗәгатьләр, вакытында, сыйфатлы карала һәм үтәлә һәм үтәлгән мөрәҗәгатьләр өлеше 77 проценттан 100 процентка кадәр.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка хезмәт күрсәтүне оештыру һәм сыйфатын бәяләүне үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендә дөнья күргән 1319 нчы карары нигезендә, без, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының «Халыкка социаль әһәмияткә ия хезмәт күрсәтүләрне бәяләү» сервисы мәгълүматларын анализлау буенча эш алып барабыз. Бәяләү нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан «Табибка язылу» һәм «Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү» сервислары кысаларында хезмәт күрсәтүләр сыйфаты рейтингы төзелде.

2021 елда «Табибка язылу» буенча сыйфатны бәяләү системасыннан гражданнар 1 миллион 752 мең тапкыр файдаланганнар (уртача бәяләү – 4,8). Узган ел белән чагыштырганда бәяләүнең гомуми саны 185 мең 388гә кимеде, әмма киметелгән бәяләүләр саны да 19 мең 388гә кимеде.

Шул ук вакытта бәяләнүнең кимүе сәбәбе итеп, гражданнар 93421 тапкыр «чиратта озак көтү», 63056 тапкыр – «табиб мөнәсәбәте», 21550 тапкыр – «регистратура, шәфкать туташлары мөнәсәбәте» билгесен күрсәттеләр. 9902 кулланучы учреждениеләрдә санитар шартларыннан канәгать булмаган.

2021 елда гражданнар «Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү» вакытында сыйфатны бәяләү системасыннан 155 мең тапкыр файдаланганнар (уртача бәяләү – 3,71). Нигездә, гражданнар бәяне киметү сәбәбе итеп түбәндәгеләрне күрсәтте: йортны (чисталыкны) тиешле тәртиптә тотмау (29% – 45449 тапкыр бәяләү), йортны төзекләндерү (24% – 37219), коммуналь хезмәтләр күрсәтү (20% – 31852) һәм йорт белән идарә итү (19% – 29822 тапкыр).

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә аның муниципаль районнардагы һәм шәһәр округларындагы җәмәгатьчелек ярдәмчеләре зур роль уйный. Алар Вәкаләтле вәкил урынга чыгып гражданнарны кабул итү вакытында актив катнашалар, гражданнарга консультацияләр бирәләр, Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен, шикаять бирү тәртибен, хокук һәм ирекне яклау ысулларын аңлаталар, төрле тикшерүләр үткәрәләр, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүчеләрне хокукый агарту эшчәнлеген тормышка ашыралар.

2021 елда җәмәгатьчелек ярдәмчеләре:

– 845 гражданны һәм 1000гә якын мөрәҗәгать кабул итте;

– районнарның чакырылыш, мәнфәгатьләр низагларын көйләү һәм хезмәт тәртибе таләпләрен саклау, ришвәтчелеккә каршы көрәш, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү, торак, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр эшендә катнаштылар;

– 11 хәрби частьта (Хабаровск һәм Приморье крайларында, Оренбург, Самара һәм Киров өлкәләрендә, Башкортстан Республикасында) булдылар.

2 бүлек. Граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау. Тавыш бирү һәм сайланулы булу хокукы

Тавыш бирү һәм сайлана алу хокукы – кешегә дәүләт һәм җәмгыять эшләре белән идарә итүдә катнашу мөмкинлеге бирә торган үзәк институтларның берсе. Яшерен тавыш бирү юлы белән гомуми һәм тигез сайлау хокукында үткәрелергә тиешле даими һәм гадел сайлаулар кирәклеге 1948 елгы кеше хокуклары Гомум декларациясендә дә, соңрак – 1966 елгы граждан һәм сәяси хокуклар турындагы Халыкара пактта да ассызыкланган. Европа Советы дәрәҗәсендә ирекле сайлауларга хокук кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Конвенциягә 1 нче беркетмә белән беркетелгән.

Омбудсменнарның бурычы – безнең илдә яшәүчеләр өчен шартларны идеаль рәвештә тәэмин итү, аларда сайлау өчен бернинди каршылыклар булырга тиеш түгел.

Сайлау хокукларына күзәтчелек итү 1993 елгы Париж принципларында универсаль халыкара дәрәҗәдә, 2019 елгы Венециан принципларында – Европа Советы дәрәҗәсендә яктыртылган омбудсмен мандатына бөтенләе белән туры килә.

Сайлау кампанияләрен әзерләү һәм үткәрү чорында Вәкаләтле вәкил Аппараты, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, төбәкнең иҗтимагый хокук саклау оешмалары һәм, әлбәттә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән хезмәттәшлек итә.

Вәкаләтле вәкил Аппараты белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә, гражданнарның сайлау хокукларын яклау мониторингын үткәрәләр, шул исәптән, ябык сайлау участокларында, ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүмат алмашалар, әлеге фактлар буенча бергәләп тикшерүләр үткәрәләр.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы буенча, 2021 елның 1 сентябренә республикада 2931939 сайлаучы бар иде.

2021 елда гражданнарның дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашуга хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мөһим вакыйга – 17–19 сентябрь көннәрендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына сайлаулар үткәрү иде. Республикада шулай ук Студентлар (Түбән Кама) һәм Азино (Казан шәһәре) бермандатлы округларында өстәмә депутатлар сайлаулар һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнарына өстәмә сайлаулар узды.

2021 елның 9 сентябреннән 19 сентябренә кадәр Бердәм тавыш бирү көне алдыннан һәм чорында гражданнарның сайлау хокукларын яклауны тәэмин итү буенча Вәкаләтле вәкил Аппаратында «кайнар элемтә» оештырылды. 73 шалтырату кабул булды.

«Кайнар элемтә»гә килгән шалтыратулар сайлаучыларны барыннан да бигрәк нәрсә борчуы һәм сайлау кампаниясе турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең халыкка мәгълүмат бирүне никадәр киңрәк тормышка ашыруы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Телдән әйтелгән мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, «кайнар элемтә»гә килгән сораулар нигездә аныклау характерында: теркәлгән урын буенча кайда сайларга, яшәү урыныннан читтә булганда кайда сайларга, өйдә ничек тавыш бирергә, авыру яки COVID-19 сәбәпле ирекле үзсаклануда булганда ничек сайларга.

Моннан тыш, сайлаучыларны сайлауларны тәэмин итү, сайлау участоклары адресларын мәгълүмат бирү мәсьәләләре күбрәк борчыды.

Шуңа күрә республиканың сайлау комиссияләре перспективалы эш юнәлешләре арасында гражданнарга сайлау законнары һәм сайлау кампаниясе турында тулаем мәгълүмат бирү буенча тырышлыкны арттырырга кирәклеген ассызыклау мөһим.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә сайлау комиссияләре эшен оештыру турында, тавыш бирү тәртибе һәм кандидатлар турында сайлаучыларга мәгълүмат бирүне яхшырту буенча өстәмә чаралар кабул итүне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр иде дип саныйбыз.

Сайлаулар үткәрү турында мәгълүмат бирү күбрәк «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацион челтәре аша башкарылганлыктан, шул исәптән сайлау участогы турында мәгълүматны Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре бердәм порталында гражданның шәхси кабинетында урнаштыру сәбәпле, «кайнар элемтә» нәтиҗәләре халыкның цифрлы грамоталыгы җитәрлек булмавын күрсәтә.

Сайлаулар яссылыгында халыкның цифрлы грамоталыгын күтәрү кирәклеге БМО һәм Европада Куркынычсызлык һәм Хезмәттәшлек буенча оешманың 2020 елда дөнья күргән «Цифрлы технологияләр чорында сайлаулар һәм фикереңне җиткерү иреге турында» уртак декларациядә дә ассызыкланган.

Күрсәтелгән Декларациянең V пунктындагы тәкъдимнәр дәүләтләргә массакүләм мәгълүматның цифрлы чараларына, шул исәптән сайлаулар яссылыгындагы мәгълүматка карата халыкның грамоталыгын үстерү буенча бергәләшеп тырышлык куярга кирәклеген күрсәтә.

Икенче яктан, Россия төбәкләренең сайлау комиссияләре рәсми сайтларына һәм социаль челтәрләрдәге битләренә беренчел күзәтү ясау сайлау комиссияләренең, шул исәптән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең интернет челтәрләрендә җитәрлек күләмдә тәкъдим ителмәвен һәм актив булмавын күрсәтә. Шулай ук яшьләрнең актив гражданлыгы позициясен үстерү һәм хокукый культурасын күтәрү өчен сайлау кампанияләренә җәлеп итәргә тиешле яшьләр, электоратның бер өлеше белән элемтә урнаштырылмаган.

Татарстан Республикасы Президенты указы белән 2022 ел Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы дип игълан ителде.

Мондый карар кабул итү нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә электорат, аерым алганда, яшьләр белән интернет мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә, бигрәк тә социаль челтәрләрдә эшне активлаштыру кирәк һәм мөһим дип саныйбыз.

Шундый эш формалары арасында сайлау комиссиясе рәсми сайтының халыкны хокукый агарту өлешен даими тутыруга, сайлау комиссиясе аккаунтларын төбәктә популяр социаль челтәрләрдә алып баруга, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе социаль челтәрләрен тутыру өчен актуаль һәм сорау булган контент булдыруга, шулай ук Телеграм мессенджерында кешенең сайлау хокукын тормышка ашыруга кагылышлы иң популяр сорауларына җавап бирү өчен чат-бот булдыруны билгеләргә булыр иде.

Сайлаулар алдыннан Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова башлангычы белән гражданнарның сайлау хокукларын яклауны күзәтүдә катнашкан төбәкләрнең кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре һәм аларның Аппарат хезмәткәрләре өчен берничә өйрәтү семинар-тренинглары үткәрелде. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Генераль прокуратурасы һәм Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы экспертлары гражданнарның сайлау хокукларын тәэмин итү, шулай ук сайлау кампаниясе вакытында хокук бозуларны кисәтү турында сөйләделәр.

2022 елда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә мондый чараларны уртак эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү, гражданнарның сайлау хокукларын яклау, саклау һәм торгызуны тәэмин итү максатыннан Вәкаләтле вәкил Аппараты, шулай ук республиканың муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы җәмәгатьчелек ярдәмчеләре өчен оештырырга тәкъдим итәм.

Татарстан Республикасында сайлаучылар өчен оештырылган 46 вакытлыча сайлау комиссиясе (ябык участоклар) бар. Болар хастаханәләрдә, шикләнелгән һәм гаепләнелгән кешеләрне сак астында тоту урыннарында, санаторийларда, вокзалларда, аэропортта.

Вәкаләтле вәкил ябык участоклардагы сайлау процессына зур игътибар бирә.

Россия Федерациясе Конституциясе сак астында булган гражданнарга, суд карары буенча иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче хөкем ителгәннәрдән аермалы буларак, дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайланырга һәм сайларга хокук бирә.

Күрсәтелгән гражданнар үзләренең сайлау хокукын, башка күпчелек хокуклар кебек үк, кирәкле шартлар тудырылган сак астында тоту урыннарында тормышка ашыралар. Сайлаулар үткәрү көнендә республиканың тикшерү изоляторларында биш сайлау участогы ачылган иде.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматы буенча, 2021 елның 15 сентябренә тикшерү изоляторларында 2256 кеше тотыла иде, шуларның 1748 е сайлау хокукына ия иде. Сайлаучылар исемлегенә кертүне сорап 1646 кеше гариза бирде. Аларның барысы да сайлаучылар исемлегенә кертелде.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә үткәргән тикшерүләр республиканың тикшерү изоляторлары сак астында булучыларга аларның сайлау хокуклары, сайлау вакыты, көне, шулай ук сайлау тәртибе турындагы мәгълүматны күргәзмә агитация аша да, эчке радио аша да җиткерүен күрсәтте.

Вәкаләтле вәкил аерым игътибарын сайлау участокларының аз хәрәкәтләнә торган кешеләр өчен уңайлыгын тикшерүгә юнәлтте. Бүген Татарстан Республикасында 273 меңнән артык инвалид яши, алар арасында 34 меңе күз күрү, ишетү, терәк-хәрәкәт аппараты авырулары буенча инвалидлар.

Бу яктан республикада зур эш алып барыла: 2014 елда Вәкаләтле вәкил һәм инвалидларның коммерциячел булмаган оешмалары вәкилләре кергән махсус эш төркеме төзелде. Бу эшне башлаганда 451 участок икенче катта урнашкан иде, 2018 елда – 314, 2020 елда 221 участокка калды.

2021 елда сайлау участокларының 92% (2557) беренче катларда урнаштырылды.

Инвалид коляскаларында хәрәкәт итүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы сайлау участокларының 1700е пандуслар белән тәэмин ителгән (61,5%).

Киләсе сайлау кампанияләрен әзерләгәндә һәм үткәргәндә бу проблемага аерым игътибар бирергә кирәк, дип саныйбыз.

Элеккечә үк гражданнарның сайлау хокукларын тормышка ашыру максатыннан, җирле үзидарә органнарына лифтлар яки физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне, инвалидларны йөртү җайланмалары булмаган биналарга сайлау участокларын беренче каттан югарыга урнаштырмаска дигән, сәламәтлекләре чикле гражданнарның, шул исәптән инвалидларның сайлау хокукларын тәэмин итүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр актуаль булып кала.

Барлык сайлау участоклары күз күреме буенча инвалид булган сайлаучыларга бюллетеньне мөстәкыйль тутыру өчен Брайль шрифтлы махсус трафаретлар белән җиһазландырылган.

Шрифты зурайтылган 553 мәгълүмат брошюрасы, Брайль шрифты белән 553 брошюра әзерләнгән.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аз хәрәкәтләнә торган гражданнар өчен 200 махсус кабина сатып алды. 2021 елгы сайлауларда 887 сайлау участогы махсус кабиналар белән җиһазландырылган иде инде. Әлеге эшне дәвам итәргә кирәк.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе «112 ашыгыч чакырулар хезмәте» һәм Чукраклар Бөтенроссия җәмгыятенең Татарстан бүлеге белән берлектә ишетмәгән сайлаучыларга ымлыклар белән аралаша белгән тәрҗемәче хезмәтен тәкъдим итү мәсьәләсен хәл итте. Моның өчен әлеге төргә керүче гражданга яки участок сайлау комиссиясе әгъзасына WhatsApp мобиль кушымтасында махсус телефон номерына видео аша шалтыратырга кирәк.

Вәкаләтле вәкил шулай ук Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы баш идарәсе белән килешү төзеде, аңа ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкил Аппаратына гражданнарның хокуклары бозылу турында хәбәрләр килә (29 сайлау хокукларын яклау мәсьәләләре буенча хәбәр).

Бердәм тавыш бирү көнендә видеокүзәтү – сайлау процессының легитимлыгын һәм гаделлеген тәэмин итүдә иң көчле коралларның берсе, ул законнар бозылуга шик булган, гражданнарның сайлау хокуклары сакланмаган очракларда тиз генә чаралар күрергә, килеп туган бәхәсләрне чишәргә мөмкинлек бирә.

Сайлауларны видеокүзәтүнең аерым тәртибе билгеләнгән: видеоязмалар интернет челтәрендә ачыктан-ачык күрсәтелми, ләкин җәмәгатьчелек һәм хокук саклау җәмәгатьчелеге Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый палаталар оештырган сайлауларны җәмәгатьчелек күзәтүе үзәкләре эшендә катнаша.

Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2021 елның 25 августында дөнья күргән карарына ярашлы рәвештә төбәкләрдәге кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә, Бердәм тавыш бирү көнендә Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре порталында эш кабинетында трансляция алып барылган видеокүзәтү ачык булды.

Татарстанда 46 вакытлыча ачылган сайлау участогыннан тыш, 2764 участок сайлау комиссиясе, һәм барлык 65 территориаль сайлау комиссиясе видеокүзәтү камералары белән җиһазландырылган. Теркәлгән файдаланучыларга сайлау участокларындагы сайлауны реаль вакыт режимында күзәтергә мөмкинлек бирүче видеокүзәтү 98 процент сайлау комиссияләрендә мөмкин.

Барлык бу инструментлар – Россия электораль практикасы өчен яңа. Яңа новацияләр керткәндә куркынычларны киметү өчен ныклы контроль кирәк, шул исәптән – омбудсменнар катнашында.

Шул уңайдан Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән Россия Федерациясе субъектларындагы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә трансляцияне кабат карау мөмкинлеге бирү буенча башлангычны яклауны һәм тиешле юлламаны Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрүне сорый.

Сайлауларны күзәтү институтын тормышка ашыруның чит ил һәм илебез тәҗрибәсе дә, сайлау комиссияләре эшчәнлегендә хәбәрдарлык атмосферасы, сайлау участокларында күзәтүчеләр булу җәмәгатьчелектә сайлауларның гаделлеге турында шактый дәрәҗәдә ышаныч тудыруын

дәлилли, гражданнарның сайлау процессында актив катнашуына булышлык итә.

Ачыклыкны тәэмин итүгә халыкара экспертларның һәм күзәтүчеләрнең катнашуы да булышлык итә.

Россия Федерациясе Дәүләт Думасына сайлауларга 55 дәүләттән, 10 халыкара оешмадан 250 халыкара күзәтүчеләр килде.

Экспертларга һәм күзәтүчеләргә карарга теләгән сайлау участоклары турында карар кабул итүдә тоткарлык тудырылмый.

Халыкара күзәтүчеләр бу эш аларга тагын шунысы белән кызыклы булуын әйтәләр, алар яңа идеяләр алып, аларны үз илләрендә тормышка ашыра ала.

2021 елның 18 сентябрендә Вәкаләтле вәкил халыкара экспертлар: Бавария Ландтагы депутаты, Мавритания Ислам Республикасы Икътисади һәм социаль советы Генераль секретаре, Сүрия Гарәп Республикасы Халык Советы депутаты белән бергә, Арча шәһәренең 937 нче, 939 нчы, Арча районы Яңа Кырлай авылының 965 нче сайлау участокларында булып, участокларның җиһазланышы белән танышты, сайлаучылар һәм комиссия әгъзалары белән аралашты.

Аз хәрәкәтләнә торган гражданнар тавыш бирсен өчен кирәкле инфраструктура белән тәэмин итү мәсьәләсе тулысынча хәл ителеп бетмәсә дә, Германиядән килгән халыкара эксперт, Бавария Ландтагы депутаты Ульрих Сингер инвалидлар һәм сәламәтлекләре чикле кешеләр тавыш бирсен өчен оештырылган чараларны югары бәяләде, аеруча Брайль шрифты белән эшләнгән мәгълүмати материалларны, бюллетеньнәрне ошатты. Һәр бюллетеньдә Брайль рельф-ноктаһы тактиль шрифты кулланыла, күзе күрмәүче участокка килә алмаса, сайлау комиссиясе әгъзалары кешенең өенә килеп, тавыш бирү мөмкинлеге тудыра ала.

Сүрия эксперты Мәхмүт Әлхәсән, үз чиратында, участокларда тавыш бирү барышын сәяси партияләрдән күзәтүчеләр, кандидатлар урында да, видеокүзәтү аша да күзәтә алуын аеруча мөһим, моның сайлауларны ачык һәм гадел итүен ассызыклады.

2021 елның 23 октябреннән 26 октябренә кадәр Үзбәкстанда узган Президент сайлауларының ачыклыгын һәм легитимлыгын бәяләү максатыннан Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе күзәтүчеләре делегациясе составында сайлауларны күзәтүдә катнашты.

Татарстан Республикасыннан күзәтүчеләр Үзбәкстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Ташкент, Сәмәрканд, Бохара шәһәрләрендәге сайлау участокларында һәм медиаүзәкләрендә булды, Үзбәкстан Республикасы Президентын сайлау тәртибе, технологик мөмкинлекләре белән танышты.

Эш сәфәре кысаларында Вәкаләтле вәкил Үзбәкстан Республикасы Олы Мәҗлесе вәкаләтле вәкиле (омбудсмен) Фирүзә Эшматова белән очрашты. Очрашу барышында яклар Үзбәкстанда 2021 елның 24 октябрендә булган Президент сайлауларында сайлаучылар өчен тудырылган шартлар, сайлаучыларның сәяси хокукларын тәэмин итүдә кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең роле турында фикер алыштылар. Очрашу нәтиҗәсе буларак, кеше һәм граждан хокукларын үтәү, яклау һәм бозылган хокукларны торгызу буенча бергәләп оператив чаралар кабул итү максатларында үзара хезмәттәшлек турында Килешүгә кул кую турында килешенде.

3 бүлек. Вәкаләтле вәкилнең кешенең социаль, икътисади һәм мәдәният хокукларын саклау буенча эшчәнлеге

3.1. Хезмәт хокуклары

Вәкаләтле вәкилнең кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен дәүләт яклавын тәэмин итү буенча эшчәнлеге аерым хокукый мәсьәләләр белән генә чикләнми. Ул күп кырлы, шулай да хокукый мөнәсәбәтләрнең киң спектры кысаларында, кешенең социаль хокукларын яклау белән бәйле эшчәнлек аерым урын алып тора.

Узган еллардагы кебек үк, безнең адреска килгән мөрәҗәгатьләрнең шактый өлеше хезмәт мөнәсәбәтләре, гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны яклау, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, дәүләт һәм муниципаль торак фондларында торакка хокукны тәэмин итү, медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлекне саклау, мәгариф өлкәләрендә, уңайлы әйләнә-тирә мохиткә кеше хокукын яклау мәсьәләләренә кагыла иде. Гражданнарның социаль хокукларын яклау турында мәгълүматлар җыю һәм анализлау шулай ук «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне, дәүләт һәм җирле үзидарә органнарына килгән сорауларны, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм иҗтимагый оешмалардан алынган мәгълүматларны тикшерү кысаларында тормышка ашырылды.

Кешенең социаль хокуклары, тулырак мәгънәдә алганда, һәркемнең лаеклы тормышын һәм иркле үсешен тәэмин итүче барлык хокуклары икәнен билгеләп, аларга хезмәт хокуклары өлкәсендәге хокуклар да керүен әйтергә кирәк. Эш хакы буенча бурычлар артуга юл куймау буенча үзвакытында чаралар кабул итүне дә кертеп, хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендәге мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итү күп гражданнарның уңайлы тормышы өчен кирәкле шарт булып тора.

Эш хакы буенча бурыч белән бәйле гомуми вәзгыять 2021 ел дәвамында кискен торды. Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, эш хакы буенча бурыч җыелган оешмалар саны 2020 ел белән чагыштырганда артык күп булмаган. 2021 елның 11 аенда хисап көннәренә (һәр айның беренче көне) бурычлы оешмалар саны 70тән 112гә кадәр иде (2020 елда 81дән 159га кадәр). Шуның белән бергә, эш хакы буенча бурыч күләме 218,9 миллион сумнан 350,2 миллион сум арасында иде (2020 елда 226,8 миллион сумнан 305,0 миллион сум арасында). Шулай итеп, 2021 елның кайбер айларында республикада эш хакы бурычы күләме буенча хәл 2020 ел белән чагыштырганда начаррак та булды.

Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә гражданнар хокукларын яклау, намуссыз эш бирүчеләргә йогынты ясау өчен кирәкле вәкаләтләре булган хакимият органнарының зур бурычы булып тора. Аларның эшен алыштырмыйча, без граждан эш хакын һәм аңа тиешле башка түләүләрне тулы күләмдә алуга аның хокуклары бозылуы һәм аларны яклау буенча хакимият органнары тарафыннан тиешле чаралар күрелмәве турында белдергән хәлләргә игътибарсыз кала алмадык. Аерым алганда, гражданнарның, эш хакын түләмәгәндә эш бирүче үз идарәсендә һәм контролендә һәм оешманың эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә буйсынуында эшкә кушса да, эш бирүченең алар белән хезмәт мөнәсәбәтләрен тиешенчә теркәмәве турында хәбәр иткән очраклар булды.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә Казан шәһәрендә яшәүче «Добропек» икмәк пешерү оешмасында эшләгәне өчен аңа тулы күләмдә эш хакы түләмәүләре турында хәбәр итте. Граждан әйтүенчә, ул күзәтчелек һәм хокук саклау органнарына да мөрәҗәгать иткән, ләкин чаралар күрелмәгән. Мөрәҗәгать итүченең шикаяте прокуратура органнарына җибәрелде. Прокуратура органнарыннан алынган җавапка караганда, хезмәт мөнәсәбәтләрен теркәү өлешендә дә, эш хакы түләү вакыты өлешендә дә хезмәт законнарын бозу очраклары булган. Нәтиҗәдә гражданга эш хакы тулысынча түләнде.

«НПП «Татспецмаш» җәмгыятендә эретеп ябыштыручы булып эшләве, аңа хезмәте өчен эш хакы түләнмәве турында Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүче хәбәр итте. Әлеге мөрәҗәгать уңаеннан Вәкаләтле вәкил Биектау муниципаль районы башкарма комитетына, оешма җитәкчесе катнашында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, керемнәрне легальләштерү буенча территориаль комиссия эше кысаларында, мөрәҗәгать итүченең керемнәрен тикшерү мәсьәләсен карауны сорап хат җибәрде. Җирле үзидарә органыннан килгән мәгълүматка караганда, мөрәҗәгатьне карагач, мөрәҗәгать итүчегә бурыч түләнгән.

Китерелгән мисалларны күрсәтеп, компетентлы органнарның игътибарын эш бирүчеләр һәм хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен теркәүне бозу очраклары артуга юл куймау буенча системалы чаралар кабул итү кирәклегенә юнәлтәбез.

Татарстан Республикасында минималь эш хакы турында Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасы эш бирүчеләр берләшмәсе Координацион советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы өч яклы килешүләр нигезендә, 2021 елда Татарстан Республикасы икътисадының бюджеттан тыш секторы оешмаларында минималь эш хакы аена 15400 сум күләмендә билгеләнде. Республикада, тулаем алганда, билгеләнгән минималь эш хакы күләмендә эш хакы түләү буенча вазгыять контрольдә тотыла. Үз хезмәткәрләренә минималь эш хакыннан түбәнрәк түләүче эш бирүчеләр җирле үзидарәләр органнары каршындагы тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча территориаль комиссияләр утырышларында тикшерелә. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2021 елның 11 аенда территориаль ведомствоара комиссияләр утырышларында 4111 предприятие җитәкчесе тыңланган, минималь эш хакы күләме турында закон таләпләрен бозып 1831 хезмәткәргә эш хакы түләгән 583 предприятие ачыкланган. Территориаль ведомствоара комиссияләр тәкъдимнәре буенча 553 оешмада 1731 хезмәткәргә 5,9 миллион сум акча түләнгән һәм 1,2 миллион сум салым түләүләре күчерелгән. Шуның белән бергә, эш бирүчеләрнең озак вакыт хезмәткәрләренә билгеләнгән күләмнән кимрәк эш хакы түләү очраклары бар. Әйтик, узган елда безнең адреска 2016–2018 елларда хезмәткәрнең тиешле күләмнән азрак эш хакы алуы турында мәгълүмат керде, аның буенча тиешле чаралар күрүне сорап компетентлы органнарга хат җибәрелде.

Вәкаләтле вәкил, безнеңчә, хакимият органнары игътибарын, гражданнарның хезмәткә хокукларын бозу, шул исәптән эш хакын түләүгә хокукларын бозу очракларын булуына да юнәлтте.

Мәсәлән, безнең адреска, республика территориясендә урнашкан тәэтү учреждениеләренең берсендә хезмәт узу чорында эш хакы алуга хокукы бозылу турында бер граждан мөрәҗәгать итте. Ул ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә хезмәт вазифаларын башкарган өчен компенсация түләмәүләрен әйтте. Мөрәҗәгатьне өйрәнү вакытында шул билгеле булды, аерым бер чор дәвамында тиешледән артык эшләгән өчен хезмәткәр акчалата компенсация да, өстәмә ял көннәре дә алмаган. Хәлне өйрәнеп һәм башкалар да әлеге хәлдә калырга мөмкин дигән нәтиҗә чыгарып, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчелегенә тәэтү учреждениеләрендә хезмәт итүче хезмәткәрләрне билгеләнгән тәртиптә акчалата компенсация түләмичә яки өстәмә ял көннәре (сәгатьләре) бирмичә артык эшләүгә җәлеп итү очракларын булдырмау буенча чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать итте. Бирелгән җавапка караганда хәл җитәкчелек тарафыннан контрольгә алынган.

Халыкның уңайлы тормышын тәэмин итәргә омтылу гражданнарның эшсезлектән саклануны нәтиҗәле системасыннан башка мөмкин түгел. Гражданнардан эш эзләүдә булышуны сорап мөрәҗәгатьләр безнең адреска даими килә һәм шул уңайдан, конкрет очраклар буенча уңай карарлар да, шулай ук халыкның мәшгульлеге өлкәсендәге гомуми вазгыятьне анализлау да кызыксыну уята.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларын анализлау халыкның мәшгульлеге өлкәсендә уңай үзгәрешләр булуын күрсәтә. Мисал өчен, 2021 ел дәвамында эш бирүче инициативасы белән тулы булмаган эш көне (тулы булмаган эш атнасы) яки тулы булмаган эш атнасын эшләүче, эш бирүче гаебе белән эш хакын саклап калмыйча ялларда булучы хезмәткәрләр саны кимү тенденциясе тотрыклы кала. 2020 елның 30 декабрендә мондый хезмәткәрләр саны 20543 кеше тәшкил итсә (ә 2020 елның 6 маена 40646 кешегә җитте), ә 2021 елның 6 октябренә – 15464 кеше. Тулы булмаган эш көне билгеләнгән хезмәткәрләр кимү белән, мәшгульлек хезмәтләре органнары юлламасы буенча эшкә урнашкан гражданнар саны артты.

Икенче яктан караганда, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, халыкны мәшгульлеге өлкәсендә эшсезлекнең уртача дәвамлыгы шулай ук мөһим күрсәткеч булып тора, чөнки һәр гражданның озак вакыт үзе яки мәшгульлек органнарына мөрәҗәгать итү аша конкрет эш урыны сайлау белән шөгыльләнергә җитәрлек акчасы юк.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларын анализлау шуны күрсәтте, 2021 елда эшсез гражданга эш эзләү өчен уртача дүрт ай вакыт кирәк булган. Билгеле бу сан төрле хәлләр җыелмасыннан, шул исәптән эшсез граждан аңа тәкъдим ителгән барлык эш вариантларыннан баш тартуны да исәпкә алып билгеләнә. Үз чиратында Вәкаләтле вәкил дәгъва итүчене эшкә алу турында гариза хезмәт законнарының барлык таләпләрен исәпкә алмыйча каралган очракны карауда катнашты.

Әйтик, безнең адреска Чаллыда яшәүче мөрәҗәгать итте, ул уйлап чыгарылган нигезләмәләр буенча эшкә алудан баш тарттылар дип саный. Мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документларны өйрәнү вакытында, без гражданның эш бирүчегә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча мөрәҗәгать итүенә игътибар иттек. Мәшгульлек хезмәте органнары эшкә юллама күчермәсендә күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең кандидатурасы буенча кандидатларны эшкә кабул итү турында гаризаларны карау сәбәпле генә кире кагылган. Шушы хәлләр нәтиҗәсендә, безнеңчә, граждан үзенең эшкә алу турында гаризасын карау тәртибе турында мәгълүмат алмаган. Бу уңайдан без вакансиягә булганда мөрәҗәгать итүче гаризасын башка кандидатлар гаризасы белән бергәләп карауларын сорап оешма җитәкчесенә хат җибәрдек.

Россия Федерациясе Конституциясе һәркемнең куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган хезмәткә хокукын билгели. Шулай итеп, хезмәткә хокук, әгәр шартлар хезмәткәр өчен куркынычсыз булмаса, тулысынча тәэмин ителгән дип санала алмый.

Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, республикада 2021 елның 11 аенда авыр нәтиҗәләргә яки үлемгә китергән, җитештерү белән бәйле 113 очрак булган. Шул исәптән авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очраклары төрле оештыру-хокукый формалы оешмаларда, шул исәптән, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдә («Азнакай үзәк район хастаханәсе», «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе», «Әлмәт ашыгыч медицина ярдәме станциясе», «Инглиз телен тирәнтен өйрәнүче 9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе», «Су каналы», «Шәһәр электр транспорты» предприятиесе) булган.

Хезмәткә хокук һәм иркене яклауның, шул исәптән, куркынычсыз шартларда хезмәтне тәэмин итү ысулларының берсе – хезмәт законнары һәм хезмәткә хокук нормалары булган башка норматив хокукый актларны үтәүгә контроль. Узган елда без, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты, Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты, Чаллы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты) карамагындагы, 2020 елда хезмәткәр сәламәтлегенә авыр зыян салган бәхетсезлек очраклары булган оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәткә хокук нормалары булган башка норматив хокукый актларны үтәүгә ведомство контролен тормышка ашыру буенча хәлне өйрәндек.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгыннан, Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетыннан, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты мәгълүматлары буенча, 2020 елда производствода бәхетсезлек очраклары булган оешмаларда планлы тикшерүләр 2021 елда уздырылган.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты, производствода бәхетсезлек очраклары булган оешмаларда планлы тикшерүләр, «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәткә хокук нормалары булган башка норматив хокукый актларны үтәүгә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендә дөнья күргән 100 нче Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә расланган, тикшерүләр үткәрү турындагы еллык планга кертмән, тикшерүләр 2022 елда булачак.

Ведомство карамагындагы производствода бәхетсезлек очраклары «теләсә нәрсә булырга мөмкин» принцибы буенча бәяләнергә тиеш түгел, дип саныйбыз. Бәхетсезлек очраклары булган икән, кимчелекләр гражданнарның куркынычсыз хезмәт шартларына конституцион хокукын бозмау максатыннан, бу оешма «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәткә хокук нормалары булган башка норматив хокукый актларны үтәүгә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендә дөнья күргән 100 нче Татарстан Республикасы Законының 4 нче маддәсе 4 нче өлешендә каралган нигезләмәләр буенча, киләсе елга планлы тикшерүләр үткәрү еллык планына кертелергә тиеш.

Моннан тыш, республика муниципаль берәмлекләрендә хезмәтне саклау буенча координация советларына, барлык якларның да фикерен исәпкә алып, һәр бәхетсез очракны карарга, җитештерүдә кешеләрне имгәтүгә китергән сәбәпләрне бетерергә тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

2021 елга хас хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә эшчәнлекнең аерым юнәлеше итеп, 2021 елның 11 октябрендә Татарстан Республикасы Баш дәүләт санитар табибы кабул иткән 7 нче карарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасында яңа короновирус инфекциясе таралуга юл куймауга юнәлтелгән чаралар билгеләнгән чорга хезмәткәрләр хокуклары мәсьәләләре буенча консультацияләр эшне атарга була.

Тулаем алганда, ел дәвамында Вәкаләтле вәкил прокуратура, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты, җирле үзидарә органнары, профсоюз органнары белән гражданнарның хезмәткә хокукларын саклау һәм яклау мәсьәләләре буенча төрле юнәлешләрдә эшчәнлек алып барды.

3.2. Социаль тәэмин итү хокукы

Үзен һәм гаиләсен тормышта мөстәкыйль рәвештә лаеклы шартлар белән объектив тәэмин итү шартлары булмаган очракларда, законда һәм башка норматив хокукый актларда күрсәтелгән гражданнарга дәүләт яклавы чаралары гарантияләнә. Адреслы социаль яклаудан башка социаль дәүләт кайгыртырга тиешле социаль гаделлек булдыру мөмкин түгел.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 елның 14 декабренә Татарстан Республикасы территориясендә социаль яклау чаралары алучылар саны 1,29 миллион кеше тәшкил итте.

Үз чиратында узган ел дәвамында теге яки бу социаль пособие түләүдән баш тартулары турында гражданнардан килгән шикаятьләр буенча Вәкаләтле вәкилгә чаралар күрергә туры килгән очраклар булды. Аерым очракларда Вәкаләтле вәкил социаль тәэминат өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты положениеләрен камилләштерү буенча чаралар күрде.

Әйтик, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2020 елның 31 мартында дөнья күргән 384 нче «3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага ай саен акчалата түләүне билгеләү һәм тормышка ашыру тәртибенә төп таләпләрне, күрсәтелгән айлык түләү билгеләү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) исемлеген һәм аны билгеләү турында гариза формасын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертелү уңаеннан, без Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү алуга хокук бирүче кешеләр исемлеген киңәйтүне сорап хат яздык. Бу гаиләнең балигъ яшьтәге бер яки берничә әгъзасының кереме булмаган очракны күздә тота. Сүз, бер яки берничә кешенең беренче төркем инвалид яки дәвалау учреждениесе карары буенча даими тәрбиягә мохтаҗ яки 80 яшь тулган өлкән кешене карау сәбәпле, кереме булмаган гаиләләргә кагыла. Нәтиҗәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендә дөнья күргән 267 нче карары белән расланган 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү бирү шартларына һәм тәртибенә тиешле үзгәрешләр кертелде. Алга таба бу үзгәрешләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яңа тәртипне билгеләгән, 2021 елның 22 октябрендә дөнья күргән 995 нче карарына да кертелде.

Эшчәнлеге халыкның социаль яктан аз якланган төркемнәре вәкилләрен яклау белән бәйле иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне тормышка ашырып, Вәкаләтле вәкил социаль тәэминат өлкәсендә, хәл итү федераль законнар нормаларын үзгәрткән очракта гына мөмкин булган проблемалы мәсьәләләрне анализлады. Әйтик, инвалид балалар һәм балачактан инвалидлар тәрбияләүче гаиләләрнең актуаль мәсьәләләре буенча инвалид балалар ата-аналарының Бөтенроссия оешмасы төбәк бүлеге мөрәҗәгатен исәпкә алып, без Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 февралендә дөнья күргән 175 нче «Инвалид балалар һәм балачактан беренче төркем инвалидлар тәрбияләүче затларга айлык түләүләр турында» Указында каралган, әгәр алар тулы булмаган эш көне шартларында яки өйдә эшли һәм инвалид бала карауны дәвам итә икән, ата-анага яки инвалид опекунына айлык түләүгә хокукны беркетү турында закон башлангычы белән субъектларга мөрәҗәгать итүне үтенеп, хат җибәрдек (доклад язылган вакытта алынган мәгълүматка караганда хәзер әлеге мәсьәлә карала).

Башкарма эш буенча бурычлы аерым гражданнарны социаль яклау механизмнарының берсе булып – 2007 елның 2 октябрендә дөнья күргән 229 нчы «Башкарма эш турында» федераль законның 101 нче маддәсендә күрсәтелгән керемнәрне алуга куелган тыю тора. Шул ук вакытта безнең адреска гражданнардан социаль характердагы түләүләргә кагылсызлыкка хокукларын бозу турында нигезле мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә караучысын югалткан өчен пенсия күчерелгән банк счетыннан акча алулары турында Казан шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итте. Без катнашканнан соң алынган акча мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылды.

Социаль яклауны тәэмин итү һәм гаиләләрнең керемнәрен саклау максатыннан узган елда дәүләт гражданнарны социаль яклауның яңа чараларын булдырды. Аерым алганда, 2021 елда балалар лагерена путевкалар алганда тотылган акчаның бер өлешен кайтару программасы тормышка ашырылды.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгыннан алынган мәгълүматка караганда 25 майдан 31 августка кадәр кешбэк программасы буенча 400 миллион сумга 30029 путевка сатып алынган.

Ләкин программаны тормышка ашыру белән бәйле проблемалы мәсьәләләр дә булды, республикада яшәүчеләр андый мәсьәләләр белән дә мөрәҗәгать итте.

Әйтик, безгә путевка бәясенең 50 процентын кайтарудан баш тартуларыннан зарланып Түбән Кама шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итте. Программа шартларына ярашлы рәвештә путевкалар 2021 елның 31 маенда «Мир» түләү системасын кулланып түләнгән. Мөрәҗәгать итүче шулай ук путевкаларны балалар ялын оештырган оешмада түләвен хәбәр итте. Путевкаларны сатып алган вакытта, күрсәтелгән оешма балаларның ялын оештыручы оешмаларның бердәм реестрында күрсәтелмәгән булган, шунлыктан мөрәҗәгать итүчегә акча кире кайтарылмаган. Гражданкага акчасын кире кайтаруга хокукын тормышка ашыруга булышу максатыннан без әлеге оешмага мөрәҗәгать иттек, Вәкаләтле вәкил ярдәме белән тиз арада путевка бәясенең яртысы кире кайтарылды.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау эшчәнлеге шулай ук опека һәм попечительлек билгеләү, тормышка ашыру һәм туктату уңаеннан килеп чыга торган мөнәсәбәтләр буенча да тормышка ашырылды.

Вәкаләтле вәкил адресына Нурлат районында яшәүчедән балигъ булмаган баласының (оныгы) «Академик В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе»ндә булуы һәм аны алга таба балалар йортына билгеләүләре турында мөрәҗәгать керде. Мөрәҗәгатьтән күренгәнчә, балигъ булмаган баланың анасын ата-ана хокукыннан мәхрүм иткәннәр, атасы берничә ел элек үлгән. Анасы ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән вакытта бала психиатрия хастаханәсендә булган. «Академик В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе»ннән алынган мәгълүматка ярашлы рәвештә, балигъ булмаган баланы психиатрия стационары шартларында дәвалау өчен күрсәтмәләр булмаган. Пациентны дәвалау вакыты тиешледән күбрәк булган. Татарстан Республикасы Нурлат район суды карары законлы көченә керүгә карамастан (аңа ярашлы рәвештә балигъ булмаган бала Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге карамагына тапшырылган булган), опека һәм попечительлек органы баланы психиатрия стационарыннан чыгару белән шөгыльләнмәгән. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә балигъ булмаган баланы академик В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсеннән чыгару һәм аны алга таба урнаштыру буенча кичекмәстән чаралар күрүне сорап хат җибәрде. Нәтиҗәдә андый чаралар күрелде.

Узган еллардагы кебек үк 2021 елда да без инвалидларны социаль яклау өлкәсендә законнар таләпләрен үтәү максатыннан тикшерү чаралары үткәрдек.

2021 елның октябрь-ноябрь айларында Вәкаләтле вәкил һәм аның җәмәгать ярдәмчеләре психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ачылган йорт-интернатларны тикшерде. Тикшерүчеләр барышында күчемсез милек объектлары (йорт, фатир, җир кишәрлеге) булган акылга зәгыйфь кешеләрнең милеккә хокуклары бозылу; интернатта тәрбияләнүченең милкен файдалану өчен башка затларга (психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ачылган «Казан йорт-интернаты», психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ачылган «Чистай йорт-интернаты») тапшыру уңаеннан тәрбияләнүчегә файда алу буенча чаралар кабул ителмәү; торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча бурычларны вакытында кайтару буенча чаралар күрелмәү (психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ачылган «Яшел Үзән йорт-интернаты», психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ачылган «Яңа Чүриле йорт-интернаты») ачыкланды. Булган кимчелекләр турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җиткерелде. Алга таба бу кимчелекләрне булдырмас өчен конкрет тәкъдимнәр эшләнде, алар 2021 елның декабрендә министрлыкта узган «түгәрәк өстәл» утырышында әйтелде.

Шуның белән бергә Вәкаләтле вәкил опека һәм попечительлек органнары тормышка ашыра торган кагыйдәләрнең 9 нчы пунктына ярашлы рәвештә, балигъ булган акылга зәгыйфь гражданнарның тормыш шартлары тикшерү, опекуннарның балигъ булган акылга зәгыйфь гражданнарның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен яклавы, аларның милкен саклауны тәэмин итү, шулай ук опекуннар яки попечительләр тарафыннан үз хокукларын яклауга таләпләрне үтәү, 2010 елның 17 ноябрендә расланган балигъ булган акылга зәгыйфь яки тулысынча акылга зәгыйфь булмаган гражданнарга карата үз бурычларын үтәү, социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе күзәтүенә урнаштырылган акылга зәгыйфь гражданның милкен саклауны тәэмин итү мәсьәләләре, опека һәм попечительлек органнарының планлы тикшерүләре предметы булырга һәм тиешле тикшерү актында чагылыш табарга тиеш дип саный.

2021 ел дәвамында инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына керүен тәэмин итү буенча чаралар кабул итүгә юнәлтелгән актив эш дәвам итте. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм җәмәгатьчелек активистлары белән без, узган елның май-июнь айларында сәүдә үзәкләрендә һәм аларга якын территорияләрдә (Казан шәһәрендә барлыгы 52 объект) уңайлы тирәлекне оештыруны тикшердек.

Үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча сәүдә үзәкләре хакимиятләренә булган кимчелекләрне бетерү турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Әйтик, Казан шәһәренең «Кольцо» сәүдә-күңел ачу үзәгендә безнең тәкъдимнәрне караганнан соң сәүдә үзәгенә керү юлында булган пандус янындагы персоналны чакыру кнопкасы ремонтланды, аз хәрәкәтләнә торган төркем өчен кирәкле аерым бәдрәф оештырылды, баскыч кырыйларында контраст маркировка яңартылды.

Үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча «Аз хәрәкәтләнә торган төркем өчен социаль әһәмиятле объектларда уңайлы тирәлекне оештыру» темасына семинар үткәрелде, аннан соң Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре 2021 елның икенче яртысында башка муниципаль берәмлекләрдә дә шундый тикшерүләр үткәрде (барлыгы 200 сәүдә үзәге).

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында без инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керүен тәэмин итү турындагы мөрәҗәгатьләр буенча кабул ителгән чараларны даими анализладык.

Әйтик, мәгълүмат системасының баш модераторы буларак, без Чаллы шәһәрендә кайбер мөрәҗәгатьләрне хәл итү буенча ризасызлыгыбызны белдердек. Нәтиҗәдә бер җәмәгать туклануы оешмасына керү юлына, шулай ук Чаллы шәһәре мэрының җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсенә керү юлына тактиль плитәсе кую буенча чаралар кабул ителде. Күпфатирлы йорт территориясендә һәм Чаллы шәһәренең Чулман проспектындагы җәяүлеләр зонасында бордюр ташын түбәнәйтү турындагы мөрәҗәгатьләр дә уңай хәл ителде.

Инвалидларны тернәкләндерүнең мөһим өлеше булып аларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү тора.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы бүлеге мәгълүматы буенча, 2021 елда 15 мең инвалид 363 миллион сумлык махсус урын-җир җыелмасы, подгузник, 3974 кеше 155 миллион сумлык утыргыч-коляска белән тәэмин ителгән.

Шул ук вакытта, үткәрелгән эшкә карамастан, Вәкаләтле вәкилгә техник тернәкләндерү чараларын үзвакытында яки тулысынча бирмәүләре турында мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә. Шушы уңайдан, гамәлдәге законда инвалид үзе сатып алган техник тернәкләндерү чарасы яки мөстәкыйль күрсәтелгән хезмәт өчен компенсация түләү механизмы каралуын билгеләп үтәбез.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының төбәк бүлеге мәгълүматы буенча, 2021 елда шундый компенсация түләүне сорап 7687 мөрәҗәгать килгән, шуларның 7260ына компенсация түләнгән.

Компенсация күләмен вәкаләтле орган сатып алынган техник тернәкләндерү чарасы яки күрсәтелгән хезмәтнең соңгы вакыттагы нәтиҗәләре буенча билгели, мөстәкыйль рәвештә сатып алынган техник тернәкләндерү чарасы яки күрсәтелгән хезмәт өчен якынча компенсация күләме турындагы мәгълүмат вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының төбәк бүлеге рәсми сайтында (http://fss16.ru) урнаштырылган мәгълүматны анализлау нәтиҗәсендә шул ачыкланды, «Инвалидларны ТСР, ПОИ һәм санатор-курорт дәвалануы белән тәэмин итү» бүлегендә тернәкләндерү чаралары һәм инвалидка күрсәтелә торган хезмәтләр (умырткалыкның муен өлеше өчен бандаж, тиешле протез һәм башкалар) федераль исемлеге кысаларында, техник тернәкләндерү чараларының (әйберләрнең) 22 позициясе буенча техник тернәкләндерү чарасы (әйберләр) бәясе турындагы мәгълүмат юк.

Вәкаләтле вәкил дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының төбәк бүлегенә әлеге позицияләр буенча техник тернәкләндерү чаралары бәясе турында мәгълүмат булмауның сәбәбен ачыклау өчен хат җибәрде.

Әлеге хаттан соң дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының төбәк бүлеге техник тернәкләндерү чаралары (әйберләре) бәясе турындагы мәгълүматны яңартты, 19 техник тернәкләндерү чаралары (әйберләре) бәясе турында мәгълүматны өстәде. Калган 13 техник тернәкләндерү чаралары (әйберләре) турындагы мәгълүмат күрсәтелгән техник тернәкләндерү чараларын сатып алу уздыргач урнаштырылачак.

Инвалидларның социаль яклауга хокукларын тәэмин итү буенча чаралар кабул ителүгә юнәтелгән актив эш формаларын куллану киләчәктә дә дәвам итәчәк.

3.3. Сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокук

Кешегә тумыштан бирелгән һәм дәүләт тарафыннан саклана торган аерылгысыз байлык ул – сәламәтлек. Россия Федерациясе Конституциясе аны әһәмиятле кыйммәтләр исәбенә кертә, һәркемгә сәламәтлек саклауга, медицина һәм социаль ярдәмгә хокукны гарантия бирә.

Гамәлдәге законга ярашлы рәвештә, сәламәтлек саклауга хокукны тормышка ашыруны гарантияләүнең берсе – сыйфатлы, куркынычсыз һәм кыйммәт булмаган дарулар.

Вәкаләтле вәкил адресына ташламаларга ия гражданнарны дару белән тәэмин итүгә кагылышлы мөрәҗәгатьләр даими килде. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчеләрне кирәкле дару препаратлары белән тулысынча тәэмин итү турында мәгълүмат алганчыга кадәр Вәкаләтле вәкил контролендә булды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча 2021 елда ташламага ия гражданнарны медицина әйберләре белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан 1,815 миллиард сум, республика бюджетыннан 1,090 миллиард сум акча бүленгән.

Шулай булса да, ташламалы дарулар белән тәэмин итү өчен бүленә торган акча җитәрлек түгел. 2021 елда якынча 3 миллиард сум акча җитмәде.

Үз чиратында, Вәкаләтле вәкил гадәти булмаган очракларда, ташламага ия гражданнарны дару препаратлары белән тәэмин итү өчен финанс мөмкинлеге табуны сорап, республика җитәкчелегенә үтенеч белән чыгуны кирәк дип санады.

Әйтик, безнең адреска Түбән Кама шәһәрендә яшәүчедән мөрәҗәгать керде, ул инвалид кызы өчен Д.Рогачев исемендәге НМИЦ федераль учреждениесе заключениесе буенча Россия Федерациясе территориясендә теркәлмәгән «Гамманорм» дару препараты билгеләнүен хәбәр итте. Бала 2021 елның августына кадәр «РУСФОНД» хәйрия фонды исәбенә дару белән тәэмин ителде. Балигъ булмаган баланы өзлексез дару препараты белән тәэмин итү финанслау булмау аркасында кыенлашты.

Вәкаләтле вәкил республика җитәкчелегенә кыйммәтле дару препараты сатып алу өчен акча бүлеп бирү турындагы мәсьәләне карауны сорап мөрәҗәгать итте. Республика хөкүмәте акча табып, бала дару препараты белән тәэмин ителде.

Сәламәтлек саклауга хокукны тормышка ашыруның аерылгысыз элементы – беренчел медико-санитар ярдәм күрсәтү. Табибка кабул ителүгә кереп булмау яки озак вакыт көтү турында төрле чыганаклардан мәгълүмат алгач, без һәр очракны тикшердек, мәгълүмат расланган очракта сәламәтлек саклау учреждениеләре игътибарын гражданның медицина ярдәменә хокукын тәэмин итәргә кирәклегенә юнәлттек.

Вәкаләтле вәкилгә Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлегендә яшәүчедән яңа туган балага Габишев амбулаториясендә врач-педиатр булмау һәм шәфкать туташының декрет ялында булуы сәбәпле планлы тикшеренү үткәрелмәве һәм вакцина ясамаулары турында мөрәҗәгать керде. Мөрәҗәгатьтән күренгәнчә, баланы икенче медицина учреждениесенә җибәрмәгәннәр.

Вәкаләтле вәкил Габишев амбулаториясендә табиб-педиатр яңа туган балага медицина ярдәме күрсәтүне оештыру буенча оператив чаралар күрсен өчен «Лаеш үзәк район хастаханәсе»нең баш табибына хат җибәрде. «Лаеш үзәк район хастаханәсе» табиб-педиатрның график буенча баланы кабул итүе турында җавап хаты җибәрде.

Табиб кабул итүенә язылу буенча хәлне күзәтү «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау юлы белән тормышка ашырылды. «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча килгән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны, шулай ук күп шикаять килгән сәламәтлек саклау учреждениеләре турында аналитик мәгълүмат Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелде.

2021 елда республикада яшәүчеләр «Табибка кабул ителүгә язылу» хезмәте күрсәтү сыйфатын Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм «ТР хезмәтләре» мобиль кушымтасы аша (199 мең тапкыр) ешрак бәяли башладылар.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендә дөнья күргән 1319 нчы карары белән расланган халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне оештыру һәм үткәрү тәртибен күзәтүче модератор сыйфатында, без «Табибка кабул ителүгә язылу» хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләрен анализлап, түбән бәяләр куелган сәламәтлек саклау учреждениеләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрдек.

2020 елдагы кебек үк гражданнарның инвалид итеп тануга хокукларын бозу турындагы мөрәҗәгатьләргә игътибарны юнәлттек. 2021 елда әлеге уңайдан медицина оешмасының медико-социаль экспертизага белешмә рәсмиләштерү буенча чаралар оештырмавы турында гражданнардан берничә мөрәҗәгать керде.

Әйтик, «ГЛОНАСС+112» системасы буенча Аксубай районында яшәүчедән 2020 елның октябрендә инсульт булган анасы мәнфәгатьләрен кайгырткан мөрәҗәгать керде. Сөйләшү барышында мөрәҗәгать итүче барлык кирәкле диагностика процедуралары үтүләрен әйтте, ләкин медицина оешмасы хезмәткәрләре медико-социаль экспертизага җибәрү өчен форма тутырмаган.

Вәкаләтле вәкил килеп туган хәлне аңлатуны сорап «Аксубай үзәк район хастаханәсе»нә хат җибәрде. Җаваптан аңлашылганча, граждан медико-социаль экспертизага оештыру җитмәгәнлектән җибәрелмәгән. Шуннан соң документлар медико-социаль экспертизага җибәрелеп, гражданга инвалидлык бирелде.

Түбән Кама районында яшәүче дә медико-социаль экспертизага җибәрү вакыты төгәл билгеләнмәве турында хәбәр итте. Без «Түбән Кама үзәк район күп профильле хастаханә» баш табибына мөрәҗәгать иткәннән соң, тиешле документлар эшләнде.

Шундый ук мөрәҗәгать Яшел Үзән районыннан да килде.

Проблемалы мәсьәләләрне күзәтүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы кысаларында амбулатор-сырхауханә ярдәме күрсәтүне тормышка ашыручы медицина оешмалары белгечләренә үзвакытында язылуны оештыру буенча өстәмә чаралар кабул итү максатка ярашлы булыр иде дип саныйбыз. Шулай ук, безнеңчә, кирәкле диагностика, дәвалау һәм тернәкләндерү яки абилитация чаралары үткәргәннән соң медицина оешмаларының гражданнарны медико-социаль экспертизага җибәрүен рәсмиләштерү процедурасын тәртипкә салу отышлы булыр иде.

3.4. Белем алуга хокук

Гражданнарның төп конституциячел хокукларының берсе – белем алуга хокук. Хәзерге вакытта белем бирү оешмалары баланы тәрбияләү һәм үстерү өчен төп социаль тирәлек булып тора. Нәкъ менә алар алдында актив гражданлык позициясенә ия, тормышта лаеклы урын алырга сәләтле югары белемле шәхес тәрбияләү бурычы тора.

Вәкаләтле вәкил ел дәвамында гражданнарның белемгә хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мөрәҗәгатьләр карады, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат җыелды һәм анализланды, белемгә хокукны тормышка ашыруның кайбер проблемаларын өйрәнү һәм тәкъдимнәр кертү буенча даими төстә мәгариф системасы эше турында мәгълүмат булган массакүләм мәгълүмат чаралары күзәтеп барылды.

Мәгариф эшләрендә катнашучылар белән актив хезмәттәшлек итү һәм мәгариф турында законнар таләпләрен бозу фактларына оператив җавап бирү өчен, Вәкаләтле вәкил уку елы башында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты вәкилләрен чакырып, «кайнар элемтә» үткәрде, аралашу барышында 138 мөрәҗәгать керде.

Аерым алганда, узган елда Вәкаләтле вәкил хокук саклау эшчәнлеген балаларны мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмаларына кабул итү, балаларны мәгариф оешмаларына китертүне тәэмин итү, мәгариф процессында катнашучылар арасындагы низаглы хәлләрне хәл итү, сәламәтлекләре чикләнгән балаларны ике тапкыр бушлай ашатуны тәэмин итү мәсьәләләре буенча тормышка ашырды.

Белем бирүне тәэмин итү максатларында республикада мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар тормышка ашырыла. 2021 елда Татарстан Республикасында 17 балалар бакчасы төзелде, шуларның 13е – «Демография» илкүләм проекты кысаларында, 3 балалар бакчасы – «Торак һәм шәһәр тирәлеге» проекты кысаларында, 1 балалар бакчасы республика акчасына. Барлыгы – 3220 урын, шул исәптән, 3 яшьтән 7 яшькә кадәр балалар өчен – 1722 урын. Узган елда җиде яңа мәктәп төзелеп, кулланышка тапшырылды. Шул ук вакытта федераль үзәктән ике мәктәп өчен генә өлешчә акча бирелде.

Күрелгән чараларга карамастан, белем бирү белән тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләр, мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмаларында да, гомуми белем бирү учреждениеләрендә дә актуальлеген югалтмый.

Гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, баланы кабул итүдән баш тартуның бердәнбер сәбәбе – белем бирү оешмаларында буш урыннар булмавы. Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмаларына кабул итүдән башка сәбәпләр белән баш тартканда чаралар күрде.

Әйтик, Лаеш районында яшәүченең баласын балалар бакчасында урын белән тәэмин итмәүләре турындагы мөрәҗәгатьне карап, без, педагогик кадрлар һәм техник персонал җитмәү аркасында урын бирүдән баш тартуны ачыкладык. Балалар бакчасының гомуми проект куәте 260 урын тәшкил итә, 14 төркем бар. 2021 елның 6 сентябрендә бакчада 197 бала тәрбияләнгән, 9 төркем эшләгән. Вәкаләтле вәкил булган педагогик составтан чыгып, бакчага өстәмә балалар алырга мөмкин дип тапты, нәтиҗәдә бакчага 27 бала алынды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматны анализлау Лаеш районының һәм, республиканың башка муниципаль берәмлекләрендә дә педагогик кадрлар кытлыгы күзәтелүен дәлилли. Әйтик, Казанда – 1497, Чаллыда – 489, Түбән Кама районында – 513, Әлмәт районында – 96, Яшел Үзән районында – 80, Алабуга районында – 68, Биектау районында – 76 кеше (мәгълүматлар 2021 елның 1 декабренә). Тулаем алганда бу көнгә республикада балалар бакчаларында 3095 педагогик хезмәткәргә ачык вакансия бар иде.

Әйтелгәннәрдән чыгып, педагогик кадрлар белән тулысынча тәэмин ителмәгән мәктәпкәчә яшьтәге мәгариф оешмалары буенча мәгариф идарәсе муниципаль органнарына сәбәпләрне ачыкларга, шулай ук вакантлы урыннарга персонал алу буенча тиешле чаралар күрелгәнме (вакансияләр турында мәшгульлек органнарына мәгълүмат бирелгәнме, массакүләм мәгълүмат чараларына, интернетка мәгълүмат урнаштырылганмы, уку йортларында соңгы курсларда укучыларга мөрәҗәгать ителгәнме), шуны ачыкларга кирәк дип саныйбыз. Болар буенча мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрен педагогик кадрлар белән тәэмин итүнең өстәмә ысуллары карарга булыр иде.

Мәгариф өлкәсендә масштаблы проблемаларның берсе – яңа микрорайоннарда гомуми белем бирү учреждениеләре җитешмәү. Шунлыктан гражданнар өчен балигъ булмаган балаларның уку урынына йөртүне оештыру актуаль икәнен әйтергә кирәк. Еш кына Вәкаләтле вәкил балаларны мәгариф оешмаларына кадәр илтү һәм куркынычсыз оештыру белән бәйле мәсьәләләрне чишүгә ныклы игътибар бирде.

Әйтик, безнең адреска Березовка, Подлесный бистәсендә яшәүчеләрдән, Бөгелмәнең «Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясе»ндә белем алучылардан балалар өчен мәктәп маршрут автобусы булмау турында 11 мөрәҗәгать керде. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен Вәкаләтле вәкил Бөгелмә муниципаль районы башлыгына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасарына хат җибәрде. Хезмәте вакытта мәсьәлә уңай хәл ителде, 2021 елның 29 декабрендә «Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясе»нә мәктәп автобусы бирелде.

Шулай ук «кайнар элемтә» вакытында ата-аналардан кергән мөрәҗәгатькә дә уңай хәл ителде. Алар Питрәч муниципаль районының Көек авылындагы «Алгоритм» технологик лицеена балалар йөртү өчен мәктәп автобусы бирүен сораган иде.

Тулаем алганда, 2021 елда муниципаль берәмлекләр 294538560,00 сумлык 120 яңа автобус алды.

Балаларның уңышлы булуы һәм гармонияле үсүе өчен уңайлы уку шартлары тудыру аерылгысыз шарт булып тора. Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил мәгариф мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында килеп туган низаглы хәлләр турындагы шикаятьләрне карады.

Андый эшчәнлектә мөрәҗәгатьләр алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты һәм муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре хезмәткәрләре белән берлектә күчмә тикшерүләр үткәрүне кирәк дип санады.

Практика шуны күрсәтә, мәктәптәге низаглы хәлләр сәбәпләренең берсе – сыйныфта уңайлы, әхлакый-психологик климат булдыру буенча мәгариф оешмасы җитәкчесе һәм сыйныф җитәкчесе ягыннан үзвакытында тиешле чаралар күрелмәү.

Мәсәлән, Түбән Кама районыннан килгән мөрәҗәгать итүченең улы белән сыйныфташлары арасында килеп чыккан киеренке хәл турындагы мөрәҗәгатьне караганда, без сыйныф җитәкчесе ягыннан педагогик этика бозылуы, сыйныфта килеп туган низаглы хәлне бетерү буенча чаралар күрелмәве турында белдек.

Кайвакыт низагта мәгариф оешмасы җитәкчесе үзе гаепле булып чыга. Без Казан шәһәренең Киров районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 135 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе» учреждениеләрендә җитәкчеләре ягыннан педагогик этика бозылуын ачыкладык. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мәгариф оешмалары җитәкчеләре дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Бәхәсләрне мәгариф оешмаларында хәл итү практикасы нәтиҗәле түгел һәм ныклы игътибар таләп итә. Югары әйтелгәннәрдән чыгып, мәгариф идарәсе муниципаль органнарына белем бирү оешмаларында низаглы хәлләрне булдырмау һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләре ягыннан педагогик этиканы саклау буенча өстәмә чаралар күрергә кирәк дип саныйм.

Мәгариф оешмаларының гамәлләре белем бирү процессында уңайлы психологик-педагогик шартлар тудыруга юнәлтелгән булырга тиеш. Һәр бала булган физик, интеллектуаль, социаль, эмоциональ, тел һәм башка үзенчәлекләренә карамастан, гомуми, бердәм һәм тулы белем бирү, тәрбияләү, үсү һәм социальләшү процессына җәлеп ителергә тиеш. Сәламәтлекләре чикле балаларга аерым игътибар таләп ителә.

Татарстан Республикасында сәламәтлеге чикле һәм инвалидлыгы булган балаларны укыту системасы булдырылган һәм үстерелә.

53 мәгариф оешмасы һәм 2 санатор мәктәп-интернатлар базасында яраклаштырылган төп белем бирү программасы тормышка ашырыла. 183 инклюзив мәктәп сәламәтлекләре чикле һәм интеллектуаль кимчелекләре булган укучыларны башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән тәэмин итә. «Ресурс сыйныфы» моделен кертү өчен 5 гомуми белем бирү мәктәбе билгеләнгән, болар: Казан шәһәренең Мәскәү районы «65 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Авиатөзелеш районы «Соматик авырулы балалар өчен 168 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Идел буе районы «97 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Совет районы 156 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе», Әлмәт шәһәренең «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе – «Дай 5» мәгариф үзәге».

Кызганычка, сәламәтлекләре чикле балаларның ата-аналарыннан килгән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре мәгариф оешмаларында физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләү өчен кадрлар җитмәүне күрсәтә.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына сәламәтлекләре чикле балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) Казан шәһәре Совет районы «11 нче күппрофильле лицей»да сәламәтлекләре чикле балалар өчен белем бирүне тиешенчә оештырмау турында шикаять керде. 2021 елда лицейда интеллектуаль кимчелекләре булган балалар өчен башлангыч белем бирү сыйныфы ачылган булган. Интеллектуаль кимчелекләре булган балаларны укыту өчен 1 сентябрьдән лицейның штат расписаниесенә үзгәрешләр кертелгән, 0,35 ставкага педагог-психолог, 0,75 ставкага логопед-укытучы, 0,75 ставкага укытучы-дефектолог, 4 ставкага тьютор, 1 ставкага социаль педагог билгеләнгән. Ләкин тикшерү вакытына лицейда тиешле кадрлар юк иде. Вакантлы вазыйфалар турында мәшгульлек үзәгенә мәгълүмат та җибәрелмәгән иде, бу уңайдан Вәкаләтле вәкил лицейны педагогик кадрлар белән тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрүен сорап, Казан шәһәре мәгариф идарәсе җитәкчесенә хат җибәрде (доклад язылган вакытта Вәкаләтле вәкил хаты карауда иде).

Һичшиксез, сәламәтлекләре чикле балаларны тормышка яраклаштыру һәм укыту процессында квалификацияле кадрлар мөһим роль уйный, грамоталы төзелгән мөнәсәбәтләрдән баланың алга таба җәмгыятьтәге хәле тора.

Безнең адреска Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәрендә яшәүче укучының анасыннан мөрәҗәгать килде, ул сөйләмендә тоткарлык булган һәм аутик спектрда тәртибе бозылган бала белән тиешенчә эшләмәүләреннән зарланган.

Аерым алганда, сентябрьдә мәктәпкә беренче сыйныфка беренче тапкыр килгән балага, сыйныф җитәкчесе, бала программа материалларын үзләштергәндә авырлык кичерә һәм барлык фәннәрдән начар өлгерә, әйләнә-тирәдәгеләргә комачаулык тудыра, уенга яки әңгәмәгә кушылып, кешеләргә бәйләнә, дигән характеристика бирә. Бирелгән характеристикада шулай ук «мондый укучының – укытучы өчен еш баш авыртуы», икәнлеге күрсәтелә. Урынга барып тикшерү мәктәп җитәкчелеге һәм сыйныф җитәкчесе тарафыннан эшне тиешенчә оештырмауны күрсәтте, мәктәптә аутизмлы баланы укыту өчен махсус шартлар тудырылмаган.

Сәламәтлекләре чикле балаларның ата-аналары мөрәҗәгатьләрен караудан тыш, Вәкаләтле вәкил «Үзенчәлекле балалар.Татарстан» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек итеп, сәламәтлекләре чикле балаларга һәм инвалидларга карата толерант мөнәсәбәтне үстерү, балаларны үстерү, абилитацияләү һәм укытуның уңышлы практикасын башка белгечләргә: педагогларга, психологларга, тьюторларга, волонтерларга, социаль хезмәткәрләргә тарату юнәлешләре буенча социаль проектларны тормышка ашыруда катнашты.

Сәламәтлекләре чикле балалар өчен уңайлы шартлар тудыру кирәклеген билгеләп, сәламәтлекләре чикле балалар өчен мәгариф оешмаларында бушлай ике тапкыр ашатуга хокукны тормышка ашыру мәсьәләсен телгә алмый булмый.

Сәламәтлекләре чикле балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) сәламәтлекләре чикле балаларны бушлай ике тапкыр ашатмаулары турында күп санлы мөрәҗәгатьләр алып, Вәкаләтле вәкил республиканың муниципаль берәмлекләренә хатлар җибәрде. Килгән җаваплардан күренгәнчә, сәламәтлекләре чикле балаларны мәктәпләрдә ике тапкыр ашатуны оештыру буенча бердәм карар юк, бүленгән бюджет акчасы күләме бер кешегә исәпләгәндә шактый аерылырга мөмкин. 19 муниципаль берәмлекләрдә сәламәтлекләре чикле балаларны ике тапкыр ашату өчен бюджеттан акча каралмаган, шул ук вакытта муниципаль берәмлекләр сәламәтлекләре чикле балаларны бушлай ике тапкыр ашатуны оештыру буенча финанслау мәсьәләләре 2022 елга муниципаль район бюджетын формалаштырганда каралачак, дип хәбәр итте.

2021 елның декабрь башында Вәкаләтле вәкил муниципаль берәмлекләргә тагын хат җибәрде. Тәкъдим ителгән мәгълүматны анализлау шуны күрсәтте, 2022 елга сәламәтлекләре чикле балаларны ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү өчен Әтнә һәм Түбән Кама районнары җирле бюджеттан акча бүлмәгән. Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары 2022 елда бюджетка өстәмә акча кергән очракта сәламәтлекләре чикле балаларны мәктәпләрдә бушлай ике тапкыр ашату өчен акча бүлеп бирергә тиеш, дип саный.

Күрсәтелгән проблемалы мәсьәләләр аларны финанслау юлы белән дә, тиешле карар кабул итү юлы белән дә хәл ителергә тиеш.

3.5. Торакка хокук

Кешенең тормыш дәрәҗәсе аның торакка хокукын тормышка ашыру белән тыгыз бәйләнгән. Торак белән тәэмин ителмәү башка социаль-икътисади хокукларны тормышка ашыруга тоткарлык тудыра. Кешегә торак кирәклеге турында халыкара-хокукый актларда да әйтелгән, Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән ныгытылган.

Торакка конституцион хокук, табыш дәрәҗәсенә яки икътисади ресурсларга ия булу-булмауга карамастан, барлык кешегә тәэмин ителергә тиеш. Әлеге хокукны тәэмин итү барлык теләүчеләргә торак биналарын алга таба бүлү өчен акча туплауны аңлатмый. Торакны сатып алу яки аны төзү күп кенә гражданнарның үз сайлавы булып тора, ләкин дәүләтнең һәм җирле үзидарә органнарының роле – торак төзелешен үстерүгә булышлык итүдә. Аз тәэмин ителгән, шулай ук законнарда күрсәтелгән шундый гражданнарның фатир мәсьәләсен хәл итү кешенең шәхси карары дип исәпләнә алмый.

Татарстан Республикасы торак төзү буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында лидерларның берсе булып кала. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматына караганда, 2021 елда 3011 мең квадрат метр торак төзелгән.

Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкилгә социаль яктан аз якланган кешеләрдән элеккечә үк торак шартларын яхшыртуны сораган мөрәҗәгатьләр килә. Аерым алганда, алар социаль найм яки социаль кулланудагы торак фонды торак бинасын алып тору килешүе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ итеп танудан баш тартудан зарланалар.

Әйтик, безнең адреска Татарстан Республикасы Мамадыш районында яшәүче мөрәҗәгать итте, аларның гаиләсен социаль кулланудагы торак фонды торак бинасын найм килешүе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ итеп танымаганнар. Безгә мөрәҗәгать иткән кешенең дәлилләре нигезле дип табылды һәм Вәкаләтле вәкил катнашыннан соң, аңа тәкъдим ителгән документлар җирле үзидарә органында кабаттан каралды. Нәтиҗәдә аның гаризасы канәгатьләндерелде.

Вәкаләтле вәкил муниципаль торак фондыннан бирелгән торакның закон таләпләренә туры килмәве турында язган татарстанлылар мөрәҗәгатьләре буенча да чаралар күрде.

Безнең адреска Татарстан Республикасы Менделеевск районында акылга зәгыйфь дип табылган кешегә икенче торакны агымдагы ремонт үткәрмичә бирүләре турында мөрәҗәгать тә керде. Бик теләсә дә, үзенең хокукый статусы нәтиҗәсендә ул анда үзе ремонт ясый алмас иде. Нәтиҗәдә шундый хәл килеп чыккан, бирелгән квартирда кеше яши алмаган, ләкин аның мәнфәгатьләрен кайгыртып мөрәҗәгать иткән кеше сүзләренә караганда, коммуналь хезмәтләр вакытында түләнеп барган.

Без җирле үзидарә органына ремонт эшләре үткәрергә кирәклеге турында хат җибәрдек, шулай ук прокуратура органнарына хат белән мөрәҗәгать иттек. Күзәтчелек органы безнең позиция белән килеште. Алынган мәгълүматка караганда, Татарстан Республикасы Менделеевск районы прокуроры әлеге факт буенча закон бозуларны бетерүне сорап район башкарма комитеты җитәкчесенә кисәтү хаты да җибәргән.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (торак белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар һәм элек бу төргә кергән затлар исемлеген булдыручы вәкаләтле орган) ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карарлар кабул иткән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларның хокукларын яклау эшен дәвам иттек.

Кайбер очракларда, карар кабул иткәндә мөрәҗәгать итүче ялгыш махсус торак фондыннан найм килешүе буенча торак алуга мохтаҗ дип танылган, яки мохтаҗлар исемлегенә керткәндә тиешле документларны кирәгеннән артык таләп ителгән ятимнәргә карата без тиешле чаралар күрдек.

2021 елда без Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, мөрәҗәгать итүче 2000 елның 1 гыйнварына кадәр торак милкенә хокукы булу (булмау) турында техник инвентаризация органнарыннан белешмәләр китермәгән очракта, мөрәҗәгать итүчене торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертү турындагы гаризаны караудан баш тарту турындагы карарына карата чаралар күрдек.

Вәкаләтле вәкил әлеге документ вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара сораштыру нәтиҗәсендә алынган булырга мөмкинлеген исәпкә алып, әлеге таләп буенча аның хокукый позициясен аңлатуны сорап Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгать итте. Министрлык җавабыннан күренгәнчә, алар 2017 елның 6 апрелендә техник инвентаризация органыннан килгән җавапка таяна, анда БТИ ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек системасында катнашмаганлыктан, вәкаләтле орган сораган белешмәне бирүдән баш тартканнар.

Без игътибарны шуңа юнәлттек, техник инвентаризация органы җавабы Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендә дөнья күргән 397 нче карарына (күрсәтелгән норматив хокукый акт 2019 елның 18 апрелендә дөнья күргән) кадәр булган, ә яңа карарда махсус торак фондыннан торак биргәндә мохтаҗлар сыйфатында ятим балаларны исемлеккә керткәндә кирәкле документлар исемлеге билгеләнгән. Анда техник инвентаризация органыннан белешмә кирәклеге күрсәтелмәгән.

Шушы уңайдан 2021 елның апрелендә Вәкаләтле вәкил, ведомствоара хезмәттәшлеге нигезендә, министрлыкка 2000 елның 1 гыйнварына кадәр ятим балаларның милкендә торак булу-булмау турындагы белешмәләрне бушлай бирү мөмкинлеген карауны сорап, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация бюросы»на хат җибәрде. Әлеге хатка уңай җавап алынды, ул Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына эштә исәпкә алу өчен җибәрелде.

Ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларның торакка хокукларын яклау эшен без килгән шикаятьләр буенча да гына башкармадык. Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре, махсус торак фондыннан найм килешүе буенча торак алуга мохтаҗ ятим балаларны, балигъ булганга кадәр ятим балалар дип танылган 23 яшькә җиткән яшьләрне исәпкә алу мәсьәләләре буенча ведомствоара торак комиссиясе әгъзасы сыйфатында, министрлык белән үзара хезмәттәшлек итте, карарлар кабул итүдә катнашты.

Мисал өчен, ведомствоара торак комиссиясе әгъзалары катнашында Татарстан Республикасы Саба районында яшәүченең, аны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертүне сораган гаризасы каралды. Эш материалларыннан күренгәнчә, балигъ яшькә җиткәч аңа социаль ипотека системасында торак төзелешен үстерүнең дәүләт яклавы кысаларында фатирның 100 проценты күләмендә акча кертү очракта үз милке итеп алу хокукы белән вакытлыча куллану өчен фатир бирелгән.

Әлеге хәлләрне исәпкә алып, без фатирдан вакытлыча файдаланып тору хокукы гына биргән торакка найм килешүе төзү, ятим балалар исәбендәге затларны билгеләнгән социаль нормалардан ким булмаган торак белән тәэмин итү юлы була алмый, икәнен күрсәттек. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның социаль ипотека программасы буенча фатир сатып алырга җыенуын дәлилләүче гамәлләр кылуы турында мәгълүматлар юк. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы безнең фикер белән килеште һәм гаризаны карап, мөрәҗәгать итүчене торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертү турында карар кабул итте.

Яңа төзелешләргә ипотеканы субсидияләү программасын озынайту 2021 елда торак кредиты алучылар санын киметмәде. Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматы буенча Татарстан Республикасы ташламалы ипотека иң күп соралган субъектлар исемлегенә керде.

Гражданнардан торак сатып алу өчен төзелгән кредит килешүләре буенча алар белән кредит оешмалары арасында килеп чыккан хокукый мөнәсәбәтләргә кагылышлы мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкилгә еш килеп тора. 2021 елда ипотека кредиты буенча, ике яки аннан күбрәк балалары булган заемчылар өчен каралган дәүләт яклавы чараларына хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләре каралды.

Әйтик, безгә Казан шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итте, аның 2019 елның гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәрге чорда өченче баласы туган, ипотека торак кредиты алучы булып тора. Ләкин аңа 2019 елның 3 июлендә дөнья күргән 157 нче «Ипотека торак кредитлары (займнары) буенча йөкләмәләрен үтәгәндә балалары булган гаиләләрне дәүләт яклавы чаралары турында»гы Федераль закон нигезендә һәм «Гражданлык хәле актлары турында»гы Федераль законның 13.2 маддәсе буенча үзгәрешләр кертү турындагы закон нигезендә аңа ипотека торак кредиты (займы) буенча йөкләмәләрен өлешчә түләү рәвешендә дәүләт яклавы чаралары күрсәтүдән «ДОМ.РФ» җәмгыяте ташламалы ипотека кредиты бирү программасы операторы баш тарткан. Баш тартуның сәбәбе – кредит акчасы кредит килешүе шартларына ярашлы рәвештә, торак сатып алуга гына түгел, килешүне теркәү белән бәйле хезмәтләргә дә бирелгән. Мөрәҗәгатьне өйрәнеп, без мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклап чаралар кабул итүләрен сорап, кредит оешмасына хат җибәрдек. Нәтиҗәдә, банктан, мөрәҗәгать итүче кабаттан документлар тапшырган очракта клиентның дәүләт яклау чаралары алуга кагылышлы соравын яңадан карау мөмкинлеге булуы турында «ДОМ.РФ» җәмгыятеннән алынган мәгълүматка сылтама белән, җавап алдык.

Гражданнарның торакка хокукларын яклауның аерылгысыз өлеше – тиешенчә сыйфатлы торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү юлы белән торакта яшәүнең уңайлы шартларын тәэмин итү. Ел дәвамында без төрле формаларда гражданнарның торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендәге дәүләт яклавы хокукларын тәэмин итү эшен алып бардык.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый торак контроле органнары белән бергә эшләдек.

Аерым алганда, гражданнарның кайбер мәсьәләләре Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында оештырылган тематик «кайнар элемтә» телефонына мөрәҗәгать иткәндә дә хәл ителде.

2021 елның ноябрьдә үткәрелгән, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләренә кагылышлы «кайнар элемтә» телефонына күпфатирлы йортта түбә агу уңаеннан чаралар күрүне сорап Яшел Үзән шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьтән соң хезмәт күрсәтүче оешма түбәгә ремонт үткәрде.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе мәгълүматларына караганда, гражданнар мөрәҗәгатьләрендә күтәрә торган төп темалар – бу күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне тоту, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфаты, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр.

Идарәче компанияләрнең үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаулары турындагы язмача мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә җиткерелде һәм Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт торак күзәтчелеген тормышка ашыра торган орган тарафыннан тиешле чаралар күрелде.

Үз чиратында, мисал итеп шуны китерергә була, Вәкаләтле вәкилгә Казан шәһәрендә яшәүчедән идарәче оешманың коммуналь хезмәтләр өчен түләүне дөрес исәпләмәве, бу факт буенча Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенең чаралар күрмәве турында шикаять керде. Мөрәҗәгать итүченең контроль-күзәтчелек органы карары белән килешмәү хакындагы дәлилләре нигезле икәнен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә хат җибәрде. Нәтиҗәдә, гражданның мөрәҗәгатен кабат карап, контроль-күзәтчелек органы идарәче компания адресына («Фучик, 72» торак ширкәтенә) электр, кайнар һәм салкын су белән тәэмин иткәндә коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр исәпләгәндә законның мәҗбүри таләпләрен бозуга юл куярга ярамавы турында кисәтү җибәрде.

Конкрет очракларда торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау белән бер үк вакытта, ел дәвамында шулай ук аерым бер аналитик эш тә алып барылды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендә дөнья күргән 1319 нчы «Халыкка хезмәт күрсәтүне оештыру һәм сыйфатына бәя бирү тәртибен раслау турында»гы карары положениеләрен тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан һәм «ТР хезмәтләре» мобиль кушымтасыннан файдаланучы кешеләр хезмәт күрсәтүче идарәче компанияләргә куйган бәя нәтиҗәләре анализланды. Түбән бәяләр ачыкланганда мәгълүмат тиешле чаралар кабул итү өчен җаваплы башкаручыларга җиткерелде.

Әйтик, 2021 елның I квартал йомгаклары буенча без, «Иске шәһәр идарәче компаниясе» һәм «Уют-Сервис идарәче компаниясе» эшчәнлегенә түбән бәяләр куелу турындагы мәгълүматны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалыгы комитетына җибәрдек. Күрсәтелгән идарәче компанияләр хезмәткәрләре йортларда булып, йортларда яшәүчеләрнең инициатив төркемнәре белән очрашулар һәм җыелышлар оештырды, алар барлыгы торак-коммуналь хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлек тискәре бәяләнгән кимчелекләр турында мәгълүмат туплады. Алга таба бу идарәче компанияләргә куелган уртача бәя үсте.

2021 елның ноябрендә Мәскәүдә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең «Гражданнарның торакка хокукларын яклау һәм аларны тормышка ашыру өчен шартлар белән тәэмин итү» темасына багышланган координацион советы утырышы узды. Чара барышында без коллегалар игътибарын 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керәчәк Россия Федерациясенең яңа редакциядәге Торак кодексының 160 нчы маддәсе 3 өлешенә юнәлттек, аңа ярашлы рәвештә, гражданнар торак биналарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә чыгымнарны компенсацияләүдән торак биналарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүләр буенча бурычлары законлы көченә кергән суд акты белән расланган очракта гына мәхрүм ителә ала. Практикада, еш кына коммуналь хезмәтләргә тулысынча түләмәү аның исәпләнгән күләме белән риза булмаудан килеп чыкканга, без Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2011 елның 6 нчы маенда дөнья күргән 354 нче карары белән расланган күпфатирлы йортлардагы биналардан кулланучыларга һәм торак йортлар милекчеләренә коммуналь хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләренең, үтәүче тулысынча түләнмәгәнлектән, коммуналь хезмәтләр буенча бурыч булганда көченә кергән суд акты белән расланган очракта гына, кулланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү хокукына кагылышлы өлешенә федераль күләмдә үзгәрешләр кертүне сорап мөрәҗәгать иттек.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Каты коммуналь калдыклар чыгару», «Контейнер мәйданчыгы төзү», «Контейнер мәйданчыгын тоту» төрләре кертелүне исәпкә алып, 2021 елда безнең эштә аерым юнәлеш – каты коммуналь калдыклар чыгару буенча хәлне күзәтү булды.

Мәгълүмати системаның баш модераторы буларак, без каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыклары белән җиһазландырылмаган, каты көнкүреш калдыклары чыгару графигы белән риза булмаган, ләкин калдыкларны озак вакыт саклау мәйданнары булмау турында мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләрен исәпкә алмыйча, чүп чыгару графигын үзгәртүдән баш тартулары турында хәбәр иткән республика авылларында яшәүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен эшкә кире кайтардык. Нәтиҗәдә, төбәк операторы каты коммуналь калдыкларны чыгару графигына төзәтмәләр кертү турында карар кабул итте.

Каты көнкүреш калдыкларын үзәкләштерелгән җыю буенча чаралар булмавы турындагы мөрәҗәгатьләргә аерым игътибар бирелде. Мәсәлән, мониторинг нәтиҗәләре буенча, Вәкаләтле вәкил башлангычы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты Кече Алат авылыннан чүп чыгару өчен техника җибәрү эшен оештырды.

Гражданнарның каты коммуналь калдыклар чыгару буенча үтәлмәгән мөрәҗәгатьләре турындагы мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының атна саен уза торган каты көнкүреш калдыклары өлкәсендә төбәк операторлары эшен карау буенча штабы утырышында яңгырады. Алга таба төбәк операторлары кыска срокларда аларны үтәү буенча чаралар күрде. Мәсәлән, без 2021 елның беренче яртысында Лаеш муниципаль районыннан «Каты коммуналь калдыкларны чыгару» төре буенча мәгълүмат системасына килгән, үтәлмәгән мөрәҗәгатьләрнең саны артуын билгеләдек. Соңрак, аларны үтәү буенча чаралар күрелде, әмма 2021 елның икенче яртысында бу районда «Каты коммуналь калдыклар чыгару» төре буенча шикаятьләр сизелерлек кимеде.

Каты коммуналь калдыклар чыгару өлкәсендәге мәсьәләләрне карау да катнашу башка мәйданчыкларда да булды, шул исәптән рәисе Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил булган «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын тормышка ашыру буенча проектлар офисы утырышында да. Нәтиҗәдә, без Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар чыгару буенча төбәк операторларына җитештерү калдыкларын чыгарганда һәм кулланылганнан соң ... һәм әйләнә-тирә мохитне саклауга юнәлтелгән тәкъдимнәр эшләнде.

Мондый чараларны үткәрү республикада яшәүчеләрнең каты коммуналь калдыклар чыгару буенча коммуналь хезмәтләр тиешенчә күрсәтмәү һәм уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукны тормышка ашыру проблемаларына карата турындагы мөрәҗәгатьләренә оператив төстә җавап бирергә мөмкинлек бирә.

3.6. Уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокук

Кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын тормышка ашыру каксашлары социаль кыйммәт булып тора. Җитештерү эшчәнлеге исәбенә товарлар, хезмәтләр кулланучы буларак гражданнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү әйләнә-тирә мохиткә, ачык иткә, кешеләрнең иминлегенә куркыныч тудырырга тиеш түгел.

Гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын саклауны күзәтүне без, көндәлек режимда, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына, тиешле төрләр буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау белән тормышка ашырдык. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының «Экология», аерым алганда, «Чүплекләр» төре буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр саны артты. Әгәр 2020 елда «Чүплекләр» төре буенча 696 мөрәҗәгать килсә, 2021 елда – 993.

«Чүплекләр» төре буенча мәгълүмат системасына иң күп мөрәҗәгатьләр Түбән Кама (231 мөрәҗәгать) һәм Әлмәт (108 мөрәҗәгать) районнарыннан килде. Шул ук вакытта гражданнарның мөрәҗәгатьләрен үзвакытында тиешенчә карамау очраклары да булды.

Әйтик, 2021 елның июнендә без, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына Түбән Кама районы Шәңгәлче җирлегендә Сарсаз авылындагы рөхсәтсез чүплекне юкка чыгаруны сорап кергән мөрәҗәгатьнең озак вакыт башкарылмавын ачыкладык.

Аны 2021 елның ноябрь аенда бетерергә тиешләр иде. Мөрәҗәгатьне үтәү өчен куелган срок белән килешмәдек һәм эшкә кире кайтардык. Нәтиҗәдә рөхсәтсез чүплекне юкка чыгару 2021 елның июнендә башкарылды.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына баш модератор буларак Вәкаләтле вәкил оештырган эш киңәшмәсендә Әлмәт районыннан килгән шикаятьләр каралды. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты районның ике авыл җирлегендә законсыз чүплекләрне юкка чыгару буенча киң колачлы эш башкарды.

Гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә конституциячел хокукларын тормышка ашыруның төп сәбәпләренең берсе булып, физиологик һәм көнкүреш ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен җитәрлек күләмдә эчәр су белән тәэмин итүне үз эченә алган, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү тора.

2021 елның җәендә һаваның коры торуы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына торак пунктларында су белән тәэмин итүне оештыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең артуына китерде (203 мөрәҗәгатькә «ГЛОНАСС+112» мәгълүмат системасы аша килгән 134 мөрәҗәгать өстәлде). Әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьләрне хәл итү контрольгә алынды. Шуның белән бер үк вакытта без үзвакытында тиешле чаралар күрелмәгән мөрәҗәгатьләрне дә эшкә кайтардык.

Торак пунктында су белән тәэмин итүдә проблемалар булу турында Лаеш районының Октябрьнең 25 еллыгы исемендәге совхоз бистәсендә яшәүче хәбәр итте. Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты йөзендә җаваплы үтәүче әлеге мөрәҗәгатьне 2022 елның августында яңа скважина борауланачак дигән мәгълүмат җибәрү юлы белән хәл итте, әлеге эшне иртәрәк срокта үтәү мөмкин булмавын аңлатмады. Шунлыктан бу мөрәҗәгать эшкә кайтарылды һәм яңа артезиан скважинасын бораулау вакыты итеп 2021 елның ноябре билгеләнде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына күзәтүне тормышка ашыру белән бергә, Вәкаләтле вәкил контроль-күзәтчелек органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә, гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукны күпләп бозу турында мәгълүматлары булган мөрәҗәгатьләрен карады.

Безнең адреска Казан шәһәре янындагы берничә торак бистәсендә – Вознесенское, Самосырово, Привольный, Вишневка, Яңа Вишневка, «Весна» торак комплексы, «Светлая Долина» торак комплексы, Константиновка, Салмачы, «Дорожник», «Полимер» бакчачылык ширкәтләрендә яшәүчеләрдән «Восточный» чүп полигонын кулланганда аларның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокуклары бозылу турында мөрәҗәгатьләр керде. Аерым алганда, мөрәҗәгать итүчеләр «Восточный» полигоны зонасында тиешледән артык пычратучы матдәләр булу фактлары буенча оператив чара күрелмәве турында әйттеләр, полигоннан килгән сасы ис сәламәтлек торышында тискәре чагыла.

Китерелгән дәлилләрне дә исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Аппаратында кызыксынган ведомстволар һәм гражданнарның инициатив төркеме белән эш киңәшмәсе үткәрелде. Алга таба Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне карау кысаларында «Восточный» чүп полигоны йогынтысы зонасында оператив төстә һаваның лаборатор контролен уздыру максатыннан, «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет учреждениесе белән бергә, мөрәҗәгать итүчеләр белән группа чаты аша аралашуны оештырды.

Тулаем алганда, Вәкаләтле вәкилнең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә кеше хокукларын яклау буенча эшчәнлеге контроль-күзәтчелек органнары һәм җирле үзидарә органнары белән бергә тыгыз хезмәттәшлектә тормышка ашырылды.

Кешенең социаль хокукларын яклау буенча эшчәнлеккә йомгак ясап, шуны билгеләргә була, узган ел дәвамында безнең адреска шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яңа короновирус инфекциясен таратмау максатыннан чикләү чаралары билгеләү белән бәйле мәсьәләләр буенча шактый мөрәҗәгать килде. Бу өлкәдә киң таралган мәсьәләләр буенча Вәкаләтле вәкил позициясе рәсми сайтта һәм социаль челтәрләрдә чагылыш тапты.

4 бүлек. Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау

4.1. Җинаять-җәза системасы учреждениеләрендә кеше хокукларын яклау

Гамәлдәге федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр пенитенциар система учреждениеләре эшчәнлегенә контрольлек итүче субъектлар булып тора.

2021 елда Вәкаләтле вәкил, җинаятьләр кылуда шикләнелгән һәм гаепләнелгән, сак астына алынган, иректән мәхрүм итү рәвешендә яисә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче хөкем ителгән кешеләр, җинаять-суд эше тәртибендә медицина характерындагы мәҗбүри эшләр кулланылган гражданнар, административ арест рәвешендә җәза билгеләнгән затлар хокукларын яклау белән бәйле мәсьәләләргә ныклы игътибар бирде.

Узган елны Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә тотылучы кешеләрдән 371 мөрәҗәгать килде.

Шикаятьләр караудан тыш, төзәтү учреждениеләрендә тотылучы тоткыннар өчен видеоконференцэлемтә режимында дәүләт органнары, Россия Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасындагы идарәсе вәкилләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе әгъзалары белән бергә, төзәтү учреждениеләрендә җәза үтәү мәсьәләләре буенча «Хокукый ярдәм көне» үткәрү практикасы дәвам итте.

2021 елда «Хокукый ярдәм көне» кысаларында барлыгы 4 тематик кабул итү үткәрелде, 31 тоткын кабул ителде.

Аерым проблемалы мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, Вәкаләтле вәкил прокуратура, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе, 16 нчы медицина часте, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында эш киңәшмәләре оештырды.

Әйтик, мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы кешеләрнең хокукларын тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән теге яки бу йогышлы авырулар булганда ярдәм күрсәтү белән бәйле мәсьәләләр бергәләшеп каралды. 2021 елда төзәтү учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтүгә кагылышлы 75 мөрәҗәгать керде.

Тулаем вазгыятьне бәяләп, төзәтү учреждениеләрендә ВИЧ-инфекциясе һәм туберкулез белән беренчел чирләү очраклары кимүне билгеләргә була. ВИЧ-инфекциялеләрне югары актив антиретровирус терапиясенә җәлеп итү арта, яңа медицина җиһазлары сатып алып медицина частьларының матди-техник базасы камилләштерелә, аерым төбәкләрдә ВИЧ-инфекциясен, вируслы гепатит, туберкулезны тикшерү өчен лабораторияләр булдырыла.

Икенче яктан, медицина ярдәме күрсәтүгә хокуклар бозылуга шикаятьләрне караганда шуңа игътибар иттек, кайбер очракларда мөрәҗәгать итүченең дәлилләре нигезле иде.

Мәсәлән, йогышлы авыру-үпкә туберкулезы булса да стационарда тикшерүдән баш тартуларыннан зарланып, Вәкаләтле вәкилгә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 3 нче тикшерү изоляторында тотылучы мөрәҗәгать итте. Безнең катнаштан соң мөрәҗәгать итүче стационар тикшеренүгә һәм алга таба дәвалау өчен «Хастаханә» бүлегенә җибәрелде.

Шундый ук чаралар Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 5 нче төзәтү колониясендә җәза үтәүче граждан Т. мөрәҗәгате буенча да кабул ителде. Ул узган елның ноябрендә Вәкаләтле вәкилгә, шикәр диабеты белән авырганлыктан аны дәвалау һәм өстәмә тикшерүне сорап мөрәҗәгать иткән иде.

Прокуратура органнары, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы медицина часте һәм Россия Федерациясенең Идел буе федераль округындагы субъектларының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре белән бергә хезмәттәшлек итеп, без каты авырган тоткыннарны җәза үтәүдән азат итү белән бәйле мәсьәләләрне өйрәндек.

2021 елның 10 аенда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы медик-санитар частенең авыру аркасында тоткыннарны тәкъдим ителә торган хөкем ителгәннәрне медицина тикшерүе комиссиясе белән 48 тикшерү үткәрде. Азат итүгә 41 кеше тәкъдим ителде, 35 кеше азат ителде (2020 елда тикшерелгән кешеләрне исәпкә алып), судка кадәр 5 кеше үлде, суд карары законлы көченә кергәнче 3 кеше үлде, суд 5 кешене азат итүне кире какты (шуларның берсе соңрак үлде).

Әлеге проблема Россия Федерациясенең башка субъектларына да хас булуын исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил хәлгә, узган елның майда Красноярск шәһәрендә узган Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр Бөтенроссия координацион советында «Хөкем ителгәннәрне һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәрне тормышка яраклаштыру контекстында медицина ярдәме күрсәтү» темасы буенча докладында үз бәясен бирде, советта Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2004 елның 6 февралендә дөнья күргән 54 нче карары белән расланган, авыру сәбәпле җәза үтәүдән азат итү турында сораган хөкем ителгәннәргә булышу өчен медицина тикшерүе кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр яңгырады.

Узган ел дәвамында Вәкаләтле вәкил иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче гражданнарның хокукларын, социаль яклауга хокукларын торгызуга юнәлтелгән чараларны күрде.

Сәламәтлеген югалткан очракта гражданның социаль яклану принципы үтәлергә тиеш. Инвалид булган гражданнарның иректән мәхрүм итү урыннарында булуы, аларны булган шәхси тернәкләндерү һәм абилитация программалары буенча тиешле техник тернәкләндерү чараларына хокукларыннан мәхрүм итәргә тиеш түгел.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә тотылучы 1 нче, 2 нче, 3 нче төркем инвалидлар булган шикләнелүче, гаепләнүче һәм хөкем ителгән кешеләр саны – 238. Шулардан беренче төркем инвалидлар – 6, икенче төркем инвалидлар – 113, өченче төркем инвалидлар – 119.

Вәкаләтле вәкилгә 2021 елның октябрендә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең 8 нче төзәтү колониясендә җәза үтәүче, 2 нче төркем инвалид, хөкем ителгән граждан Б. калган тернәкләндерү техник чарасын алу кирәклеген сорап мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүченең шикаятен карау барышында шул ачыкланды, үткәрелгән медико-социаль экспертиза нәтиҗәләре буенча аңа бер елга шәхси тернәкләндерү программасы эшләнгән.

Катгый чикләүләрне компенсацияләү максатыннан аңа дәвалану-күнегүләр үткәрү өчен аңа техник тернәкләндерү чаралары: протез бот һәм коену өчен протез бот тәкъдим ителде. Аны протез белән тәэмин итү мәсьәләсе ел буе хәл ителмәде һәм әлеге чорда мөрәҗәгать итүче бары таяклар белән генә йөри алды.

Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесенә мөрәҗәгать итүче шәхси тернәкләндерү программасы ярашлы рәвештә аңа тиешле техник тернәкләндерү чараларын алу буенча чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать итте. Алынган мәгълүматтан күренгәнчә, Б.га күрсәтелгән техник тернәкләндерү чаралары бирелгән.

Төзәтү учреждениеләрендә булганда без инвалидлар өчен тиешле тирәлек булдыру өчен кирәкле шартларның җитеклеген өйрәндек.

Тикшерүләр барышында, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 3 нче, 5 нче, 8 нче төзәтү колонияләрендә җәза үтәүче – утыргыч-колясканарда хәрәкәт итүче, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган инвалидлар ихтыяҗлары исәпкә алынмавы ачыкланды.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 3 нче төзәтү колониясендә булганда, инвалид тоткыннар тотылучы торакның керү юлына пандус куелмавы ачыкланды, колясkада утыручы инвалид читләр ярдәменнән башка анда керә алмый.

Аягының түбәнге өлеше киселгән, таяк белән йөрүче инвалид-тоткын тотылган торак бинасында бәдрәф подвальда урнашкан, аңа бару өчен текә баскычтан төшәргә кирәк. Хөкем ителүче бу каршылыкны үзе генә үтә алмый.

Ачыкланган хокук бозулар нәтиҗәләре буенча, Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән төзәтү колонияләрендә тотылучы инвалид тоткыннар өчен уңайлы тирәлек булдыру буенча тиешле чаралар күрүне сорап, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесенә хатлар җибәрде (доклад язылган вакытта Вәкаләтле вәкил хаты карала иде).

Шул ук вакытта безнең кисәтүләрдән соң 3 нче төзәтү колониясендә инвалид тоткыннар өчен уңайлы тирәлек булдыру өчен чаралар күрелде.

Инвалидларны социаль яклау турында законнар инвалидлык сәбәбе буенча кешене аеруны, хокукларын чикләүне тыя. Алар Россия Федерациясендә теләсә кайсы өлкәдә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре гарантияләнгән башкалар кебек үк бер тигез дәрәҗәдә булырга тиеш. Җинаять-башкару системасы учреждениеләре хакимиятләре хөкем ителгән, инвалид булган кешеләргә карата мактау яки кисәтү чаралары кулланганда әлеге принципны сакларга тиеш.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә хөкем ителүчедән шикаять керде, ул изолятор коридоры буйлап учреждение хезмәткәрләре озата барганда «кулларны артка» кую таләбен үтәмәгән өчен тикшерү изоляторында булганда аңа кисәтү чарасы куллануга риза булмавы турында белдерә. Мөрәҗәгать итүче – икенче төркем инвалид, сул аягын кисүләре сәбәпле таякта йөри, шуңа ул бу таләпләрне үти алмаган. Вәкаләтле вәкил катнашыннан соң, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсеннән бирелгән мәгълүматка караганда, мөрәҗәгать итүчегә ясалган кисәтү алынган.

Узган елда, гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлап, без, аерым, төзәтү учреждениеләре хакимиятләренең укуга намуслы мөнәсәбәте өчен тоткыннарга, шул исәптән укый торган, ләкин сәламәтлекләре буенча төзәтү учреждениесендә эшкә урнаша алмаган инвалидларга мактау чараларын практикада ничек куллануын өйрәндек.

Узган елның сентябрендә Вәкаләтле вәкилгә төзәтү учреждениесе хакимияте тарафыннан укуга намуслы караган хөкем ителүчеләргә бүләкләү чаралары куллану мөмкинлеге мәсьәләсе буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 3 нче төзәтү колониясендә җәза үтәүче хөкем ителгән инвалидның анасы мөрәҗәгать итте. Ананың иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче улы эшче һөнәренә укыганда күпчелек фәннәр буенча яхшы өлгереш күрсәткән, ләкин аның төзәтү учреждениесендә эшкә урнашуы өчен хроник авырулары һәм медицина ягыннан каршылыклар булган.

Җинаять-башкару законнары положениеләре буенча «укуга намуслы мөнәсәбәт» иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче тоткынга бүләкләү чаралары куллану өчен нигез булырга мөмкин. Шушы уңайдан, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, эшкә урнашмаган тоткынга карата укуга намуслы мөнәсәбәт өчен бүләкләү чаралары куллану мәсьәләсе аның иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтү чорында хәлен һәм эшне башкару мөмкинлеген исәпкә алып билгеләнергә тиеш.

Үз чиратында, мәҗбүри тоту урыннарында булган затларның, аерым алганда, тикшерү изоляторларында сакта тотылучы балигъ булмаганнарның хокукларын тәэмин итүгә аерым игътибар бирдек.

Узган елның мартында без, прокуратура, җинаять-башкару системасы учреждениеләре җитәкчеләре, кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре катнашында, «Сак астында тотылган шикләнелгән һәм гаепләнгән балигъ булмаган затлар сыйфатлы төп гомуми белем алганда проблемалар» дигән темага чаралар оештырдык.

Аларны үткәрүгә Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре һәм җәмәгатьчелек ярдәмчеләре Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә, республика территориясендә урнашкан тикшерү изоляторларындагы шикләнелгән һәм гаепләнелгән балигъ булмаганнарны укыту процессын оештыруны тикшерү сәбәпче булды.

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 3 нче тикшерү изоляторына (Бөгелмә шәһәре), Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 4 нче тикшерү изоляторына (Минзәлә шәһәре) уку процессында куллану өчен гамәлдәге укыту программасы таләпләренә җавап бирә торган укыту-күргәзмә пособиеләр, дәреслекләр һәм уку әдәбияты бүлеп бирү һәм шулай ук гомуми белем бирүгә педагогик хезмәткәрләрне җәлеп итү, шул исәптән дистанцион рәвештә җәлеп итү мәсьәләләрен карау өчен тәкъдимнәр җибәрелде.

2020/2021 һәм 2021/2022 уку елларында балигъ булмаганнарны укыту, шулай ук тикшерү изоляторларын кирәкле дәреслекләр һәм пособиеләр белән тәэмин итү турында тикшерү изоляторлары һәм мәгариф оешмалары арасында килешүләр төзү, бергә башкарылган эшнең нәтиҗәсе булды.

Алга таба Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына сак астында тотылган балигъ булмаганнарны гамәлдәге укыту программалары таләпләренә җавап бирә торган дәресләр һәм уку әдәбияты белән тәэмин итүне күзәтүне тормышка ашыруны тәкъдим итәбез.

4.2. Гражданнарның кыска вакытлы мәҗбүри булу урыннарында кеше хокукларын яклау

Халыкара хокук нормалары һәм милли законнар мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга гигиена, санитария һәм янгын куркынычсызлыгына җавап бирүче көнкүреш шартлары булдыруны күздә тота.

Узган елда Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Россия Эчке эшләр министрлыгының районнарда булган махсус кабул итү бүлмәләрендә һәм вакытлыча тоту изоляторларында көнкүреш шартларын карау буенча берничә тикшерү үткәрелде.

Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматы буенча, Менделеевск районы буенча 2021 елда федераль һәм төбәк бюджетлардан бүленгән ассигнованиеләргә вакытлыча тоту изоляторы, махсус кабул итү бүлмәсе, тоткарланган кешеләрне тоту өчен өч махсус торагы булган яңа бина кулланышка тапшырылды.

Чирмешән, Аксубай, Алабуга, Минзәлә, Балык Бистәсе районнарында полиция бүлекләре биналары капиталь ремонтланды.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә, вакытлыча тоту изоляторларындагы шартларны тикшерү максатыннан, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре идарәсендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлегендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлегендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре идарәсенең административ арестка алынган затларны тоту өчен кирәкле махсус кабул итү бүлмәсендә булды.

Шикләнелгән һәм гаепләнелгән кешеләрне вакытлыча тоту изоляторлары камераларын һәм административ тәртиптә кулга алынган кешеләрне тоту өчен кирәкле махсус кабул итү бүлмәсен тикшерү барышында, Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегендә тоткарланучыларны матди-көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүдә хокук бозулар ачыкланды, шикләнелгән һәм гаепләнелгән затларны вакытлыча тоту изоляторында һәм административ тәртиптә кулга алынган затлар тотылган махсус кабул итү бүлмәсендә су эчәр өчен баклар юк, махсус кабул итү бүлмәсендә тотылучылар мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгәнчә, кайбер камераларда кандала бар, шулай ук шикләнелгән һәм гаепләнелгән кешеләр тотылучы вакытлыча тоту изоляторы камераларында вентиляция эшләми.

Вәкаләтле вәкил хатын карап, министрлык кимчелекләрне бетерү буенча эшләде. Югарыда күрсәтелгән учреждениеләр камераларында су эчәргә баклар куелды. Вакытлыча тоту изоляторларында һәм махсус кабул итү бүлмәсендә өстәмә дезинфекция эшкәртү эшләре үткәрелде.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеген тикшерү барышында шул ачыкланды: тикшерү изоляторында тотылучы затларны ашату өчен, эчке эшләр органы шундый хезмәт күрсәтүче оешма белән ризык китертү буенча килешү төзегән. Шуның белән бергә, тикшерү вакытында, килешүдә көн саен өч тапкыр кайнар ризык китертү турындагы шарт язылмаган иде. Шуның белән ризыкны кайнар килеш китермәү үтәүче өчен килешү шартын бозу булып исәпләнмәячәк. Тикшерү үткәргәннән соң, килешүгә тиешле үзгәрешләр кертелде.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлеген тикшерү барышында, тоткарланучылар камерасында утыручы кешегә Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2003 елның 15 октябрендә дөнья күргән 627 нче карары белән расланган, административ хокук бозу өчен тоткарланган затларны тоту шартлары, туклану нормалары һәм медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы Положениенең 3 пунктын бозып, билгеләнгән нормада ризык бирелмәве факты ачыкланды. Вәкаләтле вәкил хатыннан соң, әлеге бүлек җитәкчесе тикшерү үткәреп, гаеплеләр җаваплылыкка тартылды.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре идарәсенең административ арестка алынган затларны тоту өчен кирәкле махсус кабул итү бүлмәсендә тикшерүдән соң, 1, 2, 4 катларда урнашкан камераларда кайнар су булмавы ачыкланды (доклад язылган вакытта Вәкаләтле вәкил хаты карала иде).

4.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән хөкем ителгәннәрне һәм затларны ресоциализацияләү

Мәҗбүри тоту урыннарында булган затларның медико-санитария тәэмин ителеше һәм көнкүреш шартлары белән бергә, аларны социаль адаптацияләүгә юнәлтелгән чаралар кабул итүне мөһим дип саныйбыз (сүз монда, барыннан да элек, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче гражданнар турында).

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче хөкем ителүчене социаль адаптацияләү процессы алар җәза үткән вакытта формалашырга тиеш, дип санап, без төзәтү колонияләрендә җәза үтүче затларга һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга булышырга юнәлтелгән эшчәнлек алып баручы иҗтимагый оешмалар вәкилләре инициативаларын һәрдаим якладык.

Вәкаләтле вәкил, иҗтимагый оешмалар белән беррәттән, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медико-санитар часте», Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм прокуратура органнары белән хезмәттәшлек итеп, 19 нчы, 2 нче төзәтү колонияләрендә, махсус төзелгән тернәкләндерү отрядларында психоактив матдәләрдән бәйлелеккә эләккән тоткыннарга психологик яктан булышу проектын тормышка ашыру буенча эшне дәвам итте. Узган ел ахырына берничә дистә кеше тернәкләндерү курсы үтте.

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче гражданны социаль адаптацияләү арасындагы этапта бу җәзаны җиңелрәк җәза, шул исәптән мәҗбүри эшләр белән алыштыруны санарга була.

Мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаларны үтәүне тәэмин итүче төзәтү үзәкләре челтәрен үстерү заманча җинаять-башкару системасын 2030 елга кадәр үстерү юнәлешләренең берсе булып тора. Хөкем ителгәннәрнең әлеге төрен хезмәткә җәлеп итү практикасын киңәйтү максатларында 2030 елга кадәр Россия Федерациясе җинаять-башкару системасын үстерү Концепциясе үзәкләр челтәрен үстерү белән бергә, аларны предприятиеләрдә, шул исәптән, эре объектлар төзелешендә эшкә урнаштыруда бизнес җәмәгатьчелеге катнашуын күздә тота.

Хәзерге вакытта республикада 300 урынга исәпләнгән 1 нче төзәтү үзәге, шулай ук 4 нче төзәтү колониясендә (Түбән Камада) төзәтү үзәге буенча эшләүче участок бар.

Узган елның октябрендә 50 ир тоткын өчен «Кварт» оешмасы тулай торагы базасында 1 нче төзәтү үзәгендә участок оештырылды.

Төзәтү үзәкләрендә исәптә торган 357 тоткынның 326сы эшкә җәлеп ителгән.

Үз чиратыбызда, әлеге төр хөкем ителүчеләрне тагын да зуррак эшләргә җәлеп итүгә бурычлар билгеләгәндә аларның мәнфәгатьләре дә исәпкә алынырга тиеш дип, саныйбыз. Вәкаләтле вәкил фикеренчә, хәзерге вакытта иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче тоткыннар өчен аны мәҗбүри эшләргә алыштыру, үтеп бетермәгән җәза срогын исәпләүне көйләүче гамәлдәге норматив кагыйдәләр уңаеннан җитәрлек мотивацияләнмәгән. Әлеге фикер Россия Федерациясе Җинаять кодексының 79 нчы маддәсе 3 нче өлеше, вакытыннан алда шартлы рәвештә азат ителү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, элек җәзаның үтеп бетерелмәгән өлеше җиңелрәк җәзага алыштырылган очракларда, үтеп бетерелмәгән җәза срогын исәпләүнең аерым кагыйдәләре булмавына нигезләнә. Мондый якын килү хөкем ителүчене гамәлдәге законга ярашлы рәвештә, җәза төрен алыштыру өчен сайлау алдына куя, аңа төзәтү колониясендә калып вакытыннан алда шартлы рәвештә азат ителү мөмкинлеген кабул итәргәме, әллә инде соңрак азат ителеп, мәҗбүри эшләр үтәү өчен төзәтү үзәгенә китәргәме?

Үз чиратында, республикада иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны (аларны җәза үтәүдән азат итү нигезенә карамастан) тормышка яраклаштыру буенча эшне оештыру Татарстан Республикасы хокукый акты белән билгеләнгән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендә дөнья күргән 631 нче «Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру буенча Татарстан Республикасында эшне оештыру турында»гы карары).

Мондый эшне тиешенчә оештыру меңнәрчә кешеләргә ярдәм итәр иде. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматлары буенча, 2021 елда иректән мәхрүм итү урыннарыннан 3964 кеше азат ителгән.

Узган ел Вәкаләтле вәкил иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссияләр эше турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары мәгълүматын анализлады.

Мәгълүматны анализлау шуны күрсәтте: Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасы үткән яки җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар булган затларны тормышка яраклаштыру максатларында социаль-икътисади һәм хокукый характердагы чаралар комплексын тормышка ашыру өчен ведомствоара комиссияләр төзелгән.

Шул ук вакытта Чүпрәле, Мамадыш, Сарман, Спас муниципаль районнары ведомствоара комиссияләре эше турындагы мәгълүматтан күренгәнчә, аларның ризалыгы белән элеккеге тоткыннарны тормышка яраклаштыруның шәхси программаларын эшләү һәм алар белән адреслы эш үткәрүне тормышка ашыру практикасы бар.

Шуның белән бергә, безгә аларны иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат иткәндә эшкә урнаштыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә. Шушы уңайдан җирле үзидарә органнарына Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыруга булышлык итү буенча чаралар турында мәгълүмат җибәрергә тәкъдим итәбез, ул муниципаль районнар (шәһәр округлары) территорияләрендә ведомствоара комиссияләр эше кысаларында үткәрелергә мөмкин. Әлеге мәгълүматны төзәтү учреждениеләре хакимиятләре иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче затларга җиткерсә, шулай ук мәшгульлек хезмәтләре органнарының мәгълүмат стендларына урнаштырылса, максатка ярашлы булыр иде.

Мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга, Россия Федерациясенең җинаять, җинаять-башкару һәм башка законнарында билгеләнгән чикләүләр белән бергә, Россия Федерациясе гражданнары хокуклары һәм ирекләре гарантияләнә. Әлеге төр гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эше алга таба да дәвам иттереләчәк.

5 бүлек. Кеше хокукларын саклау һәм яклау максатларында нәтиҗәле хезмәттәшлек

5.1. Хокукый агарту буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге

Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеген планлаштыра һәм тормышка ашыра, шул исәптән халыкка хокукый белем бирү буенча Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен Халыкара һәм дәүләт программалары документларына ярашлы рәвештә социаль проектлар булдыра. Алар арасында 2030 елга кадәр тотрыклы үсеш өлкәсендә Көн тәртибе зур урын алып тора, анда тотрыклы үсеш өлкәсендә 17 максатка ирешү буенча 15 еллык план формалаштырылды.

Көн тәртибе текстында кеше хокуклары гомуми декларациясе һәм кеше хокуклары буенча Халыкара шартнамәләр, тотрыклы үсешнең 17 максаты турыдан-туры яки читләтеп чагылдырыла. Кеше хокукларының һәр төбәкнең идарә итү үзәге (ЦУР) белән конкрет бәйләнешен анализлауга һәм тиешле бурычларга карап үзара бәйләнеш барлыкка килә: 169 бурычның (92%) күбесе кеше хокуклары өлкәсендә төп Халыкара стандартларга бәйле.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының тотрыклы үсеше өлкәсендәге максатлар һәм аларда тупланган бурычлар 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясендә чагылыш тапты, аңа шулай ук Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлегендә һәм Кеше хокуклары буенча республика стратегиясенә таяна (Татарстан Республикасында 2014 елдан башлап гамәлгә ашырыла).

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елга эш йомгакларын тикшергән һәм 2021 елга бурычларын билгеләгән еллык коллегиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмәгә 2022–2028 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Стратегия эшләү буенча эш төркеме төзү турында тәкъдим кертелде.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил берничә тапкыр Стратегиянең яңа проектын әзерләгәндә конкрет тәкъдимнәр керткән ачык хакимият, иҗтимагый оешмалар вәкилләре белән очрашты, тәкъдимнәр Татарстан Министрлар Кабинетының 2021 елның 24 декабрендә дөнья күргән 1285 нче карары белән расланган Стратегиянең соңгы вариантына кертелде.

Кеше һәм гражданнар хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне, яклауны һәм торгызуны тәэмин итү максатларында, Вәкаләтле вәкил 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән бурычларга таянып эш итә, шулай ук 17 нче законның тотрыклы үсеше максатыннан чыгып, коллегалары – Россия төбәкләре һәм башка илләрдәге омбудсменнар, шулай ук гражданлык җәмгыяте институтлары һәм бизнес вәкилләре белән нәтиҗәле партнерлыкны гамәлгә ашыра.

Бу мәсьәлә 2021 елның 28 июнендә «Казан (Идел буе) федераль университеты» белән берлектә һәм кеше хокуклары буенча БМОның югары комиссары идарәсе ярдәмендә оештырылган «Яңа буыннар өчен кеше хокуклары» VIII Халыкара җәйге мәктәбенең «түгәрәк өстәл» утырышында тотрыклы үсеш өлкәсендә максатка ирешүдә омбудсменнарның роле белән беррәттән фикер алышу темасы булды.

